А. И. Кравченко

ҖӘМГЫЯТЬ БЕЛЕМЕ

# ҖӘМГЫЯТЬ БЕЛЕМЕ



10

сыйныф

«РУССКОЕ СЛОВО»
«ХӘТЕР»

А.И. Кравченко

# ҖӘМГЫЯТЬ БЕЛЕМЕ

**Гомуми белем бирү учреждениеләренең 10 сыйныфы өчен дәреслек**

*Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән*

*Тәрҗемә Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан расланган*

**Москва**
**«Русское слово»**
**2009**

**Казан**
**«Хәтер»**
**2009**

ББК 60я72
К78

Серия бизәлеше: *Т. Н. Войткевич*
Рәссамнар: *В. Д. Сергеев, Е. С. Шабельник, Л. Н. Путина*

Тышлыкта *Пауль Клееның* «Физиогномик этюд. Яшен» дигән картинасыннан фрагмент.— 1927 ел.

**Кравченко А.И.**

К78 Җәмгыять белеме: Гомуми белем бирү учреждениеләренең 10 нчы с-фы өчен д-лек. Русча 8 нче басмадан М.Х.Харисов тәрж. — «ТИД «Русское слово — РС» ААҖ, 2009.— 192 б.

ISBN 978-5-94113-302-4

Әлеге дәреслек А.И.Кравченконың 8 һәм 9 сыйныфлары өчен дәреслекләренең логик дәвамы булып тора. Анда икътисад, политология нигезләре тагын да тирәнрәк һәм күпьяклырак бәян ителә, шулай ук җәмгыять үсешенең төп күренешләре карала.

Дәреслек бүгенге укучылар өчен җиңел һәм аңлаешлы итеп язылган.

ББК 60я72

ISBN 978-5-94853-999-7
ISBN 978-5-94113-302-4

© ООО «ТИД «Русское слово — РС», 2001, 2009
Все права защищены
© Татарчага тәрҗемә, «Хәтер», 2009
Барлык хокуклар сакланган

# Эчтәлек

**Кереш** .................................................... 4

1 бүлек. **Җәмгыятьне фәнни танып-белү**

§ 1. Әйләнә-тирә дөньяны танып-белү ............... 8
§ 2. Җәмгыятькә карашлар тарихы ..................... 16
§ 3. Җәмгыятьнең төзелеше ............................ 24
§ 4. Цивилизация һәм җәмгыять ........................ 31

2 бүлек. **Җәмгыятьнең үсеше**

§ 5. Бүгенге җәмгыять ..................................... 39
§ 6. Модернизация (камилләштерү) ...................... 47
§ 7. Кешелек дөньясын глобальләштерү ................ 54
§ 8. Дөньякүләм система ................................... 59

3 бүлек. **Базар икътисады**

§ 9. Базар җәмгыяте ........................................ 65
§ 10. Капитализм эволюциясе .............................. 73
§ 11. Хезмәт белән капитал арасындагы мөнәсәбәтләр ........................................ 82

4 бүлек. **Җитештерү сферасы**

§ 12. Җитештерүче базарда .................................. 91
§ 13. Эшмәкәрлек һәм бизнес ................................ 99
§ 14. Базар икътисады инфраструктурасы .......... 107
§ 15. Икътисадта дәүләтнең роле ....................... 116

5 бүлек. **Җәмгыятьнең сәяси системасы**

§ 16. Сәяси хакимият ....................................... 122
§ 17. Дәүләтнең асылы һәм оешуы ..................... 128
§ 18. Җирле үзидарә ........................................ 135

6 бүлек. **Җәмгыятьнең сәяси тормышы**

§ 19. Сәяси тормыш шартлары ........................... 143
§ 20. Сәяси тормышны идарә итү формалары һәм гражданнарның катнашу механизмнары ..... 151
§ 21. Сәяси тормыш субъектлары ........................ 161

**Сүзлек** .................................................. 169
**Әдәбият** ................................................ 190

# Кереш

Без XXI гасырда моңарчы күрелмәгән тизлекләр, өр-яңа технологияләр, дөньяны гуманитар үзгәртеп корулар чорында яшибез. Әлеге мәгълүмати гасырда әйләнә-тирәне танып-белү киңәя, белемнәр тулылана, арадаш профессияләр үзләштерелә. Белемнәрнең бер өлкәсеннән икенчесенә шунда ук күчү, эшне даими алыштырып тору һәм хезмәт базарындагы хәлләрнең үзгәрешенә вакытында реакция ясау, бөтен гомер буена туктаусыз уку һәм, ниһаять, мәҗбүри югары белем — боларның барысы да без тиздән яшәячәк дөньяның контурларын билгелиләр.

Кеше иртә балачактан ук инде үзенең алты-җиде яшьтә һичшиксез, мәктәпкә барачагын белә. Гәрчә кайберәүләр 9 нчы сыйныфка кадәр барып җитә алмасалар да, күпчелек укучылар укуларын 10 һәм 11 нче сыйныфка кадәр дәвам иттерүне күздә тоталар, бу исә университет, академия, институтка керү хокукы бирә. Югары белем абруйлы гына түгел, ә перспективалы да. Ул бизнеска, фәнгә, халыкара мөнәсәбәтләр өлкәсенә юл ача, артистлык яки юридик эшчәнлек белән шөгыльләнү, законнар эшләүче яки табиб булу мөмкинлеге бирә.

Узган гасырның 90 нчы еллары ахырында мәктәпне тәмамлаучылардан нинди профессияләр турында хыяллануылары турында сорагач, беренче урынга бизнес, хокук, менеджмент белән шөгыльләнү чыккан. 1991 елда безнең ил базар икътисады һәм демократия юлына баскач, әлеге профессияләр тулы бер дистә еллар дәвамында модада булдылар. 90 нчы еллар уртасында тагын бер бик тә кызык хәл күзәтелде: мехмат һәм химфакларны, педагогика һәм инженерлар вузларын тәмамлаучылар менеджмент, бизнес, психология, хокук белемнәренә ия булу өчен вуздан соң яңадан уку курсларына тартылдылар.

Хәзерге чор — фәнни һәм гамәли белемнәр системасында лидерлык социаль фәннәргә — икътисад, юриспруденция, психология, социология, менеджмент, политологиягә һ.б. күчү вакыты. Алар мәктәп җәмгыять белеме

курсында китереләләр. Сәяси терминологиядән файдаланып, болай дип әйтергә мөмкин: якын перспективада социаль белемгә — төп юнәлешләрне билгеләүче, ә инженерлык һәм техник фәннәргә башкарма хакимият роле биреләчәк. Социаль, киң мәгънәдә иҗтимагый фәннәр безнең илдә беренче планга XX гасырның 90 нчы елларында, ә Көнбатышта 60 нчы еллар ахыры — 70 нче еллар башында чыкты. Ихтимал, XXI гасыр ахырында яисә XXII гасырда хакимлек итүче биеклекләр иҗтимагый фәннәрнең гуманитар белем дип атала торган башка өлешенә: әдәбият белеме, сәнгать белеме, культурология, этика, философиягә һәм башка иҗади эшчәнлек өлкәләренә биреләр. Аларның кайберләре белән сез мәктәп җәмгыять белеменең әлеге курсында танышырсыз. Димәк, дәреслекләр киләчәккә перспектива белән язылганнар.

Шулай итеп, җәмгыять белеме бүген һәркемгә — булачак химикларга да, физик, инженер, бизнесмен, адвокат, табибларга, идарә итүчеләргә һәм башкаларга да кирәк. Яшь буын үзен нинди генә һөнәргә әзерләсә дә, кеше психикасы законнары, эшлекле коммуникация үзенчәлекләре турындагы фәннәрдән, сәяси көрәш һәм икътисадны оештыру принциплары, үзенең гражданлык хокуклары турындагы белемнәрдән, шулай ук мәдәният, фән һәм дин турындагы мәгълүматтан башка яши алмый.

8 һәм 9 сыйныфлар өчен җәмгыять белеме курсларында төп басым кеше һәм җәмгыять турындагы башлангыч фәнни белемнәргә ясалды, алардан аермалы буларак, 10 һәм 11 сыйныфлар өчен яңа дәреслекләрдә игътибар конкрет фәннәрнең — хокук, икътисад, психология, философия, социология, политология, культурология, этиканың нигезләрен тагын да тирәнрәк һәм җитдирәк өйрәнүгә юнәлдерелде. Биредә төп максат — вузга керергә әзерләнү өчен белемнәр базасы бирү.

Шуның белән бергә биредә белемнәрнең әлеге өлкәләрендәге төшенчәләр, теорияләр һәм якын килүләрнең барлык күптөрлелеген колачлау максаты куелмады. Сез вузда укыганда танышачак зур фән махсус терминология һәм меңләгән фәнни теория белән тутырылган һәм аларны бер китап, өстәвенә мәктәп укучысына исәпләнгән дәреслек битләрендә урнаштырып бетерү мөмкин түгел. Мисалга,

лизингның нинди булуы һәм банк операцияләренең ничек баруы, акцияләрнең конкрет төрләренең нәрсә белән аерылуы һәм бүгенге базар икътисадында аудитның нинди төрләре булуы турындагы белемне, әлбәттә, вузлардагы махсус курсларда яки, ахыр чиктә, «Икътисад нигезләре» тибындагы модульле мәктәп курсларында яисә менеджмент буенча практикумда бәян итү дөресрәк булыр.

Җәмгыять белеменең мәктәп курсы 16–17 яшьлек үсмернең дөньяга карашына юнәлеш тотса, бер үк вакытта инде булган тормыш тәҗрибәсенә, аны киңәйтеп һәм тирәнәйтеп мөрәҗәгать итсә, отышлырак булачак.

Өлкән сыйныфларда җәмгыять белеме, автор фикеренчә, үзенең асылында яшүсмер белән, әхлак проблемаларын да кертеп, ышанычлы сөйләшү формасы булып калырга тиеш. Өлкән үсмерлек яшеннән яшүсмерлек чорына күчү — үзең өчен тормышның мәгънәсе яки гомумкешелек кыйммәтләре турында гына түгел, шулай ук яхшылык, явызлык, бәхет, бурыч, хәшәрәтлек һәм канәгатьлек турында да кардиналь этик проблемалар кую һәм хәл итү вакыты. Менә шуңа күрә дә сез мораль һәм әхлак турындагы киңәйтелгән бүлекне 11 нче сыйныф дәреслегеннән табарсыз.

10 һәм 11 нче сыйныфлар өчен җәмгыять белеменең тирәнәйтелгәнрәк курсы гамәли максатны да күздә тота, ягъни әгәр абитуриент, репетитор ярдәмендә һәм вуз каршындагы әзерлек курсларына мөрәҗәгать итмичә, мөстәкыйль әзерләнү юлын сайласа, ул вузга керү өчен кирәкле белемнәр минимумын бирә. Бәлки, тәкъдим ителә торган китап үз тематикасы кысаларында мәктәп белән вуз арасында булган аерманы ничектер кыскартырга һәм сезне вузда очрашырга туры киләчәк нәрсәләргә яхшырак әзерләнергә ярдәм итәчәк.

Җәмгыять белеме курсының башка бер максаты — профориентация башлангычлары бирү. Күпләгән өлкән сыйныф укучылары моның нәрсә икәнен ачык аңлап бетермичә, юрист, икътисадчы булырга тели. Профессияне ялгыш сайлау еш кына язмышны сындыра. Әлбәттә, барысын да яңадан башларга, башка вузга күчәргә, профессияне алыштырырга беркайчан да соң түгел. Ләкин укырга еш кына күп акча кирәк була, ә профессияне алыштыруга

кыйммәтле вакыт сарыф итеlә. Җәмгыять белеме егетләргә һәм кызларга икътисадның, хокук, психология, социология һ.б. ның нәрсә икәнен аңларга ярдәм итәргә тиеш.

Этимологияне генә түгел, белемнәрнең эчтәлеген дә исәпкә алсак, җәмгыять белеме колачлый торган проблемалар даирәсенә чит илдә социаль фәннәр дип аталган һөнәрләр дә керә. Аларга социология, икътисад, психология, антропологияне кертәләр. Безнең ил традицияләре күзлегеннән караганда җәмгыять белеменә шулай ук, гадәттә, гуманитар (кыйммәти) белемнәр булып исәпләнгән культурология, этика, философия, хокук та керә.

10 һәм 11 нче сыйныфлар өчен яңа дәреслекләрдә белемнәр киңәйтеләчәк һәм тирәнәйтеләчәк. Сезгә мәктәп һәм вуз белеме системасында лидерлык позицияләренә чыга торган социаль һәм гуманитар фәннәрнең катлаулы дөньясы ачылачак.

Дәреслекләрне басмага әзерләгәндә ярдәм иткән кыйммәтле киңәшләре һәм тәкъдимнәре өчен автор С. И. Козленкога, А. П. Попов, Н. А. Моисеева, А. А. Сорокин, И. С. Хромова, А. Ю. Лазебникова, А. М. Водянскийга тирән рәхмәтен белдерә.

# 1 бүлек
# Җәмгыятьне фәнни танып-белү

## § 1. Әйләнә-тирә дөньяны танып-белү

**Фәннең һәм без барыбыз да көндәлек тормышта таяна торган гадәти аңның нигезендә танып-белү процессы ята.**

**ТАНЫП-БЕЛҮ — субъект фикерләвендә чынбарлыкны чагылдыру һәм кабул итү, аның нәтиҗәсе — дөнья турында яңа белем ул. Танып-белү, кагыйдә буларак, фәкать хакыйкатьне эзләү процессы гына, ә аның нәтиҗәсе — белем.**

**БЕЛЕМ — чынбарлыкны танып-белүнең практика тарафыннан тикшерелгән нәтиҗәсе, кеше фикерләвендә аның дөрес чагылышы.**

Танып-белүнең максаты булып объектив дөнья турында теләсә нинди (кайчакта ялган) түгел, ә нәкъ менә объектив белемнәр алу тора. Танып-белү процессында теләсә нинди, ягъни ялган белемнәр дә чагылыш таба, ләкин артык хезмәт буларак кына.

Белем буларак аңлана:

*— киң мәгънәдә — теләсә нинди мәгълүмат;*

*— тар мәгънәдә — фәнни чаралар белән расланган мәгълүмат.*

Фәнни белемдә фәнни алым ярдәмендә алынган барлык нәтиҗәләр һәм фаразлар тәнкыйтьләнергә яки кире кагылырга мөмкин.

***Танып-белү төп ике баскыч үтә — сизү һәм рациональ (логик) танып-белү.*** Сизү белән танып-белү — түбәнге баскыч — тою, кабул итү һәм күзаллау формаларында гамәлгә ашырыла. Анда сизүнең кешене тышкы дөнья белән бәйләп тора торган биш әгъзасы — күрү, ишетү, тотып

тою, ис һәм тәм сизү эшкә җигелә. Сизү образлары — безнең тышкы дөнья турындагы барлык белемнәребезнең бердәнбер чыганагы. Ләкин сизү образларында күпчелек күренешләрнең тышкы ягы теркәлә, фәкать аерым әйберләр генә танып-беленә.

Икенче баскычта — *рациональ (логик) танып-белүдә* — фикерләү һәм акыл ярдәмендә гомуми әһәмиятле яклар ачыклана. Сизү әгъзалары алган мәгълүматлардан әһәмиятлесен аерып алып, кеше фикерләүләр, фикри нәтиҗәләр һәм төшенчәләр ясап, әйләнә-тирә дөньяның закончалыкларын танып-белә.

*Танып-белү процессының һәр ике баскычы — сизү һәм рациональ танып белү бердәмлектә яши*, бер-берләренә көчә, бер-берсен тулыландыра. Алар, һичшиксез, гомуми эштә союздаш булырга тиеш. Әгәр берсе икенчесе исәбенә өстенлек итәргә теләсә, объектив дөрес белем алу мөмкин түгел. Алар берсенең хезмәтләрен киметеп күрсәтеп, танып-белү процессын фәкать бер формага — сизүгә яки рациональгә кайтарып калдырып өстенлеккә ирешергә омтыла.

Танып-белүдә сизүнең ролен арттырып күрсәтү философиядә сенсуализмны барлыкка китергән.

**СЕНСУАЛИЗМ** (лат. sensus — кабул итү, хис) — танып-белү теориясендә сизүне, кабул итүне дөрес танып-белүнең нигезе һәм төп формасы итеп санала торган юнәлеш. Сенсуализмның төп принцибы — «хисләрдә булмаган нәрсәләрнең акылда берсе дә юк».



Танып белүдә акылның ролен арттыру икенче бер фәлсәфи агымны — рационализмны барлыкка китергән.

> **РАЦИОНАЛИЗМ** (лат. rationalis — акыллы, ratio — акыл) — акылны танып-белүнең нигезе һәм төп формасы итеп таный торган фәлсәфи агым, сенсуализмга каршы тора. Рационализм нигезендә, фәнни (ягъни объектив, гомуми, зарури) белемгә фәкать акыл — бер үк вакытта белем чыганагы һәм аның дөреслегенең критерие белән генә ирешеп була.

***Танып-белү процессына шулай ук фикерләү эшчәнлегенең фаразлау, фантазия, гипотеза, күзаллау, хыял, интуиция кебек формалары да кирә.*** Галимнәр һәм сезнең белән без, үз эшләребезне интуициягә нигезлибез, ул уңай нәтиҗәләргә китерергә, фаразлауларны акларга, әмма ялгыш та булырга, озак вакыт ялгышлар һәм тискәре нәтиҗәләр тудырырга мөмкин.

***Интуиция ул — зирәклекнең (чын яки ялган) балкып китүе, аның барлыкка килүен төгәл билгеләү яки аңлату мөмкин түгел***, белем алуның интуитив ысулы турында сөйләгәндә, без шуннан чыгып эш итәчәкбез. Интуиция башка алымнар белән тикшерелергә мөмкин булган күпләгән бик тә мөһим фаразларга нигез булып хезмәт итә. Фән тарихы күрсәткәнчә, интуиция фәнни белемнең аерылгысыз компоненты булып тора һәм аның төп кыйммәте фәнни теорияне тикшергәннән соң чын һәм нигезле фаразларын табудан һәм формалаштырудан гыйбарәт.

Әмма интуиция әйләнә-тирә чынбарлык турында чын белемнәрнең ышандырырлык чыганагы булып санала алмый. Еш кына ул бик үк дөрес булмаган мәгълүматка, өзек-өзек хәбәрләргә нигезләнә. Интуитив белем ышануга кабул ителә, фәнни тикшерү һәм дәлилләү үтми, күбрәк фәнни танып-белүгә беренче баскыч булып хезмәт итә. Аның базасы — гадәти белем, ягъни ялгышулардан азат булмаган көндәлек тормыш тәҗрибәсе. Аек мәгънәгә, гомуми кабул ителгән фикергә нигезләнгән күп кенә раслаулар чын булып чыкмый.

*Фәнни танып-белүнең аерым билгесе булып аның тикшерелгән дәлилләргә нигезләнүе тора.* Бу очракта дәлилләр

булып, фактик күзәтүләрнең башка күзәтүчеләр күрә, үлчи, исәпли яки тәгәллеккә тикшерә ала торган конкрет нәтиҗәләре санала.

*Фәнни белем алуның алымы — фәнни тикшеренү.*

> **ТИКШЕРЕНҮ** — нинди дә булса объект (матди яки идеаль предмет яисә күренеш) закончалыкларын ачу максатында фәнни өйрәнү процессы.

Ул телескоп, барометрдан башлап, психологик тестларга кадәр булган, махсус конструкцияләнгән инструментларга һәм алымнарга таяна.

Тикшеренүгә шәхси алымнарны (аерым фәннәр — физика, химия, биология һ.б. өчен специфик хас булган алымнарны) һәм гомуми фәнни алымнарны (анализ, синтез, индукция, дедукция, аналогия, гипотеза, аксиомалаштыру, формалаштыру һ.б.) куллану кирә.

*Фәнни тикшеренүнең* үзара тыгыз бәйләнгән *ике баскычын* аерып күрсәтәләр:

— ***эмпирик*** — яңа фактлар табу, теге яки бу процессның агышын гомумиләштерү һәм аның тенденцияләрен эзләү;

— ***теоретик*** — гомуми закончалыкларны формалаштыру, бербөтен фәнни теория булдыру, аннары дөньяның киңәйтелгән фәнни картинасын формалаштыру.

*Эмпирик* (грек. empeiria — тәҗрибә) — *кешегә сизү тәҗрибәсе нигезендә бирелгән бар нәрсәне, ягъни аның тою, кабул итү, тышкы йогынтыларны чагылдыру, борчылу яки нәрсәне дә булса аңлау сәләтләрен аңлата.*

Фәнни тикшеренүнең *теоретик* баскычының төп компонентлары булып түбәндәгеләр санала:

— максатлар һәм бурычлар кую;

— тема буенча әдәбиятны алдан анализлау;

— башлангыч гипотезаларны формалаштыру;

— кыр тикшерүе (сорап белешү, күзәтү, эксперимент һ.б.) оештыру һәм үткәрү;

— алынган мәгълүматларны анализлау һәм гомумиләштерү;

— алынган фактлар нигезендә башлангыч гипотезаларны тикшерү;

— яңа фактларны һәм законнарны тәмам формалаштыру, аңлатмалар яки фәнни фаразлаулар алу.

Теләсә нинди тикшеренүнең ахыр этабы алынган нәтиҗәләрне гамәлгә кертү булырга тиеш. *Тикшеренүнең йомгагы, ягъни нәтиҗәсе — яңа фәнни белемнәр — объектив хакыйкать алу,* ягъни яңа формалаштырылган белемнең, объектның чынлыктагы хәле белән тикшеренү программасында билгеләнгән практик нәтиҗәләрнең туры килүе.

> **ХАКЫЙКАТЬ** — предмет һәм күренешләрнең кеше аңында танып-белүче субъекттан тыш һәм аңа бәйсез рәвештә чагылуы.

Хакыйкать кеше аңында чынбарлыкны объектив дөрес чагылдыру булып тора. Ләкин хакыйкать — фикерләүләр, төшенчәләр, теорияләр рәвешендәге ирешелгән нәтиҗә генә түгел. Хакыйкать белмәүдән белүгә, саерак белемнән тагын да тирәнрәк белемгә бару процессы ул. Һәм, димәк ки, ул чынбарлык объектларын ниндидер катып калган үзгәрешсез чагылдыру булып карала алмый. *Мәңгелек, үзгәрешсез хакыйкатьләр юк.* Хакыйкать һәрвакыт *чагыштырмача,* чөнки ул тикшерелә торган предметның бөтен эчтәлеген түгел, ә аның бер өлешен генә колачлый. Танып-белү үсә барган саен, кеше акрынлап хакыйкатьнең чагыштырмалылыгын җиңә бара, яңадан тикшерә, элек хакыйкать дип саналган иске белемнәрне раслаучы яки кире кагучы яңа белемнәр өсти. Чагыштырмача хакыйкать аша кеше абсолют хакыйкатькә — максималь объектив, төгәл, тулы һәм аны куллану өлкәсе белән чикләнмәгән, танып-белүнең алга таба үсеше белән кире кагылмый торган хакыйкатькә бара. *Хакыйкатьнең критерие — практика.* Барлык фәнни хакыйкатьләр тәҗрибә мәгълүматларына корылган, алар яңа дәлилләр яктылыгында даими рәвештә яңадан каралып тора.

Кайчак, янәсе, хакыйкать предметлар һәм күренешләрнең үзләренә хас, дигәнне ишетергә туры килә. Ләкин моның белән килешеп булмый. Чын яки ялган өсталләр юк, язу, аш, журнал өсталләре бар. Хакыйкать объектларның үзләренең үзенчәлеге түгел. Хакыйкать төшенчәсе фәкать

фикерләргә карата гына кулланыла, алар чынлап та дөрес яки ялган булырга мөмкин. Танып-белүдә хакыйкатькә каршы ялган тора.

**ЯЛГАН** — дөрес түгел, кемне дә булса ялгыштыру максатын күздә тотып, эшләрнең чынбарлыктагы хәлен бозып күрсәтү ул.

Ялганның чыганагы — логик яктан ялгыш фикер йөртү, дөрес булмаган фактлар һ.б. Ялганны булмаганны уйлап чыгару дип тә, булганны белә торып яшерү дә дип аңларга мөмкин. Логикада ялган хакыйкатьне инкарь итүне, ә хакыйкать ялганны инкарь итүне аңлата.

*Теоретик танып-белүнең иң югары формасы — дөньяны фәлсәфи аңлау.* Белемнәрне анализлау һәм синтезлау, дедукция һәм индукция, гадидән катлаулыга һәм күренештән асылга таба бару ысуллары үз камиллекләренә нәкъ менә философия кысаларында ирешәләр.

**ДЕДУКЦИЯ** (лат. deductio — чыгару) — фикер йөртүләр чылбыры, алар нәтиҗәсендә кеше гомуми белемнәрдән конкрет белем ала.

«Сәнәгать ягыннан үскән барлык илләрдә шәһәр халкы авылныкыннан күбрәк булырга тиеш», дигән гомуми закончалык белән таныш булгач, без, әгәр үскән илләр рәтенә керәбез икән, Россиядә дә шәһәр халкы саны авылныкыннан күбрәк булырга тиеш, дигән нәтиҗә ясый алабыз.

Моннан тыш, тагын логик юл белән без, аерым алганда, кешеләрнең авылдан шәһәргә күчеп килүе, билгеле бер вакыттан авылда кадрлар кытлыгы башланачагы, шәһәрдә яшәү рәвеше кыйммәтләренең авыл җирләренә таралуы һ.б. турында өстәмә мәгълүмат алырга сәләтлебез.

Моңа индукция каршы тора.

**ИНДУКЦИЯ** (лат. inductio — юнәлтү) — фактлардан гомуми раслауларга кадәр фикри нәтиҗә ясау.

Узган гасырның 90 нчы еллар башында яшүсмерләрнең укуларын дәвам иттерү урынына башта хезмәт, барыннан да элек коммерция эшчәнлеген башлауга өстенлек бирүләрен дәлилли торган күпләгән фактлар ачыла. Күпчелек

вузларда конкурс кими, абитуриентлар азая. Мондый фактларны гомумиләштерү галимнәргә җәмгыятебезнең белем бирү кризисы кичерүе турында нәтиҗә ясау мөмкинлеге бирә. Әмма 90 нчы еллар уртасына вузларда конкурс үсә, югары белем алырга теләүчеләр саны арта. Яңа фактларны гомумиләштерү белгечләрне белем кризисы тәгәлләнде дигән фикергә китерә.

Фәнни белем дедукция һәм индукция алымнарын әйләнә-тирә чынбарлыкка карата эзлекле куллану, гипотезалар тәкъдим итү һәм аларны эмпирик тикшерү нәтиҗәсе булып тора. Шулай итеп, *фәнни тикшеренү нигезендә фәлсәфи фикерләү ята*, дисәк, ялгышмабыз.

Аңа гомумилек кенә түгел, ә социаль тормышны аңлауда бөтенлек, системалылык та хас. Фәлсәфи фикерләү акыл, логика, күзәтүчәнлек көченә, аерым күренешләрдә гомумкешелек мәгънәсен ачу осталыгына таяна. Философия фәнгә проблеманы бербөтен итеп күрүне, бердәнбер гомумне яктырту осталыгы, нәтиҗәләрне логик каршылыксыз чылбыр итеп бәйләү омтылышы бирә.

Фәлсәфи танып-белүнең төп алымы — кешелекнең җыелма тәҗрибәсенә, барлык фәннәрнең казанышларына таяна торган *теоретик фикерләү*. Фәлсәфи алымның өстенлеге дөньяның гомумиләштерелгән картинасын алудан, ягъни тормышны мөмкин кадәр киңрәк теоретик аңлаудан гыйбарәт. Фәлсәфи эзләнүләргә табигый гына түгел, ә социаль тормыш та керә. Социаль тормышны фәлсәфи тикшеренү *социаль философия* дигән исем алды.

Социаль философия кешенең социаль яшәвенең ахыргы сәбәпләрен, мәңгелек нигезләрен ачуда, җәмгыятьтә кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләре урнашкан төп башлангычларны аңлауда мөһим роль уйный. Аның күп гасырлык тарихи традициясе бар: җәмгыять турында антик өйрәнүләр; Яңарыш чоры гуманизмының фәлсәфи традициясе; француз материалистларының кеше эшчәнлегенең ахыр хәрәкәт иттерүче көчләре турындагы өйрәтүе; Мәгърифәт чоры җәмгыятен оештыруның сәяси теорияләре; иҗтимагый килешү (Т. Гоббс); кешенең табигый хокуклары (Д. Локк) инде Яңа вакытта булдырылган XXII гасырның «тормыш фәлсәфәләре» идеяләре.

[1] **Төшенчәләр**: *танып-белү, сенсуализм, рационализм, тикшеренү, хакыйкать, ялган, дедукция, индукция.*

## Сораулар һәм биремнәр

1. Танып-белү җәмгыять тормышында нинди роль уйный? Танып-белү югалса, кешеләр тормышында нәрсә үзгәрер иде?

2. Танып-белү яңа белемнәр алу процессы булып тора. Әгәр кешелек дөньясы туплаган бар нәрсәне сакласаң, яңаны табуның кирәге юктыр, бәлки? Чөнки кайчандыр кеше ачкан күпме нәрсә соңыннан онытыла. Аны йөз, мең еллар үткәч кире ачалар. «Яңа ул — яхшы онытылган иске», дигән әйтем бар. Сез «яхшы онытылган иске»гә мисаллар китерә аласызмы?

*3.[2] Чынбарлыкка актив мөнәсәбәт булган танып-белүгә саташу һәм хыял дөньясына китү каршы тора. Чынбарлыктан качу өчен кешеләр төрле ысуллар уйлап тапкан: наркотиклар белән исерү, кешенең үз тормыш активлыгын киметү, дәрвишлек һәм бунтарьлык. Дәрвиш дөньядан аның белән бернинди дә уртаклыгы булмасын өчен йөз чөерә. Бунтарь еш кына чынбарлык законнары белән исәпләшеп тормыйча, дөньяны үз теләкләре, идеалы буенча үзгәртеп корырга тырыша. Танып-белүдән качуның бу һәм башка ысуллары турында сезгә нәрсәләр билгеле? Кыскача хикәя төзегез.

*4. Шундый сүз бар: танып-белү — белемсезлек галиме юлы, ягъни кешенең үз томаналыгы үлчәменә ирешүе. Сез моны ничек аңлыйсыз?

5. Сизеп һәм рациональ танып-белү үзара нинди нисбәттә тора? Ни өчен алар үзара конфликтка керә ала? Сезнең танып-белү ысулыгызда кайсы башлангыч — сизүме, әллә рациональме өстенлек итә?

**? Проблема.** Бүгенге кешеләргә әйләнә-тирә дөнья турында нинди белемнәр һәм ни өчен кирәк?

---

[1] Төшенчәләр параграфның ахырында укытучы алар белән эшләүне оештыра алсын өчен аерып бирелә.

[2] * билге булган сораулар катлаулырак булып саналалар.

**Практикум.** Параграфта фәнни тикшерену этаплары күрсәтелгән. Алардан файдаланыгыз һәм шпаргалкалар куллану темасына үзегезнең тикшеренүегезне үткәрергә тырышыгыз. Бурычлар куегыз, гипотезалар формалаштырыгыз һ.б. Ахырдан нәтиҗәләр турында кыскача отчет языгыз (1–1,5 битләр).

## § 2. Җәмгыятькә карашлар тарихы

**Фикер ияләре борынгы заманнардан ук ике яки күбрәк кешенең үзара тәэсир итешүенең механизмнары һәм глобаль социаль процесслар белән идарә итә торган яшерен пружиналарны ачарга тырышканнар. Башкача әйткәндә, кешелек җәмгыятенең структурасын һәм төзелешен ачып, алар бер үк вакытта аерым индивидның үз-үзен тотышын һәм кешеләр тормышының үзара тәэсир итешүен өйрәнергә онытмаганнар.**

Җәмгыять белеме буенча беренче хезмәт итеп бөек антик философ ***Платонның*** (б.э.к. 427–343) күренекле «Дәүләт» дигән әсәрен исәпләргә була (антик заманда «җәмгыять» һәм «дәүләт» аерылмаганлыктан, һәр ике төшенчә синонимнар буларак кулланылган). Ул җәмгыятьне өч сыйныфка бүлә: дәүләт белән идарә итүче акыл ияләреннән торган *югары*; аны фетнәләрдән һәм тәртипсезлекләрдән саклаучы сугышчыларны да кертеп (күрәсең, борынгы

заманда да хәрби-сәнәгать комплексы бик үк соңгы рольне уйнамаган) *урта*; һөнәрчеләр һәм крестьяннар кергән *түбән сыйныф*. Югары сыйныфка бик тә зур өстенлекләр бирелгән, ләкин ул даими рәвештә хакимияттән явызларча файдаланган. Мондый хәл булмасын өчен аксөякләрне, Платон фикеренчә, кешеләрнең әхлагын боза торган шәхси милектән мәхрүм итәргә кирәк. Дәүләт белән идарә итүгә 50 яшькә җиткән, югары белемле һәм талантлы, аскетларча яшәү рәвеше алып баручы кешеләр җәлеп ителергә тиеш.

Аристотель (б.э.к. 384–322), үзләренең табигатьләре буенча барлык кешеләр дә танып-белүгә һәвәс, дип белдерә. Ул хәзерге галимнәр кебек үк традицияләрне, гореф-гадәт, әхлак, кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләрен өйрәнә, фактларны гомумиләштерә, җәмгыятьне ничек итеп камилләштерү турындагы гамәли тәкъдимнәр белән тәмамланган концепцияләр төзи. Аристотельдә тәртип һәм дәүләт таянычы — *урта сыйныф*. Аннан башка тагын ике сыйныф билгеләнә — *бай плутократия* һәм милектән мәхрүм *ярлылар*. Дәүләт барыннан да яхшырак шундый очракта идарә ителә, әгәр: 1) ярлы массалар идарә итүдә катнашудан мәхрүм ителмәсә; 2) байларның эгоистик мәнфәгатьләре чикләнсә; 3) урта сыйныф башка ике сыйныфка караганда сан ягыннан күбрәк һәм көчлерәк булса. Җәмгыятьнең камил булмавы тигезләп бүлү белән түгел, ә кешеләрнең әхлакый яхшыруы белән төзәтелә, дип өйрәтә Аристотель.

Аристотель белән Платоннан соң кешенең һәм дөньяның килеп чыгуына дини карашлар хакимлек иткән бик тә озын, ике мең елга сузылган тарихи пауза урнаша.

Чын фәнни белемнәргә таба борылыш фәкать XVII–XVIII йөзләрдә Европада даһи философлар плеядасы барлыкка килгәч кенә башлана. Алар: француз ***Рене Декарт*** (1596–1650), инглизләр ***Френсис Бэкон*** (1561–1626), ***Томас Гоббс*** (1588–1679) һәм ***Джон Локк*** (1632–1704), немец ***Иммануил Кант*** (1724–1804). Шулай ук француз мәгърифәтчеләре ***Шарль Луи Монтескьё*** (1689–1755) һәм ***Жан Жак Руссо*** (1712–1778) хөкүмәтнең вазыйфаларын һәм җәмгыятьнең табигатен өйрәнәләр. Инглиз философлары ***Дэвид Юм*** (1711–1776) һәм ***Джордж Беркли*** (1685–1753), шулай ук Кант һәм Локк акыл тәэсире законнарын ачыкларга тырышалар, ә шотландияле икътисадчы һәм фи-

лософ ***Адам Смит*** (1723–1790) икътисад буенча «Халыклар байлыгының табигате һәм сәбәпләре турында тикшерену» (1776) дигән беренче трактат яза.

Дж. Локк Көнбатыш либерализмының атасы, конституцион монархия һәм дөрес төзелгән дәүләттә динамик тигезләнеш хәлендә булган: законнар чыгару, башкарма (судны да кертеп) һәм федератив (тышкы элемтәләр) хакимиятләргә бүленүнең теоретигы булып исәпләнә. Җәмгыятьнең «табигый халәтен», «барысының да бөтенесенә каршы сугышы» буларак аңлатучы Т. Гоббстан аермалы буларак, Локк табигый хәл дип үз хезмәтләре белән яшәүче кешеләрнең ирекле һәм тигезлеген саный. Шуның белән бергә ул, кешеләрнең төп табигый хокуклары — милеккә хокуклары — низаглар килеп чыгуга юл куймау өчен акыллы законнар тарафыннан ныгытылырга тиеш, дип раслый. Моның өчен иҗтимагый шартнамә нигезендә халык алдында җаваплы булган хөкүмәтне оештыручы сәяси җәмгыять төзелә.

Француз мәгърифәтчесе, хокук белгече һәм философы Шарль Луи Монтескьё дәүләт һәм җәмгыять турындагы күзаллауларны үстерүдә мөһим роль уйный. Ул географик шартлар нигезендә халыкларның характерын, йолаларын һәм гореф-гадәтләрен, алардагы хуҗалык һәм сәяси строен китереп чыгарырга тырыша. Законлылыкны тәэмин итү чарасы итеп ул *хакимиятләрне бүлү принцибын* саный. Аның төп әсәрләре — «Персия хатлары» (1721) һәм «Законнар рухы турында» (1748). Сәяси төзелешнең дәүләтнең үзенчәлекләренә, аның зурлыгына, халык белән тулылыгына, климатка, географик мохиткә, халык тоткан диngә һәм аның характерына бәйлелеген күзәтеп, Монтескьё фәнгә табигый-фәнни алым кертә.

Монтескьё хәзерге география мәктәбенә нигез салучыларның берсе була (немец географы һәм этнографы, сәяси географияне башлап җибәрүче ***Фридрих Ратцель*** (1844–1904) да шул мәктәпкә керә). Табигый шартларның төрле географик зоналардагы халыкларның үсешенә һәм мәдәниятенә йогынтысын өйрәнеп, ул кешелек дөньясы мәдәни тормышының үзенчәлекле географик картасын эшли. Үз хезмәтләрендә галим халыклар таралып урнашуның һәм мәдәниятләр таралуның гомуми картасын бирә. Җир өслеге

буйлап төрле тизлектә кешеләр ташкыннары гына түгел, ә мәдәни уйлап табулар, предметлар, идеяләр, күренешләр дә күчеп йөри. Сәясәт һәм география арасында тыгыз бәйләнеш урнаштыру — галимнең уңышлы ачышы. Дәүләтнең көче күп яктан аның территориясенә һәм географик хәленә бәйле, шунлыктан, үз куәтен арттырып, дәүләт тормыш итү киңлеген киңәйтергә омтылырга тиеш, дип исәпли ул.

Социаль фәннәр барлыкка килүгә XVIII йөздә җәмгыятьтә булган тамырдан үзгәрешләр зур йогынты ясый: Америкадагы революция, Бөек француз революциясе һәм Англиядәге индустриаль революция кешелек дөньясының шуннан соңгы үсешендә Көнбатыш цивилизациясенең төп ролен билгелиләр. Европада иске монархияләр җимерелә башлый, Төньяк Америкада демократик хөкүмәтләр барлыкка килә. Дөньяның яңа индустриаль башкалаларында эшчеләр сыйныфы тиз арта бара. Планетада халык саны берничә тапкыр арта. Шәһәрләрнең үсүе Европаның йөзен үзгәртә. Индустриаль революция технологик сикереш һәм машиналар индустриясе үсешен китереп чыгара. Гасырлар дәвамында авыл тормышының хәрәкәтсез нигезендә ята торган социаль элемтәләр җимерелә. Яңа шәһәрләрдә авылларда гомергә дә булмаган нәрсәләр: ярлы һәм хәерче кешеләрнең күплеге, тулы булмаган гаиләләр, интектергеч балалар хезмәте, ялгыз өлкән кешеләр барлыкка килә. Бу проблемалар турында, заманча яшәү рәвешенең характерлы сыйфатлары буларак, хәтта XX йөздә дә яздылар.

Социаль тормыш динамизмы социаль фәннәрнең философиядән котылуына уңай йогынты ясый. Социаль белемнең азатлыгында икенче бер шарт — табигать фәннәренең, беренче чиратта кешеләрнең фикерләү рәвешен үзгәртә торган физиканың үсүе була. Әгәр матди дөнья тәгәл үлчәү һәм анализлау предметы була ала икән, ә ни өчен социаль дөнья шундый булмаска тиеш? Бу сорауга беренче булып француз философы ***Огюст Конт*** (1798–1857) җавап бирергә тырыша. Үзенең «Позитив философия курсы»нда (1830–1842) ул «җәмгыять турында фән» барлыкка килүен билгеләп, аны *социология* дип атый.

Конт фикеренчә, җәмгыять турындагы фән табигать турындагы фәннәр белән бер рәттә торырга тиеш. Ул вакыт-

та аның карашларын әхлакта һәм закон актларында кешеләрнең үзләрен тотышлары белән идарә итү сәнгатен күрүче инглиз философы һәм юристы *Иеремия Бентам* (1748–1832), гомуми эволюция турындагы механистик тәгълиматны үстерүче инглиз философы һәм социологы *Герберт Спенсер* (1820–1903), сыйныфлар һәм социаль конфликт теориясенә нигез салучы немец философы һәм икътисадчысы *Карл Маркс* (1818–1883), индуктив логика һәм сәяси икътисад буенча фундаменталь хезмәтләр язган инглиз философы һәм икътисадчысы *Джон Стюарт Милль* (1806–1873) уртаклашалар. Алар бердәм җәмгыятьне бердәм фән өйрәнергә тиеш, дип исәпли.

XIX гасыр ахырында җәмгыятьне тикшерү турындагы фән күпләгән дисциплиналарга аерыла. Беренче булып *икътисад* аерылып чыга. Гәрчә «икътисад» атамасы әле 1790 елда ук кулланылса да, әлеге фән предметы XIX гасыр ахырына кадәр сәяси икътисад дип йөртелә. Классик икътисадка нигез салучы *Адам Смит* була. Үзенең «Халыклар байлыгының табигате һәм сәбәпләре» (1776) дигән хезмәтендә бәя һәм табышны бүлү теориясен, капитал һәм аның тупланауын, Көнбатыш Европаның икътисади тарихын, икътисади сәясәткә карашларны, дәүләтнең финансларын тикшерә. Смит икътисадны танып-белергә мөмкин булган объектив законнар эш иткән система дип исәпли. Бәянең хезмәт теориясен тудыручыларның берсе — инглиз *Давид Рикардоны* да (1772–1823) икътисади фикер классикларына кертәләр. Ул бердәнбер чыганагы эшче хезмәте булган товар бәясе җәмгыятьтәге төрле сыйныфлар керемнәренең нигезендә ята, дип исәпли.

Икътисад белән бергә башка фәннәр дә белемнең мөстәкыйль өлкәләре булып аерылып чыга. Сәяси фәнне яки *политология*не иҗат итүчеләргә итальян сәяси фикер иясе *Никколо Макиавеллины* (1469–1527) кертәләр. Аның төп әсәре «Государь» — Платонның «Дәүләт» хезмәтендәге фикер йөртүләрнең төп юнәлешен дәвам иттерә кебек, ләкин акцент җәмгыятьнең структурасына түгел, ә сәяси лидерның үзен тотышына ясалган. Ул, беренче булып, дәүләтсәясәт мәсьәләләрен дин һәм әхлак йогынтысы өлкәсеннән чыгара. Нидерландия юристы һәм дәүләт эшлеклесе, табигый хокук һәм хәзерге заман халыкара хокук фәне («Су-

гыш һәм тынычлык законнары турында» трактат) теориясенә нигез салучыларның берсе ***Гуго Гроцийны*** (1583–1645) һәм «Америкадагы демократия турында» (1835) дигән классик сәяси трактат авторы, француз тарихчысы ***Алексис де Токвильне*** (1805–1859) дә политологияне нигезләүчеләргә кертәләр.

Мәдәни антропология (соңыннан аннан кешелек мәдәниятенең асылын фәлсәфи аңлау максатын куйган тагын да гомумирәк *культурология* барлыкка килә) европалыларның Яңа Дөньяны ачуы нәтиҗәсе була. Америка индеецларының таныш булмаган кабиләләре үзләренең гореф-гадәтләре һәм яшәү рәвешләре белән хыял-фаразларны күмеп китә. Шуннан соң галимнәр игътибарын Африка, Океания һәм Азиянең кыргый кабиләләре җәлеп итә. Сүзгә сүз «кеше турындагы фән»не аңлаткан антропологияне беренче чиратта примитив яки язу барлыкка килгәнчегә кадәрге җәмгыятьләр кызыксындыра. Мәдәни антропология кешелек җәмгыятьләрен чагыштырмача өйрәнү белән шөгыльләнә. Европада әле аны тагын *этнография* һәм *этнология* дип атыйлар.

XIX гасырның даһи этнографлары арасында — диннең килеп чыгышының анимистик теориясен эшләгән, иң борынгы мәдәниятне тикшеренүче инглиз ***Эдуард Бернетт Тайлор*** (1832–1917); «Борынгы җәмгыять» китабында (1877) ыругның иң борынгы җәмгыятьнең төп ячейкасы буларак әһәмиятен беренче булып күрсәткән Америка тарихчысы ***Льюис Генри Морган*** (1818–1881); бөтен дөньяга билгеле «Алтын ботак» китабының (1907–1915) авторы инглиз дин тарихчысы ***Джеймс Джордж Фрезер*** (1854–1941). Аларның тикшеренүләре, шулай ук философлар, сәнгать белгечләре һәм социологларның өйрәтүләре нигезендә акрынлап *культурология* формалаша.

**КУЛЬТУРОЛОГИЯ** — кеше һәм җәмгыять турындагы социаль һәм гуманитар белемнәр чатында формалашкан һәм мәдәниятне бербөтен буларак өйрәнә торган фән. Аның предметы — гомумкешелек һәм милли мәдәни процессларның объектив канунчалыклары, кешеләрнең матди һәм рухи тормышындагы истәлекләр, күренешләр һәм вакыйгалар.

Шулай итеп, без иҗтимагый фикер тарихына зур булмаган сәяхәт кылдык һәм фәннең бүгенге этабы бусагасы янында ук туктап калдык.

---

**Төшенчәләр:** *иҗтимагый фәннәр, икътисад, политология, культурология, психология.*

---

**Сораулар һәм биремнәр**

**1.** Җәмгыять турындагы фәннәр үсешенең төп этапларын атагыз.

**2.** Социаль фәннәрне үстерү белән кайсы галимнәр шөгыльләнгән?

***3.** Антик җәмгыятьнең структурасын характерлап, Платон сыйныфны аерып күрсәткән (аларны исегезгә төшерегез). Сез Россия җәмгыятендәге нинди сыйныфларны аерып күрсәтә аласыз? Аларны тасвирлагыз.

***4.** Аристотель һәм Платон заманнарында югары сыйныфка бик тә зур өстенлекләр бирелгән, ул даими рәвештә үз хакимиятеннән явызларча файдаланган. Сезнең карашка, ике мең ярым ел үткәннән соң кешелек җәмгыяте үсеше закончалыкларында нәрсә дә булса үзгәрдеме?

***5.** Шәхси милек турындагы мәсьәлә социаль фикер тарихында күп тапкырлар күтәрелә. Күпләгән фикер ияләре шәхси милекне тигезсезлек һәм социаль явызлык чыганагы дип саный һәм аны бетерергә тәкъдим итә. Бу мәсьәлә буенча сез ничек уйлыйсыз? Шәхси милекне иҗтимагый милеккә алыштырудан кешеләр арасындагы үзара мөнәсәбәтләр яхшырамы? Үз позициягезне дәлилләгез.

***6.** Чит илләрдә укучылар мәдәни антропология белән теориядә генә түгел, практикада да эш итә. Мисалга, Американың Филадельфия штаты укучылары этнографик заповедникларда һәм паркларда, аерым алганда, Фармаунт Паркта булалар, аларда ерак илләрдә яшәүчеләрнең яшәү рәвешләре һәм традицияләре белән таныша. Дәресләрдә алар биремнәр башкаралар, мәсәлән, үз куллары белән Африка маскалары ясыйлар, бу исә дөньяның төрле почмакларында яшәүче төрле халыклар турында сөйләүче мәдәни антропология буенча уку

программасының бер өлеше булып тора. Үзегезнең башка мәдәниятләр белән ничек танышуыгыз турында сөйләгез.

**? Проблема.** Җәмгыять турындагы фәнне кешелек дөньясы ирешкән барлык фәннәрнең иң югары ноктасы дип буламы?

**Практикум 1.** Сул баганадагы һәр фән өчен уң якта тора торган билгеләмәне сайлап алыгыз. Исегездә тотыгыз: фәннең билгеләмәсе әлеге дисциплина нәрсәне өйрәнә дигән сорауга җавап бирә.

*Таблица*

| | |
|---|---|
| 1. ПСИХОЛОГИЯ | а) халык урнашуы, туу һәм үлү процессларын, миграцияне, гомер озынлыгын |
| 2. СОЦИОЛОГИЯ | б) дөнья халыкларының көнкүреш һәм мәдәният үзенчәлекләрен, аларның килеп чыгуы, таралып урнашулары һәм үзара мөнәсәбәтләре проблемасын |
| 3. ИКЪТИСАД | в) кешенең килеп чыгуын һәм эволюциясен, кешеләр расалары барлыкка килүен, кешенең нормаль төзелешенең нормаль вариацияләрен |
| 4. ДЕМОГРАФИЯ | г) кешелек дөньясының үткәнен конкрет вакыйгалар һәм фактлар куптәрлелегендә, җәмгыять үсешенең закончалыкларын |
| 5. ЭТНОГРАФИЯ | д) хайваннарның һәм кешеләрнең үзләрен тотышларын, кабул итү, фикерләү, тану, истә калдыру процессларын |
| 6. АНТРОПОЛОГИЯ | е) хакимлек итү һәм буйсыну мөнәсәбәтләрен, дәүләт төзелешен һәм хакимият институтларын, идарә итү режимнарын |
| 7. ТАРИХ | ж) социаль төркемнәрнең үзара тәэсир итешүен, социаль институтларның эшләвен, җәмгыятьнең социаль структурасын |
| 8. ПОЛИТОЛОГИЯ | з) җитештерү, алмашуны, товар һәм хезмәт күрсәтүләрне бүлү һәм куллануны, базар мөнәсәбәтләре системасын |

**Практикум 2.** Дәреслекнең тиешле бүлекләре һәм параграфларыннан файдаланып, түбәндә китерелгән җөмләне тәмамларга тырышыгыз:

Җәмгыять белеме буенча беренче хезмәт дип...

Ш. Монтескьё түбәндәгеләргә нигез салучыларның берсе була: ...

Индустриаль революция ... китереп чыгара.

Социаль тормыш динамизмы социаль фәннәрне ... дән коткару өчен уңай шартлар тудыра.

Сүзгә сүз «кеше турындагы фән» дигәнне аңлата торган антропологияне иң беренче чиратта ... кызыксындыра.

Культурология һәм философиядә цивилизацияне ... буларак аңлау күбрәк таралу ала.

## § 3. Җәмгыятьнең төзелеше

8 нче һәм 9 нчы сыйныфлар өчен җәмгыять белеме курсында без кыскача гына бүгенге җәмгыятьнең асылын һәм структурасын карадык. Хәзер инде җәмгыятьне өйрәнүгә ике караштан — фәлсәфи һәм социологик яктан якын килик.

***Киң фәлсәфи мәгънәдә җәмгыять дип кешеләрнең тарихи урнашкан уртак эшчәнлеге формасының теләсә кайсы бергәлеген атыйлар.*** Җәмгыятьне әле тагын икенче табигать дип тә атыйлар, шуның белән ул табигый табигатьтән читтә тора, аның логик дәвамы буларак бар-



лыкка килә алмый һәм аның законнары буенча эш итәргә сәләтсез, дип басым ясап күрсәтәләр.

Бу карашка каршы торучылар да бар. Алар кешеләр җәмгыяте хайваннарның биологик бергәлегенең турыдан-туры дәвамы булып тора һәм җәмгыятьтә хайваннар дөньясында булмаган бер нәрсә дә юк, дип раслыйлар. Мәсәлән, кырмыска оясы кешелек җәмгыятенең камил аналогы булып тора: ул шулай ук катлаулы оештырылган, анда хезмәт бүленеше һәм махсуслашу, кырмыскалар «сөйләшә торган» үз телләре бар һ.б. Шунлыктан алар кырмыскаларны уртак тормыш алып бара торган, күпләгән башка тере затлар кебек үк социаль хайваннар дип атыйлар.

Чынлап та, фән кырмыскаларны гаилә корырга сәләтле, берничә кастадан торган иҗтимагый бөҗәкләргә кертә. Кырмыскаларның бер төрләре җир өсте шәһәрләре — бүгенге шәһәр-мегаполисларны хәтерләтүче кырмыска оялары төзи, ә икенчеләре борынгы бабаларыбызны — әзер ризыклар җыючы һәм аучыларны хәтерләтүче сукбайларча яшәү рәвеше алып бара. Кешелек җәмгыятен кырмыска оясы рәвешендә күз алдына китерү бик тә кызыктыра.

Шуңа да карамастан, тышкы охшашлык еш кына ялгыш була. Кешелек җәмгыяте табигатьнең органик өлешенең түгел, ә аның эволюциясе нәтиҗәсе булып тора. Кырмыскалар 65 млн ел яшиләр һәм 10 мең төрнең берсе дә бу вакыт эчендә практик яктан үзгәрмәгән. Кеше бары тик 2 млн ел гына яши, ә шул кыска гына вакыт эчендә сыйфат үзгәрешләре кичергән. Эш нәрсәдә соң?

Барлык бөҗәкләр (кырмыскалар, бал кортлары яки гусеницалар) индивид буларак түгел, ә ыруг буларак эволюцияләшә. Хайваннарда, ә кеше үзенең биологик табигате буенча аларга керә, безгә инглиз галиме, табигать белгече ***Чарлз Дарвин*** тасвирламалары буенча таныш булган *индивидуаль сайланыш*, ә бөҗәкләрдә коллектив сайланыш эш итә: аерым затлар түгел, ә бөтен популяция камилләшә. Менә шуның өчен дә бөҗәкләрнең берләшмәләрен *биологик югары организмнар* дип атыйлар. Барлык затлар, бер тип организмы кебек генетик программалаштырыла.

Югары организм машинага охшаган. Хайваннар һәм кешеләр биологик яктан универсаль, алар чиратлап төрле вазыйфалар (азык табу, үрчү, төзү, саклану һ.б.) башкара

ала. Шуның өстенә алар бер җенеслеләр. Ә кырмыскалар һәм бал кортлары биологик махсуслаштырылганнар, күпчелеге җенессез. Бер затлар фәкать үрчүгә генә сәләтле, башкалары азык таба алалар, әмма яңадан җитештерү сәләтеннән мәхрүмнәр.

Бөҗәкләрдә өйрәнүгә — минималь, ә кешеләрдә максималь сәләт. Кешеләрнең үзләрен тотышының 80%ы социаль үзләштерелгән, ә 20% — биологик тумыштан. Өйрәнүгә сәләт югарырак булган саен, индивидуаль үсеш дәрәҗәсе дә шулкадәр югарырак. Барлык бөҗәкләр берберсенә охшаш. Әмма моны хайваннар турында әйтү читен, ә кешеләр турында инде бөтенләй дә мөмкин түгел. Фәкать кешеләр генә җәмгыять — индивидларның уртак эшчәнлегенең югары оешкан формасын булдырган. Димәк, үсешнең индивидуаль дәрәҗәсе һәм иҗтимагый дәрәҗәсе бер-берсе белән тыгыз бәйләнгән: индивид бай булган саен, җәмгыять шулкадәр катлаулырак. Кырмыскаларга һәм бал кортларына кагыла торган «социаль хайваннар» дигән сүз катгый фәнни төшенчәгә караганда күбрәк метафора булып кала. Хезмәт бүленеше турында да шуны ук әйтергә була.

*Җәмгыятьне төрле позицияләрдән карап була. Аны аңа керүче барлык төркемнәр җыелмасы дип карарга мөмкин һәм ул чакта без барыннан да элек халык белән эш итәчәкбез.*

*Җәмгыятьнең төп кучәрен социаль иерархия тәшкил итә, анда кешеләр байлык һәм хакимлек күләме критерие буенча урын алган дип карарга була.* Югарыда — бай һәм бөтен хакимиятне кулга алган элита, аннары — урта сыйныф, ә түбәндә җәмгыятьнең ярлы һәм хокуксыз күпчелеге (яки азчылыгы) булачак.

*Җәмгыятьне биш фундаменталь инструмент: гаилә, производство, дәүләт, мәгариф (мәдәният һәм фән) һәм дин бергәлеге дияргә мөмкин.* Кайчак соңгы икесен берләштерәләр. Аталган институтлар җәмгыятьнең калганнарын тотып тора торган баганалары вазыйфасын башкаралар.

*Ниһаять, җәмгыятьне төп дүрт — икътисади, сәяси, социаль һәм мәдәни өлкәләргә бүләргә мөмкин.*

Аларны яссылыкта барысы да үзара тигез, ягъни бер үк горизонталь дәрәҗәдә булырлык итеп урнаштырырга мөмкин. Ләкин аларның һәрберсе өчен җәмгыятьтә баш-



Җәмгыятьнең вертикаль структурасы

каларныкына охшаш булмаган үз функциясен һәм ролен билгеләп, вертикаль урнаштырырга да мөмкин.

Шулай итеп, *икътисад* яшәү өчен средстволар табу вазыйфасын башкара һәм җәмгыятьнең фундаменты була. *Сәяси өлкә* һәрвакыт җәмгыятьнең идарә итү өскормасы ролен үтәде, ә халыкның социаль-демографик һәм профессиональ составы, халыкның зур төркемнәр арасындагы үзара мөнәсәбәтләр белән шөгыльләнүче *социаль өлкә* җәмгыятенең бөтен пирамидасы аша үтеп чыга. *Рухи* өлкә дә шундый ук универсаль, үтәли характерда. Ул җәмгыятьнең барлык катларына кагыла. Дөньяның яңа картинасын график сурәтләп була (27 битне кара).

Дүрт өлкәгә туры китереп, җәмгыятьнең дүрт институтын аерып күрсәтәләр.

**«Институт»** атамасының күпләгән мәгънәсе бар. Европа телләренә ул латиннан килгән: institutum — билгеләү, урнашу. Вакытлар үтү белән ул ике әһәмият ала: тар техник (махсуслашкан фәнни һәм уку йортлары исемнәре) һәм киң социаль-иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең билгеле бер даирәсе буенча, мәсәлән, никах институты, мирас калдыру институты, хокук нормалары җыелмасы.

Әлеге төшенчәне хокук белгечләреннән алып, социологлар аңа яңа эчтәлек бирделәр. Социаль институтларны

иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең билгеле бер өлкәсен (гаилә, производство, дәүләт, мәгариф, дин) җайга сала торган норма һәм механизмнар җыелмасы буларак аңлап, безнең алар турындагы күзаллауларыбызны тирәнәйттеләр.

Аларның бурычы — җәмгыятьнең бик тә мөһим (фундаменталь) тормыш ихтыяҗларын канәгатьләндерү. Төп социаль институтлар кебек үк, алар барлыгы дүртәү генә:

***— кешеләрне арттырып торуга ихтыяҗлар (гаилә һәм никах институты);***

***— яшәү средстволары табу ихтыяҗлары (икътисад институтлары, җитештерү);***

***— иминлеккә һәм социаль тәртипкә ихтыяҗлар (сәяси институтлар, дәүләт);***

***— рухи проблемаларны хәл итү, яңа белемнәр үзләштерү һәм тапшыру, яшь буынны тәрбияләү ихтыяҗлары (киң мәгънәдә рухи институтлар, ягъни фәнне һәм мәдәниятне дә кертеп).***

Йомгаклау ясыйк: *социаль институт — җәмгыятьнең үзенең иң мөһим ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен оештырылган һәм социаль нормалар җыелмасы белән җайга салына торган төзелеше.*

Институтлар аркасында кешеләр *социальләшә* (мәдәни нормаларны үзләштерү һәм социаль рольләрне үзләштерү), яңа буыннар *туа* (гаилә институты), яшәү средстволары *табыла, тәртип урнаштырыла* һәм *рухи* йолалар үткәрелә.

Институтлар бик борынгы заманнарда барлыкка килә. Башлангыч ноктасы итеп кеше тудырган беренче эш коралын алсак, **җитештерүгә** 2 млн ел туры килә. Антропологлар **гаиләгә** икенче урын бирәләр һәм түбән чик 500 мең ел билгесе белән үтә, дип уйлыйлар. Шуннан бирле ул күпләгән: полигамия, полиандрия, моногамия, уртак яшәү, нуклеар, киңәйтелгән, тулы булмаган һ.б. формалар һәм төрләр кабул итеп, эволюция үтә. **Дәүләт** якынча мәгариф яшендә, дөресрәге 5–6 мең ел. Әгәр беренчесе белән шактый ачык һәм бер-ике мең елга гына ялгышып булса, мәгариф белән эш катлаулырак тора.

Хәзерге вакытта **мәгариф** социаль институты мәктәпләр, техникум, вуз, академия төрле курслар һ.б. плюс Мәгариф министрлыгы һәм аның бөтен аппараты, фәнни-тикшеренү институтлары, нәшриятлар, газета һәм журналлар редак-

цияләре, типографияләр һәм педагогика белән бәйле башка күп нәрсәләр җыелмасыннан гыйбарәт.

Галимнәр *буыннан-буынга тапшырыла, килеп туган хәлләргә бәйле рәвештә үзгәрә һәм аларга яраклашу коралы булып хезмәт итә торган иҗтимагый гореф-гадәтләр җыелмасы, билгеле бер үз-үзеңне тоту гадәтләре, фикерләр һәм яшәү рәвеше гәүдәләнеше буларак, социаль институтка* икенче билгеләмә бирәләр.

Шул рәвешле, «социаль институт» төшенчәсе абстракция генә түгел. Ул әлеге өлкәдә хезмәт итүче реаль кешеләр биргәлеген, шулай ук конкрет законнар, идарә итү карарлары һәм практик чаралар системасын белдерә. Алар күренеп торган объектлар — әлеге институтның эшләве матдиләшә торган биналар, күпер, завод, персоналлар, торак квартиралар, җиһазлар. Мисалга, гаилә институтына дәүләт булышлыгы балалар пособиеләрендә, балалар бакчалары, мәктәпләр, хастаханәләр төзүдә һ.б. да гәүдәләнә.

*Таблица*

**Җәмгыятьнең төп институтларының вазыйфалары һәм структур элементлары**

| Вазыйфалар | Институтлар | Төп рольләр | Физик сыйфатлары | Символик сыйфатлары |
|---|---|---|---|---|
| балалар турында кайгырту, тәрбияләү | гаилә-никах | ата, ана, бала | йорт, аның торышы | балдаклар, никахлашу, контракт |
| азык, кием, торак табу | икътисади | эш бирүче, ялланган хезмәткәр, сатып алучы, сатучы | предприятие, офис, кибет | акча, сәүдә, марка, реклама |
| законнарны, тәртипләрне һәм стандартларны яклау | сәяси | закон чыгаручы, хокук субъекты | иҗтимагый биналар һәм урыннар | флаг, кодекс, хартия |
| дини мөнәсәбәтләргә һәм күрсәтмәләргә булышу, динне тирәнәйтү | дини | поп, яки мулла, дин тотучы | чиркәү яки мәчет, яки синагога | Тәүрат яки Коръән |
| кешеләрне социальләштерү, базис кыйммәтләренә һәм гамәлләренә тарту | мәгариф | укытучы, укучы | мәктәп, көллият, дәреслек | диплом, дәрәҗә |

**СОЦИАЛЬ ИНСТИТУТЛАР** — нормалар, традицияләр, гореф-гадәтләр белән җайга салына торган һәм җәмгыятьнең фундаменталь ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә юнәлдерелгән уртак эшчәнлекне оештыруның тарихи урнашкан, тотрыклы формалары.

---

**Төшенчәләр:** *җәмгыять, социаль институт, икътисади өлкә, сәяси өлкә, социаль өлкә, мәдәни өлкә.*

---

## Сораулар һәм биремнәр

**1.** Җәмгыятьнең бер-ике социаль институтының, әйтик, мәгариф һәм гаиләнекенең, кыскача тасвирламасын төзегез. Һәркем куллана ала торган әдәбияттан файдаланып, аларның тарихи эволюциясен, вазыйфаларын, аларга керә торган социаль оешмаларны, шулай ук традицияләрне, гореф-гадәтләрне, статусларны һәм рольләрне характерлагыз.

***2.** Түбәндәге фикер йөртүне сез ничек аңлатыр идегез: «Россия дип аталган безнең җәмгыять хәзер яшәүче барлык кешеләр җыелмасы түгел. Аларга әлеге территориядә элек яшәгән барлык кешеләрне һәм бирегә 100 елдан соң һәм 1000 елдан соң яшәячәкләрне дә өстәргә кирәк».
Сез моның белән килешәсезме? Җавабыгызны дәлилләгез.

**3.** Уртак яшәү рәвеше алып баручы тере затларны галимнәр социаль хайваннар дип атый. Аларга арыслан, сыер, чыпчык һәм шакалларны кертеп буламы? Алар да бит коллектив яшәү рәвеше алып бара. Ә бәлки, аларга, бал кортлары кебек үк социаль хайваннар рәтенә ныклап керү өчен нәрсә дә булса җитмидер?

**4.** Индивидуаль һәм коллектив сайланышлар үзара нәрсә белән аерыла? Ни өчен берсе җәмгыять барлыкка китерүгә сәләтле, ә икенчесе — юк. Кеше ыругында һәрвакыт кумәк сайланыш кына булса, бүгенге кешеләр нинди булырлар иде?

***5.** Ничек уйлыйсыз, ни өчен социаль институт буларак җитештерүгә 2 млн ел, гаиләгә бары тик 500 мең ел, ә дәүләткә фәкать 5–6 мең ел? Соңрак барлыкка килгән элек барлыкка килгәннәрдән катлаулыракмы? Бәлки,

болай да буладыр: катлаулырагы нәкъ менә катлаулырак булганы өчен соңрак барлыкка киләдер? Ул чакта сез, дәүләт җитештерүдән катлаулырак дип исәпли аласызмы? Әллә алар катлаулылыклары буенча тигез бөек социаль институтлармы? Ул чакта ни өчен берсенә үзенең формалашуы өчен — миллион, ә икенчесенә мең еллар кирәк булган?

6. Әгәр институт дигәндә закон яки учреждение рәвешендә гореф-гадәтләрне һәм тәртипләрне ныгытуны аңласак, чукындыруны, адвокатура, хезмәт базары, парламент, никахлашу, ана булуны, биржаны социаль институтларга кертеп буламы?

7. Җәмгыятьнең төп институтларын санагыз. Алар нинди вазыйфалар башкара?

## § 4. Цивилизация һәм җәмгыять

Галимнәр парадоксаль закончалыкны искәрделәр: кешелек җәмгыятьләренең барысы да үз тарихларын бер үк баскычтан — борынгы община строеннан башлаган. Дистәләрчә мең ел элек аларга якынча бер үк типтагы социаль структура, хезмәт эшчәнлеге алымнары, дин тоту, көнкүреш һәм рухи мәдәният хас була. Бүген исә социаль структураларның, сәяси системалар, икътисади үсеш, рухи һәм нәфис мәдәниятләрнең бихисап күп төрле типлары һәм дәрәҗәләре яши. Димәк, тарихи юлдан барлык җәмгыятьләр дә бер үк тизлектә түгел, берәүләр — акрынрак, икенчеләре тизрәк барган. Кешелек җәмгыятләре үсешенең тигез бармавы нинди дә булса бердәнбер: географик, икътисади яки рухи факторның йогынтысы икәнен фән һич тә аңлата алмый.

Шул чакта аңа ярдәмгә үсешнең барлык якларын һәм сәбәпләрен колачлаган «цивилизация» төшенчәсе килә. Өстәвенә аерым-аерым, һәрберсе үзе генә булып түгел, ә тыгыз һәм гаҗәеп дәрәҗәдә гармонияле бердәмлектә. Нәрсә соң ул цивилизация һәм бу сүз каян килеп чыккан?

«Цивилизация» сүзе (лат. civilis — гражданлы, дәүләти) XVIII гасыр уртасында Франциядә барлыкка килә. Урта гасырларда суд практикасына кагылышлы юридик мәгънәгә ия була, социаль күрсәтмәләр, хокуклар һәм ирекләргә,

шулай ук характерларның йомшаклыгына һәм аралашудагы әдәплелеккә туры килә. Шулай аңлана торган цивилизация кеше яшәешендәге матди шартларның уңайлылыгын аңлата. Озак вакытлар мәдәниятне һәм цивилизацияне тәңгәлләштерәләр, ләкин XIX гасырда аларны аералар. Ә XX йөз башында немец философы *Освальд Шпенглер* (1880–1936) үзенең «Европаның кояшы бату» дигән хезмәтендә аларны бөтенләй дә капма-каршы куя. Цивилизацияне ул мәдәниятнең югары стадиясе дип атый, мәдәният анда тәмам юкка чыга. Мәдәният ул — үзенең өлгергәнлегенә җитмәгән һәм үз үсешен тәэмин итмәгән цивилизация.

Бүгенге фәндә цивилизациянең асылына бердәм караш урнашмады, шунлыктан әдәбиятта аның 100 дән артык билгеләмәсе бар.

*Галимнәрнең берләре әлеге билгеләмәне тарихи чорларга караталар һәм антик, урта гасырлар һәм бүгенге цивилизацияләр турында сөйлиләр.*

*Башкалары локаль, региональ һәм глобаль цивилизацияне, мәсәлән, Атлантик, Тын океан, Көнчыгыш, Көнбатыш цивилизацияләрен күздә тотып, аны географик урын белән бәйли.* Алар икътисади укладны һәм мәдәниятне, яшәү, гаделлек, язмыш мәгънәсен, хезмәтнең һәм ялның ролен аңлау белән аерылалар.

*Өченчеләр дини һәм социомәдәни критерийларга таяна һәм Евразия, Мөселман, Христиан, Европа һәм башка цивилизацияләрне анализлый.*

*Дүртенчеләр цивилизацияне илнең социаль мәдәни үсеше дәрәҗәсе итеп күзаллый һәм анда кешелек дөньясының космосны буйсындыру, компьютер технологияләре һәм әлек күрелмәгән энергия чыганакларын кертү белән бәйле техник казанышлар биеклеген күрә.*

Нәтиҗәдә, цивилизация белән матди уңышлар, ә мәдәният белән кешенең рухи дөньясы тәңгәлләштерелә. Алар цивилизациянең мөһим билгеләренә халыкның укымышлылыгы дәрәҗәсен, үлем-китем (аеруча балаларда) коэффициентын, шәһәрләрнең санитар хәлен, экологияне һ.б. кертәләр.

Культурология һәм философиядә цивилизацияне яшәүнең мөстәкыйль механизмы булган социомәдәни макро яки

суперсистема буларак аңлау киңрәк таралып алды. Мондый якын килү үз башлангычын XIX гасыр рус фикер иясе ***Н. Я. Данилевскийдан*** (1822–1885) ала. «Россия һәм Европа» (1869) дигән хезмәтендә ул биологик организмнар кебек үсүче *мәдәни-тарихи типлар* (цивилизацияләр) *теориясен* тәкъдим итә. *Типларны аеруның төп критерие булып телләр якынлыгы тора, ә мәдәни-тарихи типлар үзләре психик, антропологик, социаль, территориаль һәм башка билгеләрнең кушылуы буларак аңлана.*

> **МӘДӘНИ-ТАРИХИ ТИПЛАР** — *билгеле бер территорияне биләгән һәм үзләренең, үзләренә генә хас, мәдәни һәм социаль үсеш үзенчәлекләре булган тарихи бергәлекләр ул.*

Алар төп дүрт: мәдәни, сәяси, икътисади һәм дини элементларның үзенчәлекле берләшүләре белән аерылып тора. Бер цивилизациядә — икътисади, икенчесендә — сәяси, өченчеләрендә — дини, дүртенчеләрендә мәдәни башлангычлар өстенлек итә. Данилевский фикеренчә, бары тик Россиядә генә барлык бу элементлар гармоник кушылалар, шунлыктан ул башкалардан тирән үзенчәлеклеге белән аерылып тора торган аерым тарихи тип булып тора. Н. Я. Данилевский 13 типны яки «үзенчәлекле цивилизация»не аерып күрсәтә, О. Шпенглер — 8 типны, инглиз культурологы ***Арнольд Тойнби*** (1889–1975) 6 типны аерып күрсәтә.

Бүген фәндә *ике теория* көндәшлек итә:

— *цивилизациянең стадияле үсеш теориясе;*

— *локаль цивилизацияләр теориясе.*

*Стадияле теория* цивилизацияне кешелек дөньясының прогрессив үсешен билгеле бер стадияләре (этаплары) аерылып торган бердәм процесс буларак карый. Цивилизацияләрнең *локаль теориясе* бөтендөнья тарихи процессын билгеле бер территорияне биләгән, социаль-икътисади һәм мәдәни үсешенең үз үзенчәлекләре булган тарихи урнашкан бергәлекләр җыелмасы итеп карый.

Аерымлыклары булуга карамастан, һәр ике теория якылылар тарихи процессның уртак структур берәмлеге цивилизациянең булуын таный, ул бербөтен иҗтимагый система буларак карала.

***Цивилизациянең асылын, аның кабатланмас үзенчәлеген билгели торган факторларга галимнәр түбәндәгеләрне кертә:***

— ***географик*** (яисә табигый) мохит;

— ***хуҗалык итү системасы*** (икътисад);

— ***социаль оешу*** (җәмгыять тибы, социаль структура);

— ***дин*** (яисә дин дәрәҗәсенә күтәрелгән идеология);

— ***рухи кыйммәтләр;***

— ***сәяси-хокукый система.***

Шулай итеп, ***бүгенге фән цивилизацияне***, берьяклы карашлардан баш тартып, ***комплекслы аңлый***. Мондый очракта «цивилизация» атамасы «җәмгыять» төшенчәсеннән киңрәк.

*Цивилизациянең ике — фәнни-техник һәм социаль-хокукый ягы бар.* Цивилизациянең үсеш критерие — кешенең табигать көчләре өстеннән акыллы идарә итүе дәрәҗәсе һәм шәхеснең хокукларын һәм ирекләрен тәэмин итә торган социаль-хокукый өлкәләрнең (шул исәптән хокукый дәүләтнең булуы) үсеше.

Цивилизация билгеләренең җыелмасын тасвирлап, культурологлар аның төп һәм җыелма сыйфаты буларак менталитетны нык аерып күрсәтәләр. Бу төшенчә төрле иҗтимагый фәннәр: политология, психология, социология, философия тарафыннан кулланыла.

> **МЕНТАЛИТЕТ** (соңгы лат. mentalis —аңлы) — индивидка яки төркемгә хас фикерләү, дөньяны кабул итү, рухи халәт рәвеше.

Философия һәм культурологиядә ул, гадәттә, халыкларның милли үзенчәлекләрен, мәдәниятнең аерылып торган сыйфатларын тасвирлау өчен кулланыла. Мәсәлән, рус менталитеты сыйфатлары — рухилык, коллективизм, күңел киңлеге. Менталитет кешенең һәм халыкның дөньяны кабул итүен, шәхеснең субъектив дөньясын барлыкка китерә торган кыйммәтләр һәм идеаллар характерын билгели.

*Цивилизация ниндидер хәрәкәтсез бер нәрсә түгел. Ул үсә: туу, чәчәк ату, таркалу һәм үсү стадияләре үтә.* Тарих дәвамында кабатланмас йөзе һәм якты сыйфатлары булган күпләгән цивилизацияләр яшәгән һәм яши. Берләре җимерелгән яки аларны җимергәннәр, икенчеләре, элгәре



мирасны үзләштереп, аларның җимерекләрендә барлыкка килгән.

*Цивилизациянең яшәү дәвамлыгы нинди?* А. Тойнби һәм О. Шпенглер фикеренчә, цивилизациянең барлыкка килүдән алып бетүгә кадәр үсү циклы якынча 1 мең ел тәшкил итә. Рус галиме ***Л. Н. Гумилев*** (1912–1992) башка — 1,5 мең ел дигән карашта тора. 1848 елда Бельгия статисты А. Кетле, математика алымнары кулланып, цивилизациянең уртача яшәү озынлыгы борынгы империяләр мисалында 1461 ел, плюс-минус 185 ел, дигән нәтиҗәгә килә.

Тарихи фактларны анализлау күрсәткәнчә, борынгы Мисыр цивилизациясе 3 мең елдан артык яшәгән һәм б.э.к. 332 елда Александр Македонский гаскәрләре һөҗүме астында җимерелгән. Дүрт мең елдан артык яшәгән конфуциан кытай цивилизациясе дөньяда күп еллар лидер була, барлык дөньякүләм үсешкә гаять зур йогынты ясаган һәм ясый. Тамырлары белән б.э.к. 2–3 меңьеллыкларга тоташкан, бүгенгә кадәр яшәгән һинд-будда цивилизациясе борынгылардан санала. Күпләгән илләр һәм халыклар әлеге куәтле цивилизацияләр йогынтысы астында була. Византия цивилизациясе мәдәният дөньясында мең ел (395 елдан 1453 елга кадәр) хакимлек итә. Россия дә үзенчәлекле мәдәни-тарихи тип буларак шуның кадәр яши. Гарәп цивилизациясе б.э. VI гасырында урнаша башлый һәм үз йогынтысын бүгенгә кадәр саклый. Көнбатыш цивилизациясе тамырлары белән IV гасырга (халыкларның бөек

күчеш чоры) барып тоташа һәм инде VIII–IX гасырларга үзенең беренче чәчәк атуына ирешә («Каролинг Яңарышы»).

Тарихи фактлар алда аталган барлык цивилизацияләрнең инде җир эшкәртүчелек (игенчелек) таралганнан һәм язу барлыкка килгәннән соң барлыкка килүләрен дәлилли. Чынлап та, алар — кешелек цивилизациясе барлыкка килү юлында ике зур тарихи дәвер. 10–12 мең ел элек игенчелекнең барлыкка килүе социаль һәм мәдәни үсештә зур үзгәрешләр белән билгеләп үтелә. Шәһәрләр, хосусый милек, акча, ялланган армия, эре империяләр, идарә итүнең катлаулы системасы һәм җәмгыять структурасы — цивилизациянең зарури билгеләре барлыкка килә. Андый билгеләр арасында диннең тууын да әйтеп үтәргә кирәк.

Цивилизациягә җәмгыять үсешенең шактый югары дәрәҗәсе буларак якын килгәндә, Полинезия һәм Океаниянең примитив җәмгыятьләре аның кысаларыннан читтә тора, аларда әлегәчә иң борынгы яшәү рәвеше дәвам итә, язу, шәһәрләр һәм дәүләт юк. Үзенчәлекле парадокс килеп чыга: аларның мәдәниятләре бар, цивилизацияләре юк. (Язу булмаган урында цивилизация дә булмый.) Шулай итеп, ***җәмгыять һәм мәдәният элегрәк, ә цивилизация соңрак барлыкка килгән.*** Үзенең бөтен тарихында кешелек җәмгыяте цивилизация шартларында 2% да артык булмаган вакытын яшәгән.

Шулай итеп, үсешнең язуга кадәр стадиясендә торган халыкларны цивилизацияле дип санап булмый. Шулай да тарихчылар үз язулары булмаган скифларның үзенчәлекле цивилизацияләре турында сөйлиләр. Тупиктан чыгу өчен кайбер культурологлар неолитик цивилизацияне (б.э.к. 7–4 мең ел) яисә табигый бергәлекне мөстәкыйль типка аерып күрсәтәләр. Бу типка табигый еллык цикл кысаларында, табигать белән бергәлектә һәм гармониядә яшәүче халыкларны кертәләр. Бик ерак булмаган вакытка кадәр әлеге тип планетаның түбәндәге территорияләрендә өстенлек итә: Австралия аборигеннары, Америка индеецлары, Африканың күп кабиләләре, Себер һәм Төньяк Европаның кече халыклары. 1915 елда Көнбатыш антропологлары якынча 650 шундый җәмгыятьне саный, ул вакытта аларның күпчелеге исән була әле.

Вакытлар үткәч, цивилизация төшенчәсенә яңа мәгънәләр өстәлә. Үзен яхшы тота белгән кешене «цивиль» дип атыйлар, ә «цивильләштерү» яхшы тәрбияле һәм әдәпле, аралашучан һәм кызыксынучан итүне аңлаткан. Дөньяви җәмгыятьтә «цивильлек» — әдәплелек дигән сүз булган.

---

**Төшенчәләр:** *цивилизация, мәдәни-тарихи тип, менталитет.*

---

**Сораулар һәм биремнәр**

1. Цивилизацияләрнең төп квалификацияләрен санагыз. Һәр классификациянең критерием табыгыз.
2. Фәндә цивилизация үсешенең нинди төп теорияләре яши?
3. Цивилизацияләр яшәвенең дәвамлылыгы нинди?

*4. Цивилизациянең асылын билгели торган факторларга түбәндәгеләр кертелгән: географик (яисә табигый) мохит, хуҗалык итү системасы (икътисад), социаль оешу (җәмгыять тибы, социаль структура), дин (яисә дин дәрәҗәсенә җиткерелгән идеология), рухи кыйммәтләр, сәяси-хокукый система. Аларны анализлагыз, аларның кайсысы аның үсешенә күбрәк йогынты ясавын, кайсылары — нәтиҗә, кайсылары сәбәп ролен үтәвен ачыклагыз.

5. «Менталитет» сүзен ешрак рус милли характеры белән бәйләп кулланалар. Ничек уйлыйсыз, милли менталитет белән милли характер арасында аерма бармы?

*6. Россиянең төньягында — тундрада, туганнары Аляскада да яшәүче кече халыклар гомер итә. Сүз кем турында бара? Тугандаш ике халыкның охшашлыкларын һәм аерымлыкларын сурәтләгез. Аларны бер цивилизация тибына керүчеләр дип исәпләп буламы?

7. Бу кеше бик үк «цивиль» түгел дигәндә һич тә аның билгеле бер уклад тибын яки географик бәйлелеген күздә тотмыйлар. Алайса, бу очракта сүз нәрсә турында бара?

**? Проблема.** Төрле цивилизацияләр бер-берсенә йогынты ясыймы? «Әйе» булса, ни рәвешле?

✍ **Практикум 1.** Түбәндә китерелгән таблицага борынгы цивилизацияләрнең иң характерлы яки иң исегездә калган сыйфатларын язарга кирәк.

| Цивилизация | Характерлы сыйфатлары |
|---|---|
| Борынгы Мисыр<br>Борынгы Греция<br>Кытай<br>Борынгы Һиндстан | |

✍ **Практикум 2.** Россия менталитетын характерлый торган сыйфатларның тулырак исемлеген төзегез.

2 бүлек

# Җәмгыятьнең үсеше




## § 5. Бүгенге җәмгыять

8 һәм 9 сыйныфлар өчен җәмгыять белеме курсында ачыклавыбызча, кешелек җәмгыяте үзгәреп кенә калмый, ә үсә дә, ягъни һәр тарихи этапта фән, белемнәр, китаплар, теорияләр ярдәмендә үзенә яңаны гына түгел, ә яхшырагын да өсти тора; яңа техника тормышка элек күрелмәгән эш кораллары һәм технологияләр кертә; мәгариф тагын да классификациялерәк кадрлар әзерли һ.б.

Без кешелек җәмгыяте үсеше тарихында өч стадияне күзәттек: аучылар һәм җыеп тукланучылар, аграр һәм индустриаль; соңгысы дөньяның ныграк үскән төбәкләрендә дүртенче стадиягә — постиндустриаль җәмгыятькә күчә бара.

Кешеләр җыеп тукланучылар һәм аучылар булганда, артыгын җитештермәгәндә һәм уңышка даими шанслары булмаганда, аларның саны 10 млн нан кимрәк булган. Ун мең ел элек алар үсемлекләр үстерергә өйрәнгәннәр, азык һәм энергия алу өчен хайваннарны кулга ияләштергәннәр, шәһәрләр төзи башлаганнар, язу уйлап тапканнар. Аграр җәмгыять чорында Җирдә халык 200 млн кешедән артмаган. Ниһаять, ике йөз ел элек кешеләр пар энергиясен файдаланырга өйрәнгәннәр һәм электр двигательләре, соңрак атом энергиясе куллануга күчкәннәр. Хәзер инде планетада 6 млрд чамасы кеше яши.

Үсешнең барлык бу стадияләрендәге җәмгыятьләр хәзергәчә янәшә яши: гәрчә кешелек дөньясының күпчелеге аграр мәдәният стадиясендә яшәвен дәвам иттереп, исәпкә алынмаслык азчылык азык җыючылар һәм аучылар булып калса да, кешеләрнең якынча өчтән бере индустриаль һәм постиндустриаль җәмгыять стадиясенә ирешә.

Без кешелек җәмгыятенең тагын бер мөһим сыйфатын ачыкладык — ул *арта баручы тизлек белән* алга таба хәрәкәт итә икән.

Җәмгыятьнең эволюциясен, үз үсешендә кешелек цивилизациясе үткән төрле стадияләрне чагыштырып, галимнәр ***тарихның тизләнеш законын*** билгеләи. Бу закон буенча һәр стадиягә үзеннән элек булганына караганда азрак вакыт китә, ягъни закон тарихи вакытның тыгызлануын дәлилли. Һәр соңгы дәвердә техник уйлап табулар һәм фәнни ачышлар күбрәк була, эш коралы һәм технология тизрәк камилләшә. Әгәр традицион җәмгыятьтә эш коралының бер төре дистәләрчә һәм йөзләрчә буыннар дәвамында бик аз гына үзгәртүләргә дучар булса, хәзерге дөньяда бер буын гомерендә генә дә коралларның, техника һәм технологияләрнең берничә төре алышына. Элек эш кораллары буыны алышыну тизлеге кешеләр буыны алышыну тизлегеннән артка калып барган. Ләкин хәзер эш кораллары буыны кешеләр буыны алышыну тизлегеннән кызурак алышына.

Бүгенге җәмгыять — кешелек тарихы эволюциясендә кыска гына вакытны, соңгы 250–300 елны колачлаган иң югары ноктасы. Ул үсешнең җәмгыятьнең ике тибына туры килә торган ике чорын — индустриальне һәм постиндустриальне үз эченә ала. Тарихның тизләнеш законы нигезендә тарихи вакыт тизләнә, җәмгыятьнең һәм формациянең яңа типлары вакыт буенча кыскарак, әмма эчтәлек буенча баерак була бара. Индустриальгә кадәр җәмгыять — мең елларга, индустриаль җәмгыять — йөз елларга, постиндустриале (аның тәмамланмаган булуын исәпкә алып) дистә елларга сузыла.

«Җәмгыятьне» бүгенчә аңлау Европа мәдәниятендә XVII–XVIII гасырлардан да алда формалашмаган. XVIII гасыр ахырында «гражданлык җәмгыяте» төшенчәсе барлыкка килә. Ул барлык халыкның холыкларын һәм гореф-гадәтләрен, халыкның үзенчәлеген һәм үзидарәсен, ниһаять, гади кешеләрнең сәяси тормышта дәүләт тарафыннан юнәлтүле түгел, ә стихияле төстә катнашуын сурәтли.

Элек гади кешеләрне «җәмгыять» дип аталган оешма составына кертмәгәннәр. Шулай итеп, «җәмгыять» төшенчәсе аристократия, ягъни халыкның үз кулына байлык һәм

хакимият туплаган азчылыгы белән чикләнгән. Без бүген бу өлешне «югары җәмгыять», «югары катлау», элита дип атыйбыз. Мондый традиция антик чорга барып тоташа. Җәмгыятькә, дәресрәге, шәһәр-дәүләткә Платон һәм Аристотель фәкать ирекле гражданнарны гына керткәннәр. Коллар җәмгыять әгъзалары булмаган. Әмма беренчеләре, кагыйдә буларак, азчылыкны тәшкил иткән.

XVIII гасыр ахырыннан, нәкъ менә Европаның сәяси йөзен үзгәрткән Бөек француз революциясе булганнан соң (1789–1799), «җәмгыять» сүзе киң мәгънәдә кулланыла башлый. Ул кешеләрнең туып килгән үзаңын, күпчелек халыкның сәяси тормышта катнашуга омтылышын чагылдыра. «Җәмгыять» төшенчәсенең кешеләрнең һаман саен киңрәк даирәсенә таралуы даими һәм шактый каршылыклы процесс була. Европаның кайбер илләрендә хатын-кызларның бүгенгәчә тавыш бирү хокуклары юк.

Нәкъ менә XVIII гасырны Европаның икътисади йөзен үзгәрткән, *сәнәгать революциясенең* кузгалу ноктасы дип атыйлар. Алпавыт гаиләсеннән, хезмәтчеләр һәм крепостной крестьяннардан яисә шәһәр һөнәрчесе гаиләсеннән, өйләнмәгән өйрәнчекләр, ирекле ялланган эшчеләр һәм хезмәтчеләрдән торган йорт фабрикасына алмашка бер-бер предприятиедә меңләгән ялланган эшчеләр, иркен цехлар һәм катлаулы җиһазлар булган эре сәнәгать килә.

Медицинадагы уңышлар, яшәүнең санитар шартлары һәм туклану сыйфаты яхшыру нәтиҗәсендә үлем-китем нык кими, уртача яшәү озынлыгы арта. Халык саны да үсә. Уңайлырак тормыш, мәдәни азык, белем алуның яхшырак мөмкинлекләрен эзләп, кешеләр һаман саен үз теләкләре белән авылдан шәһәргә күчеп килә.

> **ШӘҺӘРЛӘШҮ (УРБАНЛАШУ)** — шәһәр халкы өлешенең артуы һәм шәһәрчә яшәү рәвешенең халыкның барлык катлауларына таралуы.

Бу күренеш башка бер процессның — *индустриальләштерүнең* аерылгысыз юлдашына әверелә. Ул тагын да яхшырак әзерлекле хезмәткәрләр таләп итә, чөнки яңа технологияләр даими катлаулана. Андый мөмкинлекләрне нәкъ менә урбанлашу тәэмин итә, ул авыл халкын суырып ала һәм аны югары белемле шәһәр кешесенә әверелдерә.




Нык үскән индустриаль илләрдә эш атнасының уртача озынлыгы

Икътисади мөстәкыйльлек һәм гражданнарның сәяси ирекләре киңәю нәтиҗәсендә шәхес төшенчәсе акрынлап гади кешеләргә дә тарала. Әле бит күптән түгел генә, төгәлрәге XVII гасырда, икътисади яктан бәйле хәлдә булган гади халыкны җәмгыятьнең тулы хокуклы әгъзалары итеп танудан баш тартканнар.

**Индустриаль җәмгыять.** Индустриаль җәмгыятьтә, мөгаен, беренче тапкырдыр, эш урыны яшәү урыныннан аерыла: һөнәрчеләрдән аермалы буларак, эшче һәр иртәсен үз йортын калдырып чыга һәм шәһәр транспортында шәһәрнең үз предприятиесе урнашкан бүтән читенә китә. Андый җәмгыятьтә халыкның төп өлеше сәнәгатьтә эшли һәм шәһәрдә яши. Андый типтагы җәмгыять барлыкка килүгә ике глобаль процесс сәбәп була:

— ***җитештерүне индустриальләштерү;***

— ***шәһәрләштерү.***

Индустриаль җәмгыять XVIII гасырда барлыкка килә. Ул икътисади һәм сәяси революцияләр баласы. Икътисади дигәндә *бөек сәнәгать революциясе* (аның ватаны Англия), ә сәяси дигәндә *Бөек француз революциясе* күз алдында тотыла. Аларның һәр икесе дә Европаның йөзен тамырдан үзгәртә: беренчесе кешелек дөньясына икътисади ирекләр һәм яңа социаль стратификация, нәкъ менә сыйныфларга

бүленешне, ә икенчесе сәяси ирекләр һәм хокуклар, шулай ук җәмгыятьнең яңа сәяси формасын — барча кешеләрнең закон алдында тигезлегенә нигезләнгән *демократия* бирә.

Өч гасыр эчендә Европа җәмгыяте танымаслык булып үзгәрә. Феодализмга алмашка капитализм килә (К.Маркс теориясе буенча). Кулланука «индустриальләштерү» төшенчәсе керә. Аның әйдәп баручысы — машиналар җитештерү, ирекле эшмәкәрлек һәм яңа тип законнар ватаны Англия. Индустриальләштерү — фәнни белемнәрне сәнәгать технологиясендә куллану, энергиянең яңа чыганакларын ачу, аның ярдәмендә машиналарга элек кешеләр яки йөк хайваннары башкарган эшләрне тапшыру мөмкинлеге ул. *Сәнәгатькә күчү кешелек дөньясы өчен үз вакытында җир эшкәртүгә күчкән кебек үк әһәмиятле революция була.* Сәнәгать аркасында халыкның зур булмаган өлеше, җир эшкәртүгә тотынмыйча, халыкның күпчелеген туйдыра ала. Бүген авыл хуҗалыгында АКШта халыкның 5% ы, Германиядә — 10% ы, Япониядә 15% ы мәшгуль.

Җир эшкәртә торган дәүләтләрдән һәм империяләрдән аермалы буларак, *индустриаль илләрдә* халык саны күбрәк — дистәләрчә һәм йөзләрчә миллион кеше. Алар — югары урбанлашкан җәмгыятьләр. Әгәр җир эшкәртә торган җәмгыятьләрдә шәһәрләр мөһим роль уйнаса, индустриаль җәмгыятьтә алар төп рольне уйный башлый.

Хезмәт бүленеше нык алга китә. Меңнәрчә һәм дистә меңнәрчә профессияләр барлыкка килә. Шул ук вакытта иске профессияләргә алмашка яңалары килү тизлеге дистәләрчә һәм йөзләрчә тапкыр арта, җитмәсә әле аларның күпчелеге аграр җәмгыятькә таныш булмый. Килер вакыт, сәнәгать хезмәтенең абруе да котылгысыз рәвештә төшә башлар. Әмма мондый хәл чираттагы стадиягә — постиндустриаль җәмгыятькә күчү белән бәйле булачак.

**Постиндустриаль җәмгыять.** Индустриальгә кадәр (традицион) җәмгыятьтә үсешнең төп билгеле торган факторы булып, төп институтлары чиркәү һәм армия булган авыл хуҗалыгы була. Индустриальдә — башында корпорация һәм фирма торган сәнәгать. *Постиндустриаль сәнәгатьтә төп билгеләгеч фактор булып теоретик белем,* шулай ук аның җитештерү һәм туплану урыны буларак университет санала.

Индустриальләштерү процессын һәм нәтиҗәсен график ысул белән чагылдырырга була. АВ турысы индустриальләштерү процессын сурәтли. Турыпочмаклыкның аскы өлеше җәмгыятьнең сәнәгать казанышлары белән тулылану дәрәҗәсен күрсәтә. Ул традицион җәмгыятьтә минималь һәм индустриальдә максималь

***Индустриаль җәмгыятьтән постиндустриальгә күчү товар җитештерү икътисадының хезмәт күрсәтүгә әверелүе белән бергә бара, бу исә хезмәт күрсәтү өлкәсенең җитештерү өлкәсеннән өстенлеген аңлата.***

***Социаль структура үзгәрә: сыйныфларга бүленү үз урынын профессиональ бүленүгә бирә.***

***Социаль тигезсезлек критерие буларак, милек үз әһәмиятен югалта,*** **хәлиткеч булып укымышлылык һәм белем дәрәҗәсе кала. Мондый процесслар индустриальдән постиндустриаль җәмгыятькә күчүне тәгаллләп килә торган АКШ белән Япониядә күзәтелә. Россия күптән түгел индустриальгә кадәрге җәмгыятьтән индустриальгә күчүне тәгаллләде.**

***Бүгенге дәвердә әйләнешкә ресурсларның яңа ике төре: мәгълүмати һәм кеше ресурслары*** **кертелде. Мәгълүмати ресурс — кешелек дөньясы туплаган һәм аның тормыш эшчәнлеге өчен кирәкле белемнәр һәм мәгълүматлар. Аларны табу персональ компьютер терминаллары аша глобаль коммуникация системасы буенча гамәлгә ашырыла. Мәгълүмати ресурслар, болардан тыш, үзләренә белгечләрнең индивидуаль белемнәрен дә кертә. Ресурсларның башка**

төрләре кебек үк, алар сатылырга һәм сатып алынырга мөмкиннәр.

Галимнәр инанганча, мәгълүмати аралашуның үзәген кеше факторы тәшкил итә, аны башка — икътисади, машина, табигать факторлары белән бергә карап була. Кеше факторының асылы шунда: бик тә катлаулы техника һәм үтә дә нәзек технология үсешендәге казанышларга карамастан, кеше-хезмәткәрнең роле кимемәде, киресенчә, туктаусыз үсә.

---

**Төшенчәләр:** *тарихның тизләнеш законы, традицион җәмгыять, индустриаль җәмгыять, постиндустриаль җәмгыять, шәһәрләшү, индустриальләштерү.*

---

**Сораулар һәм биремнәр**

**1.** Тарихның тизләнеш законы ничек чагыла?

**2.** Постиндустриаль җәмгыятьнең нинди характерлы сыйфатларын аерып күрсәтергә була?

**3.** Индустриаль һәм постиндустриаль җәмгыятьләрнең төп охшашлыклары һәм аерымлыклары нәрсәдә?

***4.** Кайбер тарихи фактларны исегезгә төшереп, түбәндәге сорауларга җавап бирегез:

а) 1861 елда крепостной хокукны бетерү һәм Россиянең капитализмга күчүе «көнбатышлылар» барлыкка килүенең сәбәбеме, әллә нәтиҗәсеме?

б) Большевикларны сез кемнәр рәтенә кертер идегез — «көнбатышлылар»гамы, әллә «славянофиллар»гамы? «Славянофиллар» бүген бармы? Аларга нәкъ менә кемнәр керә?

**5.** Ни өчен галимнәр «постиндустриаль җәмгыять» атамасына синоним итеп «индустриаль революция» һәм «кибернетика җәмгыяте» дигән төшенчәләрне кулланалар?

***6.** Өстәмә әдәбияттан, газета-журнал материалларыннан файдаланып, түбәндәге темага кыска (2–3 бит) эссе языгыз:

«Нык үскән илләрнең артта калган илләргә йогынтысы хәтта куллану өлкәсендә дә тискәре роль уйный. АКШ, Япония яки Франциядә халыкның кулланугa булган сорау дәрәҗәсе шактый югары: анда начар товарны

сатып алмыйлар. Ләкин ул барыбер җитештерелә. Ничек уйлыйсыз, алар кая җибәрелә? Җирле халыкның Көнбатыштан китерелгән товарларга әзер булмавы нәрсәдә чагыла? Алар кирәк урында кулланыламы? Куллану бумы аборигеннарның яшәү рәвешенә һәм кыйммәти ориентлашуларына ничек йогынты ясый?»

***7.** Халыкларның тигезсез үсүе һәм сәнәгать революциясе законын үзара бәйләгез. Беренчесен белгән хәлдә икенчесенең үсеш темпындагы аерманы ни рәвешле аңлатып була? Ни өчен сәнәгать революциясе Россиядә Англиягә караганда озаграк барган? Монда нинди үзгәртеп корулар соңга калган?

**8.** Шәһәрләштерү һәм индустриальләштерүнең охшашлыгы һәм аермасы нидән гыйбарәт? Плюсларны һәм минусларны табыгыз.

**? Проблема.** Бүген Россияне нинди типтагы җәмгыятькә кертеп була?

**Практикум.** Җәмгыятьнең һәр тибының характерлы сыйфатларын аерып күрсәтегез. Таблицаны тутырыгыз.

*Таблица*

| Җәмгыять тибы | Үлчәмнәр | Дәвам итү вакыты | Хуҗалык итү ысулы | Милек формасы | Тигезсезлек дәрәҗәсе | Социаль оешма | Сәяси оешма | Дәүләт тибы | Идарә итү аппараты |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Локаль төркем | | | | | | | | | |
| Ыруг общинасы | | | | | | | | | |
| Юлбашчылык итү | | | | | | | | | |
| Аграр җәмгыять | | | | | | | | | |
| Индустриаль җәмгыять | | | | | | | | | |

## § 6. Модернизация (камилләштерү)

«Модернизация» сүзе инглизчәдән тәрҗемәдә «заманчалаштыру» дигәнне аңлата. Ул җәмгыятьне заман таләпләренә туры китерә торган камилләштерү, иске формалардан баш тарту һәм яңаларын эзләү дигән сүз. Дөньякүләм социологиядә «модернизация» дип *индустриальгә кадәрге җәмгыятьтән индустриальгә, аннары постиндустриальгә күчүне* атыйлар.

Менә инде илле еллап дөнья фәнендә *модернизация теориясе* дигән исем алган концепция алдынгы позицияне алып тора. Ул социаль прогресс төшенчәсенә таяна, чөнки барлык җәмгыятьләр, нинди генә дәвердә яшәсәләр дә һәм нинди генә төбәктә урнашсалар да, кешелек җәмгыятенең кыргыйлыктан цивилизациягә таба баруының бердәм, барысын да колачлый торган, универсаль процессына кушылуын күздә тота. Фән һәм техника прогрессы дөньякүләм чәчәк атуга һәм барлык социаль проблемаларны хәл итүгә илтә. Бу агымда һәр илнең мәдәни үзенчәлеге икенче планга күчә кебек, ә беренчегә аларны берләштерә торган гомумкешелек кыйммәтләре системасы чыга.

*«Модернизация»* атамасы социаль прогрессның барлык чорына да түгел, бары тик аның бер этабына — бүгенгесенә генә карый. Кешелек тарихының бу чорын аның туу моментыннан, аннары капитализм чәчәк атуыннан исәпли башлаганлыктан, модернизациянең асылын нәкъ менә шул формация кыйммәтләре һәм казанышларының бөтен дөньяга таралуы белән бәйлиләр. Конкрет сүз рационализм, исәп-хисап белән тоту, урбанлашу, индустриальләштерү турында бара. Модернизация лидерлары — АКШ һәм Көнбатыш Европа, аларга бөтенләй һәм тулысынча кушылдылар һәм югары икътисади нәтиҗәләргә ирештеләр. Әмма үз үсешләрендә артта калган Азия, Африка, Латин Америкасы илләренә, Япония үрнәгендә Көнбатыш технологияләрен, капитал салымнарын һәм тәҗрибәсен кулланып, алга киткән индустриаль илләрне куып җитәргә берни дә комачауламый. Әлеге теория авторлары шулай уйлый.

Модернизация үз үсешләрендә соңга калган илләрнең, этапларның чиратлылыгын бозмыйча, ни рәвешле бүгенге стадиягә ирешү һәм эчке проблемаларын хәл итү мөмкин-



леген аңлатырга тиеш. Модернизация дөньякүләм икътисади система дип аңланган дөньякүләм бергәлеккә керү ысулын күрсәтә. Аның ике төрен аерып күрсәтәләр.

**Органик модернизация.** *Шул илнең үзенең үсеш моменты булып тора һәм алдагы эволюциянең бөтен барышы белән әзерләнә.* Мәсәлән, Англиянең XVIII гасырдагы сәнәгать революциясе нәтиҗәсендә феодализмнан капитализмга күчүе. Андый модернизация икътисадтан түгел, ә мәдәнияттән һәм иҗтимагый аңның үзгәрүеннән башлана. Капитализм кешеләрнең тормыш укладындагы, традицияләр, дөньяга караш һәм ориентлашуларындагы үзгәрешләрнең *табигый* нәтиҗәсе буларак барлыкка килә.

**Нәорганик модернизация.** *Ул ныграк үскән илләр ягыннан тышкы чакыруга җавап булып тора* һәм хөкүмәт тарафыннан тарихи артталыкны җиңү һәм чит илләргә бәйлелектән качу максатында «куып килә торган» үсү ысулын гәүдәләндерә. Россия шул исәптә һәм ул татар-монголлар явы нәтиҗәсендә үз үсешендә берничә йөз елга артка алып ташлануы аркасында, берничә тапкыр алдынгы илләрне куып җитәргә омтыла. XVIII гасырдан Петр I реформалары, XX гасырның 30 нчы елларындагы индустриальләштерү, 1985 елгы үзгәртеп кору һәм 1991–1993 еллардагы икътисади реформалар нәкъ менә шул максатны күздә тота.

Нәорганик модернизация чит ил җиһазлары һәм патентлары сатып алу, чит технологияне алу (еш кына икътисади шпионаж юлы белән), белгечләр чакыру, чит илләрдә укыту, инвестицияләр юлы белән гамәлгә ашырыла. Тиешле

үзгәрешләр социаль һәм сәяси өлкәләрдә дә бара: идарә итү системасы нык үзгәрә, яңа хакимият органнары кертелә, ил конституциясе чит ил аналогларына карап үзгәртелә. Россиядә XVIII һәм XX гасырларда, Японидә XIX һәм XX гасырларда күп яктан нәкъ менә шулай була да. Соңгысына үзе технология һәм финанс алган АКШны куып җитү һәм узып китү өчен 20 ел кирәк булды. Кыска гына вакыт эчендә нәорганик модернизация органикка алышынды. Япония үз нигезендә үсә һәм үз чиратында, кабатлау өчен үрнәк булып тора. Россиядә эш башкача тора. Беренче башлангыч реформалардан даими чигенешләр, аларны тормышка ашыруның эзлеклелеге аркасында күчеш чоры озакка сузылды. Менә хәзер генә Россия эзлекле рәвештә реформалар юлыннан бара.

Нәорганик модернизация мәдәнияттән түгел, ә икътисадтан һәм сәясәттән башлана. Башкача әйткәндә, органик модернизация — «түбәннән», ә нәорганик «югарыдан» башлана. «Камилләштерү» принциплары халыкның күпчелек өлешләрен колачларга өлгерми, шунлыктан ныклы социаль яклау тапмый. Алар бары тик җәмгыятьнең ныграк әзерлекле өлешенең генә аңын колачлыйлар. Интеллигенция «көнбатышлылар»га һәм «славянофиллар»га аерылган XIX гасырда бу шулай була. Беренчеләре тизләтелгән модернизацияне һәм Көнбатыш үрнәкләрен механик күчерүне яклый, ә икенчеләре мөстәкыйль үсеш юлын, ягъни органик модернизацияне алга сөрә. Беренчеләрнең саны киң массаларны агартуга һәм рациональ кыйммәтләр файдасына ышандыруга җитми. Капитализм Россиядә уңышсызлыкка очрый.

Җәмгыять үсешендә һәм индустриаль җәмгыятьтән постиндустриальгә күчүдә *техник прогресс* бик тә зур роль уйный. Ул кешелек җәмгыятен танымаслык итеп үзгәртә. Шуның нәтиҗәсендә ул бүген кешесез җитештерү дәверенә керә. 2000 елда «ак якалар», ягъни автоматлаштырылган җитештерүдә, фәнни һәм гамәли эшләрдә, шулай ук мәгълүмат өлкәсендә шөгыльләнүче хезмәткәрләр алга киткән илләрдә эшче көчләрнең 90% ы чамасын тәшкил итәләр. Мәшгульлекнең аерым формасы — *өйдә эшләү* барлыкка килә. Ул безне эш урыны яшәү урыныннан аерылгысыз булган дәвергә кире кайтара кебек. Әгәр бу кире кайту булса




Соңгы йөз елда кешелек дөньясының индустриаль куәте чыганаклары бик нык үзгәрде: сәнәгатьне хәрәкәт иттерүче көч буларак, кеше һәм хайваннарның роле кимеде, ә техника куллану артты

да, сыйфат ягыннан тагын да югарырак баскычка кайту. Компьютер белән өйдә эшләүчеләрнең инде миллионнарга җиткән бүгенге буыны үтә дә төгәл машиналарның клавишаларына баса да искитмәле күп мәгълүмат белән эш итә. Шул ук вакытта аларның хезмәт җитештерүчәнлеге 4 тапкыр арта. Чит ил компанияләре үз секретарьларын һәм эш башкаручыларын һаман саен ешрак өйдә эшләргә күчерәләр.

Индустриаль җәмгыять үсешенең яңа этабы турында XX гасырның икенче яртысында, фән-техника прогрессы башка сыйган барлык чикләрне узып киткәч сөйли башлыйлар. Социаль чынбарлыкны яхшырак чагылдыра торган яңа төшенчә кирәк була. Аны Америка социологы ***Даниель Белл*** «постиндустриаль җәмгыять» дип кулланышка кертә. Моннан тыш, башка атамалар да кулланыла: «икенче сәнәгать революциясе», «өченче дулкын», «супериндустриаль җәмгыять», «өченче индустриаль революция», «кибернетика җәмгыяте».

XX гасырның 70 еллары кешелек җәмгыяте үсешендә яңа этапның исәп башлангычына әверелә. Ул мәгълүматиэлектрон системалар барлыкка килү, сәнәгатьтә һәм хезмәт

күрсәтү өлкәсендә, сәүдә һәм алмашу өлкәсендә микропроцессорлар куллану белән характерлана. Агробизнес, нефть химиясе, геннар инженериясе, компьютер техникасы технологиянең җәмгыятьтә төп рольне уйнавын дәлилиләр. 70 еллар уртасында алга киткән илләрдә сәнәгатьтә мәшгульлек нык кими: Япониядә — 36%, Германиядә — 46%, АКШта — 30%, Англиядә — 41% кала. Киресенчә, хезмәт күрсәтү өлкәсендә мәшгульлек арта: АКШта — 65% ка, Япониядә — 50%, Германиядә — 45%, Англиядә — 43% ка кадәр җитә.

Техник прогрессның тизлеген билгели торган энергия чыганаклары тамырдан үзгәрә. Традицион җәмгыять — кеше мускуллары, аграр җәмгыять — терлекләр көче, индустриаль — электр, пар, җил, су куәте һәм, ниһаять, постиндустриаль җәмгыять — атом һәм термо-төш энергиясе дәверләре.

**Модернизация — яхшылыкмы, әллә яманлыкмы?**

Бүген бу сорауларга күп илләр галимнәре җавап бирергә тырыша. Модернизация проблемалары берәүне дә битараф калдырмый.

Узган гасырның 60–70 елларында, артта калган илләргә түбәндәгеләр белән ярдәм итеп, индустриаль дөнья яхшылык эшли, дип исәплиләр: 1) фермерлыкны һәм авыл хуҗалыгы машиналары таратып, уңыш алуны арттыра; 2) «тере» акча запаслары булдыра; 3) арзан эшче көчләр базары булдыра.

Гәрчә халыкара ярдәм күрсәтү проекты авторлары катып калган этноцентристлар булмыйча, күбрәк изге нияттән чыгып эш итсәләр дә, алар традицион җәмгыятькә Көнбатыш бизнесмены күзлегеннән карыйлар. Көчсез дәүләтләрдә яшәүчеләрне планлы тәртиптә яңа рольләргә, профессияләргә өйрәнергә, алар күнекмәгән фермер техникасын үзләштерергә мәҗбүр итәләр. Зур үзгәрешләр кетәләр. Ләкин алга китеш булмый.

«Тере» акча запаслары әлеге илләр хөкүмәтләрен дөнья базарына актив чыгарга этәрә. Ләкин арзан чимал — шикәр һәм кофе чыгару дөньякүләм бәяләрне төшерә һәм өченче дөнья илләренә зыян ки-

терә. Авыл хуҗалыгын механикалаштыру һәм фермерлыкка күчү авылдан вак җитештерүчеләрне кысрыклап чыгара. Җитештерүне эре монополияләр үз кулларына ала. Авыл хуҗалыгы продукциясенә бәяләр күтәрелә, ә шәһәргә эшсез аграрийлар ташкыны агыла. Хакимиятнең демократик институтлары да эшләп китә алмый. Алар аборигеннарның традицион мәдәниятләренә каршы килә. Сепаратлык омтылышлары көчәя. Африка дәүләт суверенитеты таләп итүче күпләгән кабилә берлекләренә таркала башлый. Гражданлык сугышлары һәм этникара тарткалашлар саны арта.

Бакчачылык стадиясендәге артта калган җәмгыятьләргә сабан керткәч, хатын-кызның азык җитештерүдәге һәм җирле базардагы роле бик нык төшә. Аның икътисади хакимлеге кими, ә ир-атлар хакимлеге көчәя. Хатын-кыз күбрәк йорт эшләре белән шөгыльләнә, бала таба һәм тәрбияли. Көнбатыш культурологлары омтылган җенесләр тигезлеге барып чыкмый. Хатын-кызны бер өлкәдә азат итәләр, әмма икенчесенә бәйләп куялар.

Шулай итеп, камилләштерүнең Көнбатыш варианты хатын-кызның традицион җәмгыятьтәге хәлен катлауландыра һәм күпчелек халыкның матди ягын да яхшыртмый.

---

**Төшенчәләр:** *органик модернизация, нәорганик модернизация, техник прогресс.*

---

**Сораулар һәм биремнәр**

**1.** Модернизация җәмгыять үсешенең кайсы стадиясендә барлыкка килә?

***2.** Модернизация — яхшылыкмы, әллә явызлыкмы? Сорауны шулай кую дөресме?

***3.** Көндәлек матбугаттан, фәнни мәкаләләрдән һәм публицистикадан файдаланып, узган гасырның 90 еллар чигендә Россиядәге икътисади реформаларның барышын анализлагыз. Аларны Модернизация концепциясе белән бәйләгез. Кайбер сорауларга җавап бирегез:

а) Реформаларны нинди кыенлыклар күбрәк тоткарлаган?

б) Тамырдан үзгәртүләр өчен иҗтимагый аң өлгергәнме, юкмы?

в) Модернизацияне халыкның кайсы катламнары яклаган, кайсылары — юк?

г) Реформалар барышын кайсы законнар чыгару чаралары тизләткән, ә кайсылары тоткарлаган?

д) Җәмгыятьнең төрле өлкәләре, аның институтлары бер үк тизлектә үзгәргәннәрме?

е) Кешеләрнең матди хәле, тормыш дәрәҗәсе нинди хәлдә булган һәм бу реформалар барышына ничек йогынты ясаган?

**4.** Органик һәм нәорганик модернизация нәрсәләре белән аерыла? Ни өчен берсе югарыдан, икенчесе түбәннән бара?

**5.** Тизләтелгән модернизациянең плюслары һәм минуслары конкрет нәрсәдә чагыла? Модернизациянең көнбатыш варианты нәрсә ул? Ул безнең илдә ни дәрәҗәдә кулланыла ала?

**? Проблема.** Көнбатыш илләр Россиягә ни өчен матди ярдәм күрсәтә? Алар безнең илне икътисади бәйлелеккә төшерергә тырышамы, әллә модернизация белән бәйле реформалар барышын тизләтмәкчеме?

**Практикум.** Параграф һәм Россия тарихы дәреслекләре материалларын файдаланып, таблицаны тутырыгыз.

*Таблица*

| Күренеш | Максатлар | Төп эчтәлек | Нәтиҗәләр |
|---|---|---|---|
| XVIII гасыр Петр I реформалары | | | |
| XX гасырның 30 елларында индустриальләштерү | | | |
| 1985 елгы үзгәртеп кору | | | |

## § 7. Кешелек дөньясын глобальләштерү

Индустриальгә кадәрге җәмгыять урдалардан, кабилә, патшалык, империяләрдән башлап күптән түгел барлыкка килгән милли дәүләткә кадәр аерым-аерым социаль берәмлекләрдән торган бик тә чуар, төрле-төрле мозаикадан гыйбарәт була. Әлеге бергәлекләрнең һәрберсенең бәйсез һәм үзен тәэмин итә торган икътисады, үзенең мәдәнияте була. Постиндустриаль җәмгыять — бөтенләй башка нәрсә. *Сәяси планда миллидән өстен берәмлекләр төрле масштабта яши:* сәяси һәм хәрби блоклар (НАТО), идарә итә торган төркемнәр коалициясе («Зур җиделек»), континенталь берләшмәләр (Европа берләшмәсе), бөтендөнья халыкара оешмалар (БМО). Хәзер инде Европа парламенты һәм Интерпол йөзендә бөтендөнья хөкүмәте контурлары да беленә. Төбәкара һәм дөньякүләм икътисади килешүләрнең роле көчәя. ***Хезмәтнең глобаль бүленеше куәтелә, күпмилләтле һәм трансмилли корпорацияләрнең роле үсә,*** алар еш кына уртача милли дәүләт керемennән артып китә торган керемгә ия. «Тойота», «Макдоналд», «Пепси-Кола» яки «Дженерал Моторс» кебек компанияләр милли тамырларын югалттылар һәм бөтен дөнья буйлап эш йөртәләр. Финанс базарлары вакыйгаларга яшен тизлегендә җавап бирә.

*Мәдәниятта бертөрлелеккә омтылу тенденциясе өстенлек итә.* Массакүләм мәгълүмат чаралары (ММЧ) планетабызны берләштерә. Миллионнарча кешеләр бер үк вакытта төрле урыннарда бара торган вакыйгаларның шаһитлары булалар, бу исә зәвыкларны бердәйләтә. Бөтен җирдә шул ук куллану товарлары. Миграция, чит илләрдә вакытлыча эшләү, туризм кешеләрне башка илләрдәге яшәү рәвеше һәм характеры белән таныштыра. ***Гомум кабул ителгән бердәм сөйләм теле*** — *инглиз теле* формалаша. Компьютер технологияләре бер үк программаны бөтен дөньяга тарата. Көнбатыш массакүләм мәдәният универсальгә әйләнә, ә җирле традицияләр эреп югала.

Һәр тарихи дәверне һәм җәмгыять тибын бөек ачышлар гәүдәләндерә. Индустриальгә кадәрге җәмгыятьтә — ут табу, тәгәрмәч һәм алфавит ачу, индустриальдә — китап басу станогы, пар машинасы һәм конвейер линиясе, постиндустриаль җәмгыятьтә атом энергиясе, *компьютер* һәм



Телевидение бүгенге җәмгыятьне глобаль берләштерү факторына әверелде

*телевидение* революцион үзгәрешләр китереп чыгардылар. Соңгысы турында аерым сөйләргә кирәк. 1939 елда Бөтендөнья ярминкәсендә Эн-би-си Кушма Штатларда даими рәвештә телевидение тапшырулары башлаганнан соң фәкать ярты гасыр вакыт эчендә ТВ кешелек дөньясына үз йогынтысын элеккеге барлык ачышларга караганда да күпкә киңрәк һәм тизрәк таратты. *Телевидение яшәү рәвешен формалаштыруга, кешеләр арасындагы үзара мөнәсәбәтләргә, идарә итү структурасына һәм хәтта цивилизацияне аңлауга бик тә тирән йогынты ясый.* Ул үзеңне вакыйгалар уртасында итеп сизү мөмкинлеге бирә һәм ничек кенә гаҗәп тоелмасын, максатына ирешә: миллионнарча тамашачының күзгә күренми генә катнашуы теләсә кайсы вакыйгага колач һәм әһәмият бирә.

Айларны атналарга, көннәргә һәм хәтта сәгатьләргә кадәр кысып, телевидение тормыш темпын тизләтте, җәмгыятьне глобальләштерүнең куәтле факторына әверелде. Ул иҗтимагый фикерне формалаштыра, мифлар тудыра, тарих серләрен ача. Сериал геройлары һәм эстрада йолдызлары

безнең өйләребезгә килеп керде һәм инде гаилә әгъзалары-быз булып беттеләр диярлек. Маҗаралы, детектив, мәхәббәт, героик, көнкүреш һәм сәяси фильмнар безгә чынбарлыктан да чынрак булып тоела. Телевидение кешеләрне туплый, тамашачы аудиториясе феномены — чынлап та интер-националь күренеш. Без Америка сәясәтчеләренең эш-гамәлләрен якынча америкалыларның үз процентлары нисбәтендә үк гаеплибез яки хуплыйбыз. Әмма амери-калылар да Россия хөкүмәтендәге үзгәрешләр турында рос-сиялеләрдән соңга калып белмиләр (иртәрәк булмаса әле). Иң гаҗәбе шунда, министрлар кайчак үзләренең эштән алынулары, эшкә билгеләнүләре яки башка эшкә күче-релүләре турында беренче булып телевидение хәбәрләрен-нән беләләр.

Телевидение — бүгенге җәмгыятьне глобальләштерүнең иң куәтле факторларының берсе.

Боларның барысында да тамашачы үзен турыдан-туры катнашучы итеп тоя. Әрмәнстандагы җир тетрәүме, Аляс-када боз әсирлегенә эләккән китлар фаҗигасеме, кешеләр күпчелек очракта башкаларның бәла-казаларын үз күңел-ләренә күпкә якынрак ала башладылар. Безнең рухи дөнья-быз катлауланды, драмалашты, тирәнрәк һәм бер үк вакыт-та хаотигракка әверелде. Телевидение камерасы ярдәмендә бер Җир шарының шундый экзотик почмакларында һәм шундый илләрдә булдык ки, аларга бару өчен безнең акча-быз, бәлки, гомергә дә җитмәс иде.

Кешенең әхлакый батырлыгының бөеклеген, иң кыен шартларда исән калучы гади кешеләр үрнәкләрен күрсәтеп, телевидение бездә күбрәк өмет һәм оптимизм тудыра. Шул ук вакытта ул, экраннардан кешенең әшәкелекләрен, сәяси партияләрнең үзара дошманлашуын, коррупцияне һәм җинаятьне, биржалардагы паниканы һ.б. күрсәтеп, скепти-цизм таралуга ярдәм итә. Әгәр уртача бала билгеле бер яшькә җиткәнчегә кадәр соңгы хәбәрләрдә һәм нәфис фильмнарда дистәләрчә мең чын көчләү актларын күрмәсә, безнең җәмгыятьтә көчләү азрак булыр иде. Ихтимал, бу халкы социаль институтларга һәм үз лидерларына хөрмәт белән караучы җәмгыять булыр иде. Нәкъ менә тамашачы күрсәтелә торган вакыйгаларга битараф калмаганлыктан, телевидение безгә аерым бер көч белән йогынты ясый.

ТВнең көче — фикерләү ысулына тирән йогынты ясауда. Ул иске мифларны яңартуга һәм яңаларын тудыруга сәләтле. Популяр телеперсонажлар Ф. М. Достоевский яки У.Шекспир персонажлары кебек һәм әле алардан ким булмаган тирән әхлак сыйфатларына ияләр, өстәвенә аларны тагын да киңрәк публика күрә ала. Телеперсонажлар беренче чиратта, тиешле күләмдә милли рух сыйфатларын чагылдырулары белән истә кала. Алар үзеңне тоту һәм әхлаклылык эталоннарына әвереләләр.

ТВ әле Советлар Союзы яшәгәндә үк илебезнең сәяси, мәдәни һәм икътисади тормышында үзәк урынны алып торды. Ул ***М. С. Горбачев*** башлаган ачыклык чорында мөһим роль уйнады. Аның образы массакүләм мәгълүмат чаралары алга сөргән сәясәт турындагы күзаллауларга шул кадәр төгәл туры килде ки, кайбер советологлар, Горбачев телевидениедән башка хакимиятне ала һәм кулында тота алмаган булыр иде, дип уйладылар.

Телевидение безнең чынбарлыгыбызны актуальләштерә. Россия парламентында Дума фракцияләре көрәшендә даими рәвештә сәяси лидерларның югары күтәрелүләрен һәм түбән төшүләрен күрсәтә торган телерейтингларны дәлил итеп китерәләр.

Бүгенге президентлар үз иле халкына телевидение экраннарыннан мөрәҗәгать итәләр. Ул милләтләрне һәм халыкларны берләштерә, һәрберебезне соңгы хәбәрләр курсында тота. Без аннан башка бүгенге җәмгыятьне күз алдына китерә алмыйбыз, ә җәмгыять замандашлар белән телевидениедән башка контакт таба алмый.

Телевидениенең дөньяны ничек итеп тамырдан үзгәртүенең яхшы дәлиле — кешеләрнең үзара сөйләшү темалары. Алар нәрсә тикшерә соң? Дәүләт лидерларының сәяси белдерүләрен, телевидение яңалыкларының соңгы сводкасында күрсәтелгән вакыйгаларны, «сабын операсы»ның чираттагы сериясен карауларын һ.б.

Телеэкран гаилә учагы үзәгенә әверелде, аның тирәсенә дуслар, туганнар һәм кунаклар җыела. Без бүген вакыйгаларда катнашмаска, аларны экраннарда карарга яратабыз. Ихтимал, телевидение безне азрак хәрәкәтләнергә мәҗбүр итәдер, аның каравы бунтарьлыгыбызны да киметте.

Иртә балачактан ук телевидение безне башта — карарга, аннары гына тоярга һәм уйларга өйрәтә. Ул вакыйгаларның инде сайлап алынганнарын, төзәтелгәннәрен күрсәтә. Гәрчә ул эшкәртелгән продукт, коллектив иҗаты нәтиҗәсе булса да, инерция буенча без аны чи материал итеп кабул итәбез. Бүгенге ТВ төрле уку материалларының күбесен махсус һәм фәнни-популяр тапшыруларда күрсәтә. Көллият һәм университет студентлары читтән торып белемне ТВ чаралары аша гына түгел, бүген бөтен җир шары чолгап алган Интернет челтәрләре аша да алалар.

---

**Терминнар:** *глобальләштерү, төрле масштабтагы миллидән өстен берәмлекләр, ММЧ.*

---

**Сораулар һәм биремнәр**

**1.** Җәмгыятьне глобальләштерүгә нәрсә хас?

**2.** Нәрсә ул «төрле масштабтагы миллидән өстен берәмлекләр»? Мисаллар китерегез һәм аларның функцияләрен тасвирлагыз.

**3.** Кешелек җәмгыяте үсешенең глобаль факторы буларак, телевидениенең функцияләрен тасвирлагыз.

**4.** Кешеләрнең көндәлек тормышына телевидение ничек йогынты ясый? Андый йогынтыны үз гаиләгез мисалында тасвирлагыз.

**5.** Телевидение ничек итеп илнең сәяси тормышы факторына әверелә?

***6.** Түбәндәгеләр турында уйланыгыз: сәяси партияләр эфир вакыты өчен ничек көрәшәләр; сез телевидение яңалыкларыннан ишетә торган сәяси рейтинглар ничек билгеләнә; сайлаучыларның сәяси өстенлек бирүләрен формалаштыруга телевидение ничек йогынты ясый?

***7.** Фараз кылыгыз: глобальләштерү процессы дөньяның төрле илләрен нинди нәтиҗәләргә китерергә мөмкин.

**? Проблема.** Ничек уйлыйсыз, глобальләштерүнең бөтен дөньяны тулысынча бербөтенлеккә китерүе мөмкинме? Әллә бу мөмкин түгелме? Ни өчен?

**Практикум 1.** Глобальләштерү процессы күренешләренең тулырак исемлеген төзергә тырышыгыз.

**Практикум 2.** Этнопланетар фикерләү (ЭФ) — үзеңне билгеле бер илнең кешесенә караганда Җир планетасы

кешесе итеп күзаллау, яисә уйда гына булса да бөтен планета өчен кайгырту сәләте. ЭФ — яңа термин; аны кемнең уйлап табуы билгесез, ә менә аның принципларын гамәлгә ашыруга кемнең алынуы билгеле. Ул — Калмыкия президенты, республиканы икътисади һәм рухи яктан яңарту, аны икенче Кувейтка әверелдерү максатын куйган К. Илюмҗанов. Ул дөньяның танылган кешеләре Боби Фишерны, Майкл Джексонны, «Бони-М» ансамблен чакыру өчен миллионнарча доллар тота. Элек артка калган, СССР вакытында тормыш дәрәҗәсе буенча 70 урында торган республика хәзер дөньякүләм цивилизация биеклегенә омтыла. Калмыкиянең икътисади яңарту шарты итеп ул рухи прогрессны куя. Президент һәр мәктәп укучысында һәм һәр өлкән кешедә ЭФ — аның кечкенә иле — дөнья системасының бер өлеше булуы, аның провинция түгеллеге, әмма үз республикаң өчен горурлану, аның үзәге булу мөмкинлеге, һәркем үз йортының экологиясе өчен генә түгел, Африкадагы ач балалар турында да кайгыртсын өчен ышаныч тәрбияләргә тырыша.

К. Илюмҗанов планнарын сез ничек бәяләр идегез?

## § 8. Дөньякүләм система

Глобаль дәрәҗәдә кешелек җәмгыяте әле тагын **дөньякүләм бергәлек** дип атала торган дөньякүләм системага әверелә бара. Ул хәзер планетада яшәүче барлык илләрне үз эченә ала.

Американың танылган политологы У.Валлерштайн дөньякүләм системаны өч өлешкә бүлә:

— **төш;**

— **ярымпериферия;**

— **периферия.**

***Төш — Көнбатыш Европа, Төньяк Америка илләре, Япония; аңа камилләштерелгән җитештерү системасы һәм нык үскән икътисады булган иң көчле дәүләтләр керә.*** Аларда башкаларга караганда да күбрәк капитал, сыйфатлы товарлар, иң катлаулы технологияләр һәм җитештерү чаралары. Әлеге илләр кыйммәтле һәм югары технологияле продукцияне периферияга һәм ярымпериферияга чыгаралар.

Ярымпериферия һәм периферия илләре — икенче һәм өченче дөнья дип йөртелә торган илләр. Аларда хакимият тә, байлык та, йогынты да кимрәк.

**Өченче дөнья**

«Өченче дөнья» дигән атама 1952 елда Франциядә барлыкка килә (tiers monde). Ул АКШ белән СССР (беренче белән икенче дөнья) арасындагы «салкын сугыш» дәверендә дошманлашкан бу якларның берсенә дә кушылмаган илләр төркемен характерлый. Алар арасында Югославия, Мисыр, Һиндстан, Гана һәм Индонезия була. 50 елларның икенче яртысында бу атама тагын да киңрәк әһәмият ала. Ул барча аз үскән илләрне аңлата. Шулай итеп, аның эчтәлеге географик түгел, ә икътисади эчтәлек белән тулылана. Аз үскән дәүләтләргә Латин Америкасы, Африка (КАР дан тыш), Азиянең (Япония, Сингапур, Гонконг һәм Израильдән башка) барлык илләрен кертә башлыйлар. Ә Гаити, Бангладеш, Африка Сахарасы дәүләтләре кебек бик тә хәерче һәм ярлы илләрне дүртенче дөнья разрядына кертәләр. Аларны инде икътисади прогресс юлына баскан өченче дөньядан аералар.

***Периферия — Африка һәм Латин Америкасының иң артта калган һәм ярлы дәүләтләре ул.*** Алар төшнең чимал өстәмәләре булып саналалар. Файдалы казылмалар чыгарыла, әмма урында эшкәртелми, ә читкә җибәрелә. Өстәмә продуктның күп өлеше чит ил капиталы тарафыннан үзләштерелә. Җирле элита акчасын үз дәүләтеннән читтә сала, ул чит ил капиталына хезмәткә алына һәм бары тик аның мәнфәгатенә генә хезмәт итә (гәрчә бу кешеләр читкә китмәсә дә). Сәяси режимнар тотрыклы түгел, переворотлар еш булып тора, даими тестә социаль һәм милли каршылыклар барлыкка килә. Югары сыйныф түбән сыйныфтан урта сыйныфның киң катлавы белән аерылмый.

Аларның яхшы яшәве чимал чыгаруга бәйле булганлыктан, технологияләр һәм капитал читтән генә кертелә. Хөкүмәтләр (алар еш кына диктаторлык яки авторитар режимнар) чит ил инвестицияләре килгәндә генә яшиләр һәм ил белән азмы-күпме әйбәт идарә итәләр. Ләкин Көн-

батыш ярдәме дә еш кына дәүләт түрәләре кесәсендә яки аларның чит илләрдәге счетларында утырып кала. Андый хөкүмәтләр тотрыклы түгел, алар даими төстә халыкара конфликтлар, Латин Америкасы илләрендә, Иран һәм Филлипиндагы кебек эчке сугышлар һәм фетнәләр китереп чыгаралар. Хәтта революцияләрдән соң да яңа хөкүмәтләр репрессияләргә тотыналар, тиздән үзләренең сәләтсезлекләрен күрсәтәләр һәм озакламый аларны бәреп төшерәләр.

Өченче дөнья илләренең демографик хәленә каршылыклы процесслар хас: балалар күп туа һәм күп үлә, халык күп кешелек авыллардан, эш эзләп, начар үскән шәһәрләргә күчеп китә.

60 нчы еллардан өченче һәм дүртенче дөнья илләре нык үскән илләрдән бурычка берничә миллиард доллар ала. Кредитларны Көнбатышта икътисади күтәрелеш чорында, димәк, түбән процентлы ставкаларда алалар, ә түләвен бөтенләй башка шартларда түләргә туры килә. Көнбатышка тулаем бурыч 800 млрд доллардан артып китте, ә заемчыларның кредиторларга түләү юллары күренми. Иң күп бурычлылар — Бразилия, Мексика, Аргентина, Венесуэла, Нигерия, Перу, Чили һәм Польша. Әлеге илләрнең икътисадына булышлык итәргә тырышып, Көнбатыш кредиторлары заемнарны рефинансларга мәҗбүр була. Әмма алар ешрак теге яки бу илнең кредитларны өлешчә яки тулысынча түләргә сәләтсезлекләре белән очраша. Шул кадәр зур күләмнәрдәге бурычларны түләмәү халыкара финанс системасын боза.

***Ярымпериферия төш белән периферия арасындагы арадаш позицияне алып тора. Алар — шактый дәрәҗәдә үскән индустриаль илләр.*** Төш илләре кебек үк, алар читкә сәнәгать һәм сәнәгатьнеке булмаган товарлар чыгаралар, ләкин аларга төш илләренең хакимлеге һәм икътисади куәте җитми. Мәсәлән, Бразилия (ярымпериферия ил) Нигериягә автомобильләр, машиналар өчен моторлар, АКШка эфлисун согы экстраты һәм кофе чыгара. Җитештерү механикалаштырылган һәм автоматлаштырылган, ләкин илнең сәнәгатендәге барлык яки күпчелек технологик казанышлар төш илләреннән алынган. Ярымпериферийгә динамик сәясәтле, көчәя баручы урта сыйныфлы, тиз үсә барган илләр керә.



У. Валлерштайн һәм Д. Белл теорияләрен берләштереп, без дөньякүләм бергәлек структурасының яңа схемасын алабыз: төш — постиндустриаль җәмгыятьләр, ярымпериферия — индустриаль җәмгыятьләр, периферия — традицион (аграр) җәмгыятьләр

**У. Валлерштайн классификациясен Д. Беллның постиндустриаль җәмгыять теориясе атамаларында китерсәк, мондый нисбәтләр алырбыз:**

**— төш — постиндустриаль җәмгыятьләр;**
**— ярымпериферия — индустриаль җәмгыятьләр;**
**— периферия — традицион (аграр) җәмгыятьләр.**

Инде әйтелгәнчә, дөньякүләм система акрынлап оеша. Тиңдәшле рәвештә, төрле илләр төрле вакытта төштә лидерлык ролен башкарырга, перифериягә төшәргә яисә ярымпериферия урынын алырга мөмкин.

Гадәттә төштә бер дәүләт өстенлек итә. XIV гасырда дөньякүләм сәүдәдә Төньяк Италия шәһәр-дәүләтләре хакимлек иткән. Голландия — XVII гасырда, Англия — 1750 елдан соң, Кушма Штатлар 1900 елдан соң лидер булган. 1560 елда дөньякүләм система төше Көнбатыш Европада (Англия, Франция, Нидерландия, Португалия һәм Испания) урнашкан. Төньяк Италия шәһәр-дәүләтләре ярымперифериягә кушылган. Төньяк-Көнчыгыш Европа һәм Латин Америкасы периферияне тәшкил иткән. Күпләгән җәмгыятьләр (бигрәк тә Океания һәм Африка белән Азиянең эчке өлкәләре) әле күптән түгел генә перифериядән читтә иде. Алар үз продуктларын җитештереп һәм кулланып,

ягъни натураль хуҗалык белән шөгыльләнеп, озак вакыт дөньякүләм капиталистик икътисадка кушыла алмыйлар. Бүген андый илләр чынлыкта юк. Элеккеге совет блогы илләре (Венгрия, Польша, Болгария һ.б.) икенче дөнья илләренә кертелгән. Алар озак вакыт дөньякүләм капиталистик системадан читләштерелеп тордылар. Хәзер аларны периферияга яки ярымпериферияга кертәләр.

80 елларда У. Валлерштайн тәкъдим иткән төш һәм периферия теориясе бүген принципта дөрес дип санала, ләкин билгеле бер дәрәҗәдә төзәтүгә һәм өстәмәгә мохтаҗ. Яңача якын килгәндә, кайчак «трансмилли дөнья» дип атала торган бүгенге халыкара бергәлекнең нигезен әйдәп бара торган халыкара оешмалар, 50–60 төп финанс-сәнәгать блогы, шулай ук 40 меңләп ТМК (трасмилли компания) тәшкил итә. «Глобаль икътисади федерация» тыгыз хуҗалык, сәяси һәм мәдәни элемтәләр белән сугарылган. Көнбатышның эре корпорацияләре, бөтен дөньяда, барыннан да элек өченче дөнья илләрендә филиаллар булдырып, бөтен дөньяны финанс һәм товар ташкыннары белән чолгап алалар. Алар дөньяның төрле төбәкләрен бер-берсе белән икътисади бәйлелеккә кертәләр.

***Әлеге глобаль киңлектә түбәндәгеләр аерылып тора:*** сәүдә-финанс каналларына контрольлек итә торган *постиндустриаль Төньяк;* сәнәгате нык үскән төп державаларның милли икътисадлары җыелмасы — ***югары индустриаль Көнбатыш;*** хуҗалык тормышын яңа индустриаль модель кысаларында төзи башлаган, ***интенсив үсеп килә торган яңа Шәрекъ;*** күпчелек табигый ресурслар исәбенә яши торган ***чимал Көньягы,*** шулай ук күчеш хәлендәге ***посткоммунистик дөнья дәүләтләре.***

---

**Төшенчәләр:** *дөньякүләм бергәлек, дөньякүләм система төше, дөньякүләм система ярымпериферияасе, дөньякүләм система перифериясе, өченче дөнья.*

---

**Сораулар һәм биремнәр**

**1.** Сезнең карашка, Россия дөньякүләм системага нинди дәрәҗәдә кертелгән?

***2.** Ул монда нинди урын алып тора? Җавабыгызны дәлилләгез.

3. Төш, ярымпериферия һәм периферия илләре арасындагы аерымлыкларны күрсәтегез.

*4. Россия кая керә? Элеккеге СССР кая керде?

5. Беренче, икенче, өченче һәм дүртенче дөнья илләре нәрсәләре белән аерыла?

*6. Куба, АКШ, Кытай, Япония, Югославия, Россия, Чили, Аргентина, Бельгия кебек илләрне сез кая кертер идегез?

*7. Түбәндәге нигезләмәне дәлилле яки кире кага торган материал җыегыз: төрле тарихи этапларда Россия төрле дөньяга (икенче, өченче һ.б.) кертелә алыр иде.

**? Проблема.** Ничек уйлыйсыз, хәзерге дөнья лидерлары — АКШ һәм Көнбатыш Европа илләре үз ихтыярларын башка илләргә үзләренең финанс яки сәяси куәтләре нәтиҗәсендә көчләп тагалармы? Бәлки, аларның башка йогынты каналлары бардыр?

**Практикум.** Төркемнәргә бүленеп, биремнәрне башкарыгыз.

I төркем — бүгенге дөньяда төш илләре проблемаларын модельләштерергә һәм мөмкин булган хәл итү юлларын билгеләргә.

II төркем — бүгенге дөньяда ярымпериферия илләре проблемаларын модельләштерергә һәм мөмкин булган хәл итү юлларын билгеләргә.

III төркем — бүгенге дөньяда периферия илләре проблемаларын модельләштерергә һәм мөмкин булган хәл итү юлларын билгеләргә.

# 3 бүлек
# Базар икътисады

## § 9. Базар җәмгыяте

**Базар һәм базар җәмгыяте кешеләрне, бер караганда гади нәрсәгә — ничек нәтиҗәле итеп акча эшләргә, аннары аны тотарга өйрәтә.**

Кешенең теләкләре, ихтыяҗлары, мәнфәгатьләре, фикерләре һәм башка бик күп нәрсәләре акча булуга яки булмауга бәйле. Акча булса, без канәгать, тыныч, тигез холыклы, ул булмау исә кайчак стрессларга һәм күңел төшенкелегенә илтә.

Базар кешеләргә зур байлыклар гына түгел, һичшиксез, зыян да китерә. Социаль яки икътисади күренешнең бер ягы гына була алмый. Иҗтимагый тормышның диалектикасы шундый: һәр күренешнең плюслары һәм минуслары, уң һәм сул ягы бар. Базар белән дә шундый ук хәл. Берәүләрне ул — артык бай һәм әрәм-шәрәм итүче, икенчеләрне хәерче һәм сак тотучы итә.

Җәмгыять табигый чыганаклардан нефть чыгара. Нефть — милли ресурс ул. Аннары аны чит илгә саталар, аны саткан акчага «тавык ботлары», «мерседес»лар һәм компьютерлар алалар. Ресурслар акчага алыштырыла, аңа товарлар алына, алары ахыр чиктә ашала яки файдаланыла. Искитмәле, ләкин җәмгыять фәкать бер максат белән — соңыннан барысын да ашау, сарыф итү, ташлау өчен файдалы казылмалар чыгара, завод-фабрикаларга миллионнарча кешеләрне туплый, җыя, бурычка бата. Җитештерү һәм куллану калдыклары, мегаполисларыбыз тирәсендәге бик тә зур чүплек өемнәре, менә нәрсәгә әверелә табигый ресурслар.

Базар җәмгыяте кулланучыга эшли, аның кечкенә генә теләген дә канәгатьләндерә. Ләкин һич кенә дә гади кешеләр, үз иле гражданнарының ихтыяҗлары турында кайгыртудан түгел. Базар икътисады кешеләрнең ихтыяҗларын белә торып кабарта, чөнки аннары ихтыяҗ кесәсе кабарачак. Кеше үз теләкләре, капризлары, ихтыяҗлары, кирәге өчен акча түли.

***Базар икътисады безнең ихтыяҗларыбызның колачына, күләменә, юнәлешенә бәйле.*** Аның тармаклары — индустрияләр (мәсәлән, туристлык, азык, оборона һ.б. индустрияләр) кулланучы кесәсе өчен ярышалар.

Акчага комсыз бу албастыларга кешенең рухи дөньясы, хисләр һәм кичерешләр байлыгы, мәшәкатьләре һәм кечкенә шатлыклары һич кенә дә кирәкми. Аларга аның кесәсе кирәк. Алар кешегә *кулланучы* буларак кына карый. Шулай итеп, ***акча — кешелек дөньясы өчен мул тормыш кына түгел, бәла дә.*** Моны, кешеләрнең бер-берләреннән читләшүләренең, аларның хис һәм эмоцияләре кыйммәтсезләнүенең сәбәпләре турында уйланып, барлык бөек философлар да, хакимиятнең югары эшелоннарындагы коррупцияләрнең, хезмәт урыныннан явызларча файдалануның, түрәләрнең сатлык җанлылыгы сәбәпләре турында фикер йөртеп, политологлар да аңлаган. Акча шәхесне арзанайта, әхлакны кимерә, җинаятькә илтә. Шуның белән бергә акча — хуҗалык мөнәсәбәтләрендә иң нәтиҗәле оештыручы, кешенең теләсә нинди социаль байлыкка — яраткан китапны укудан башлап абруйлы курортларда шәп ял итүгә кадәр ирешүенең универсаль каналы булып тора.

Икътисади яктан үскән илләрдәге җитештерүнең югары дәрәҗәсе куллануның югары дәрәҗәсен дә китереп чыгара. Кешеләр кулланып калырга гына теләмиләр, уңайлы торакка, абруйлы белем алуга, китапларга, автомобильләргә, сәяхәтләргә, музыкага, модалы аппаратурага, киемгә һ.б. га да ихтыяҗ кичерәләр.

Дөнья шулай корылган ки, кешенең ихтыяҗы зур, акчасы аз. Икътисад — тегесен дә, монысын да тигезләү техникасы. Кешенең чикләнмәгән ихтыяҗлары һәм җәмгыятьнең чикләнгән мөмкинлекләре бер ноктада очрашкач, кеше канәгатьсезлек хисе тоя, ә кайчак көчле стресс кичерә. Отышта фәкать фән генә, чөнки икътисад җәмгыять һәм

кешеләр өчен әлеге парадоксны хәл итү юллары турындагы файдалы рецептлар җыелмасы ул. Кешеләрдә — чикләнгән ихтыяҗлар, ә җәмгыятьтә чикләнмәгән ресурслар булса, аның кемгә кирәге булыр иде?

*Базар икътисадын иң күп ихтыяҗларны иң аз средстволар исәбенә канәгатьләндерү мөмкин булган система итеп билгеләргә мөмкин.*

Әле акча барлыкка килгәннән күпкә элек, бик борынгы икътисад чорларында, ягъни натураль алмашу вакытында, кешеләр инде ничегрәк итеп файдалырак алмашу турында уйланганнар. Үзара файдалы алмашу — менә ул базар икътисадының чын башлангычы — бик борынгы заманда, кешеләр әле капиталның, табыш, милек һәм акчаның нәрсә икәнен белмәгәндә барлыкка килгән. Әмма инде үзләрендә тулып яткан товарны читләрдәге, аларда булмаганга алмашканда нинди файда алачакларын төгәл күз алларына китергәннәр.

Мең еллар үткән һәм бүгенге икътисад барлыкка килгән.

**ИКЪТИСАД** — көндәшлек механизмы аша үзара җитештерү, куллану, бүлү, товарлар һәм хезмәтләр алмашу мөнәсәбәтләренә керүче зур төркем кешеләрнең рациональ оештырылган эшчәнлеге.

*Көндәшлек кайдадыр һәм кайчандыр нәрсәгә дә булса дефицит булган урында һәм вакытта барлыкка килә.* Билгеле булганча, икътисади уңайлыклар — чагыштырмача сирәк була торган товарлар ул. Әгәр азык продуктлары һәм кием-салым, күңел ачу хезмәтләре һ.б. тулып ятса, аларга



кеше хезмәте кермәсә, алар барысы да, социаль уңайлык-рәхәтлекләр (күпчелек кешеләр теләгән әйберләр) булып калып, дефицит булмаслар, ягъни түләүсез булырлар иде. Димәк, алар икътисади уңайлык, ягъни акчага сатыла торган товарлар булудан туктарлар иде. Икътисад бары тик кешеләргә сирәк уңайлыкларны алуның иң рациональ һәм нәтиҗәле ысулы булганда барлыкка килә.

Базарда барысы да гади: акчаңны алып киләсең, тиешле бәяне түлисең һәм товарны алып китәсең. Әгәр акчаны каян алырга дип сорасагыз, эшләп табыгыз дип җавап бирерләр. Базар җәмгыятендә шулай ук дефицит товар булган хезмәт тә акчага сатыла. Һәркем үз хезмәтен сата, ә алынган средствога үзе теләгән нәрсәне сатып ала ала. Әгәр, бер караганда, сорауны һәм тәкъдимне стихияле рәвештә генә тигезли торган (чынлыкта исә күзгә күренгән хаос артында катлаулы оештырылган механизм ята) базар булмаса, дефицит уңайлыкларны миллионнарча кешеләр арасында дәүләткә бүләргә туры килер иде. Ә аның ничек эш итүен сез инде социализм мисалында беләсез.

Бүген инде бер генә җәмгыятьтә дә ике куян (бер-берсен кире кага торган уңайлыклар) артыннан куарга ярамаганны һәм аларның икесен дә тотып булмаслыкны һәркем аңлый. Аз җитештереп тә, күп кулланып, тупларны күпләп әзерләп тә, халыкны икмәк белән туендырып, икътисадның гражданлык секторын да, хәрби секторын да уңышлы үстереп булмый.

***Базар җәмгыятендә иҗтимагый җитештерү түбәндәге шартларда төзелә: а) ресурслар чагыштырмача сирәк; б) альтернатив уңайлыклар бер бөтенгә кушыла.*** Эшмәкәр үз бизнесын оештырырга карар кылды, ди. Фирмасын терки, бурычка билгеле бер күләмдә сумма ала (беренче капитал) һәм инде производствоны эшләтә башларга әзер. Әмма иң элек ул гади булмаган мәсьәләне хәл итәргә тиеш: ничек итеп шактый чикләнгән суммага (беренче дефицит ресурс) бер-берсенә каршы килә торган нәрсәләр алырга — бинаны арендага алган өчен түләргә, техника һәм җиһаз алырга, персонал ялларга? Барысы да акча таләп итә: хезмәткәрләрне күбрәк алдыңмы, җиһазларга акча аз кала һәм киресенчә. Чималны күбрәк алсаң, арзанрак, димәк, түбәнрәк сыйфатлы техника кулланырга туры



Альтернатив продукция җитештерү кире пропорциональ бәйлелеккә буйсына: бер продукт әзерләүне арттыру башкасын киметү исәбенә бара

киләчәк. Акчаның күбрәк өлешен чит ил җиһазы алуга тотсаң, персоналга түләп бетермәскә туры киләчәк, ә аның баш күтәрүе яисә башка предприятиегә китүе ихтимал.

Әйтик, эшмәкәр үз финансларын чыгымнарның барлык статьялары буенча уңышлы урнаштырды, ди. Аның артыннан яңа проблема килеп туа: нәрсә җитештерергә яки сатырга. Искә төшерик, акча — чикләнгән сумма. Әгәр сүз компьютерлар турында барса, «тимер»нең үзен дә, программа белән тәэмин ителешне, урнаштыруны да, ремонт белән хезмәт күрсәтүне дә комплектта аласы килә. Тегеләре дә, болары да акча сорый. Әгәр сез акчагызны берсенә тотсагыз, икенчесен чикләргә яисә бөтенләй алмаска туры киләчәк.

Җәмгыять белән дә шулай. Әгәр ул алдынгы хәрби фән дәрәҗәсендә булырга омтыла икән, акчаның шактый өлешен оборонага тотарга туры киләчәк. Дәүләт бюджеты, шәхси капитал кебек үк шактый чикләнгән. Икътисадта әйберләрне саклауның бик тә гади формуласы яши: бер урында артса, икенче урында кими. Әгәр ил үз җирләренең 10% ын көтүлекләргә яки хәрби полигоннарга бирсә, бодай үстерүгә яки торак төзелешенә нәкъ 10% җир кимрәк биреләчәк.

Шулай итеп, *җәмгыятьнең ресурслары чикләнгәндә һәм продукция альтернатив төрләрдә булганда, җәмгыять, предприятие кебек үк бер төр продукция чыгаруны икенчесен кимету исәбенә арттыра.*

Альтернатив продукциянең кире пропорциональлеге законы эшмәкәргә: ***бер төп продукция җитештерү өчен ресурсларны икенчесен җитештерүдән алырга кирәк, ди.*** Туплар һәм икмәк үзләрен җитештерү өчен акча таләп иткәндә генә үзара көндәшләр булалар, ә акча — чикләнгән күләмдә. Акча урынында эшче көч булырга мөмкин.

Шулай итеп, сез бер продуктны күбрәк күләмдә икенчесен кимету исәбенә аласыз. Гади товар җитештерү өчен әлеге күңелсез тенденция белән янәшә башкасы, шулай ук күңелсезе бара. Ул ***кими бара торган керем законы*** дип атала. Әлеге закон буенча продукциянең һәрбер өстәмә берәмлеген арттыра барып җитештерү физик хезмәтне, акчаны, нервларны һ.б. һаман саен күбрәк сарыф итү бәрабәренә ирешелә. Мөгаен, сизгәнегез бардыр: 4–5 сәгать ныклап эшләгәннән соң, алдагы һәр сәгать мәңгелек булып тоела. Ул арта барган киеренкелек исәбенә бирелә. Ашлама кертмичә һәм ял иттермичә һәр ел уңыш үстерүгә файдалансаң, җирнең уңдырышлылыгы да әнә шулай кими. Хезмәт һәм җирнең уңдырышлылыгы чикләнгән ресурслар булалар.

Җитештерү колачы арту яки «массакүләм җитештерүдәге экономия» нәтиҗәсендә керем керүнең артуы түбәндәге камилләштерүләр белән бәйле: 1) кешеләрнең һәм терлекләрнең мускул энергиясеннән тыш, энергиянең башка чыганакларын (су һәм җил, пар, электр энергиясе, турбиналар һәм эчке янулы двигательләр, атомның эчке энергиясе) куллану; 2) автоматлаштырылган үзкөйләүле механизмнардан (токарь станоклары, инструментлардан) файдалану; 3) үзара алыштырулы стандарт частьләр куллану; 4) катлаулы процессларны кабатланып тора торган гади операцияләргә бүлү; 5) вазыйфаларны махсуслаштыру һәм хезмәтне күпләгән башка технологик факторлар белән бүлү. Әлеге төрле факторлар кушылуының типик мисаллары булып автомобильләр җыюның конвейер системасы яки бүгенге эрләү һәм туку эше үсешенең тарихи юлы хезмәт итә ала.

Дөньяга конвейерның нәтиҗәлелеген беренче булып исбатлаган Генри Форд үз эшчеләрен автомобильләр һәм торак белән тәэмин итә, чөнки стандартлаштыру һәм күпләп җитештерү нәтиҗәсендә арзан һәм бик тә зур күләмнәрдә эшләп чыгара. Продукциянең чираттагы һәр берәмлеге аңа күбрәк түгел, ә азрак хезмәт куеп һәм азрак үзкыйммәт белән бирелә. Аш бүлмәсе пычагыннан башлап бүгенге компьютерга кадәр продукциянең бәясен кимету аны киң халык массалары сатып алырлык итә. Масса-күләм җитештерү Америкага матди муллыкны моңарчы күрелмәгәнчә үстерү һәм урта сыйныф санын арттыру мөмкинлеге бирә. Ә урта сыйныф булган җирдә товар һәм хезмәт күрсәтүләрнең киң ассортиментын күпләп кулланучы бар. Җитештерү арта — ихтыяҗлар киңәя, ә алар киңәйгән саен яңадан яңа индустрияләр барлыкка килә. Күпләп җитештерү җәмгыяте күпләп куллану җәмгыятенә әверелә. Индустриаль җәмгыять постиндустриальгә күчә. Баштарак әйтелгән *ихтыяҗлар — җитештерү — ихтыяҗлар* түгәрәге әнә шулай тәмамлана.

Капиталистик икътисад социалистик икътисад эшли алмаганны: ихтыяҗларның һәм җитештерүнең бер-берсе исәбенә түгел, ә бер үк вакытта үсүен тәэмин итә. Бик тә сакчыл һәм бер үк вакытта бик тә җитештерүчән булып була икән бит. Тагын да күбрәк тотарга һәм аннан да күбрәк алырга мөмкин. Чикләнгән ресурслар икътисадының котылгысыз бәҗрасы өзелә. Моны фән-техника прогрессының өр-яңа казанышлары тормышка ашыра. Иң заманча техниканы кертү тырышлыкны, акчаны һәм вакытны элек алар акылсыз сарыф ителгән урыннарда янга калдыру мөмкинлеге бирә. Техниканың һәр яңа буыны һаман саен күбрәк ресурсларны экономияли. Димәк, аны кертү файдалы бизнес булырга мөмкин. Техник прогрессның акылсыз тизлеге һәр нәрсәгә диярлек күнеккән кешеләрне шаккатыра. Компьютерларның яңа буыны базарга әле искеләрен сатып бетергәнче үк керә. Техника физик яктан искерми, мораль яктан искерә. Һәм бу да яңа кулланучылар артыннан куу. Россия дә керә барган базар җәмгыяте әнә шундый.

---

**Төшенчәләр:** *базар икътисады, көндәшлек, базар җитештерүе.*

---

**Сораулар һәм биремнәр**

1. Базар икътисадын гамәлгә ашыру һәм үстерү өчен нинди шартлар кирәк?
2. Кими бара торган керем законы нидән гыйбарәт?
3. Производствоның керемен нинди юллар белән арттырып була? Аларның берсен сурәтләгез.
*4. 70–80 елларда «арадаш дипломатиясе» дигән атама бар иде, ә 90 елларда яңасы — «алып-сату (челнок) бизнесы» дигәне барлыкка килде. Болар бөтенләй төрле төшенчәләр. Аларны аңлатыгыз.
*5. Элеккеге СССР икътисады структурасының 70% ы эре предприятие иде. АКШ икътисады структурасында 70% — урта һәм вак предприятие. Бу нәрсә турында сөйли? Мондый фактларны сез ничек аңлатыр идегез?
*6. Элеккеге СССРда 80 нче еллар ахырында хезмәткә яраклы халыкның мәшгульлек дәрәҗәсе дөньяда иң югары иде: ул 95% билгесенә кадәр күтәрелде. Шул уңайдан түбәндәге сорауларга җавап бирегез:
а) Мәшгульлекнең югары дәрәҗәсе нәрсә турында сөйли — ил икътисади үсешенең югары дәрәҗәсе яки түбәнгесе турындамы?
б) Халыкның мәшгульлек дәрәҗәсе югары булып та, эшсезлек була аламы? Әгәр була ала икән, нинди формада — ябыкмы, ачыкмы?
в) Билгеле булганча, 80 елларда мәшгульлекнең үсүе бездә производствога хатын-кызларны җәлеп итү исәбенә булды. Бу бала туу дәрәҗәсенә ничек тәэсир итте — уңаймы, әллә тискәреме?
7. Киметелгән бәяләрдән күбрәк кем ота — спекулянтмы, әллә кулланучымы?

**? Проблема.** Базар икътисадын үстерү өчен Россиядә кирәкле шартлар бармы?

**Практикум.** Сез бу фикерләр белән килешәсезме? Үз карашыгызны дәлилләгез.

Акча байлык кына түгел, кешелек дөньясы өчен зур бәла да.

Кайдадыр һәм кайчандыр нәрсәгә дә булса дефицит туса, көндәшлек шунда һәм шул вакытта барлыкка килә.

Алмашу акчалы формага кергәч, дөньяда сәүдә барлыкка килә.

Икътисад кешеләргә сирәк уңайлыкларны акыллы итеп урнаштырырга кирәк булганда гына барлыкка килә, ә базар андый уңайлыкларны алуның иң рациональ һәм нәтиҗәле ысулы буларак уйлап табылган.

Гади товар җитештерү борынгы Мисыр фиргавеннәре вакытында да, совет юлбашчылары дәверендә дә булган.

## § 10. Капитализм эволюциясе

Базар җәмгыяте сәүдә институтыннан барлыкка килгән. Сәүдәнең бүгенге формалары — кешелек цивилизациясенең меңьеллык үсеше нәтиҗәсе. Борынгы общиналар тормыш өчен кирәкле бар нәрсәне җитештергән. Ләкин алар да күршеләрдә тулып яткан кайбер нәрсәләргә кытлык кичергән. Аларга кирәкле әйберләр дефицитын *алмашу* капларга тиеш булган.

Беренчесен — дилетантлар, икенчесен профессионаллар эшли дип уйлап, алмашу белән сәүдәне ике төрле күренеш дип карап була. Әмма алмашуның (аның белән турыдан-турымы яки читләтепме Җирдәге барлык кешеләр шөгыльләнә) сәүдәгә әверелүе капитализмның урнашуы юлында тарихи адым була, хәзер исә әлеге һөнәрне аңа бөтен гомерләрен багышлаган сәүдәгәрләрнең махсус әзерләнгән катлавы гамәлгә ашыра. Ә бит эре капиталларны беренче булып кулларында тотучылар сәнәгатьчеләр түгел, ә сәүдәгәрләр, соңрак банклар, биржалар, базарларны оештыручылар була. Ләкин алмашу һәм сәүдәне капитализм күренешенең үсешендәге эзлекле ике фаза дип тә карарга була.

*Тигезгә тигезне генә алмашып була, әмма табыш белән сәүдә итәргә кирәк.* Сату итүчеләр — тарихта беренче профессиональ бизнесменнар, кешелек дөньясына табыш һәм спекуляция тәме сеңдерәләр. Чөнки бит сәүдәдә әйди торган стимул булып, бер урында арзангарак алдым, икенче урында кыйбаткарак саттым дигән принцип хезмәт итә.

Җәмгыять үсешенең һәр баскычында сәүдәнең роле арта бара. Дистәләрчә һәм йөзләрчә профессияләрдән

торган җәмгыятьләр (ә Борынгы Мисыр һәм Шумер җәмгыятьләре нәкъ шундый булалар) сәүдәсез яши алмыйлар инде. Сәүдәнең киңәюе борынгы империяләрнең мәдәни йогынтылары киңәю белән бергә бара. Финикия алфавиты дөньядагы күп халыклар язуының нигезенә нәкъ менә Финикия сәүдәгәрләренең ару-талуны белмәс эшчәнлеге нәтиҗәсендә салына. Ә Рим державасының бердәмлеге корал көче белән генә түгел, сәүдә элемтәләре белән дә кулда тотыла. Эшлекле сәүдәгәр — файдалы алыш-биреш өчен кая кирәк шунда барырга әзер торучы сугышчы — урта гасырлар халифәтенең характерлы фигурасы. Гарәп сәүдәгәрләре Үзәк Африкага һәм Төньяк Европага, Урал артына, Чукоткага һәм Камчаткага кадәр барып җитә.

> **СӘҮДӘ** — алмашуның ул акча формасын алган вакытта дөньяга килгән югары үскән формасы. Сәүдә — халыкларның аралашу ысулы да әле ул.

Башта сәүдә алмашу формасында булган, эквивалент сыйфатында сарыклар һәм үгезләр, соңрак металлар, барыннан да ешрак алтын файдаланылган.

Товар-акча мөнәсәбәтләре дәвере борынгы империяләр чәчәк аткан чорда башланган. Лидиялеләр бер үк зурлыктагы металл кисәкләрен әле б.э.к. VIII гасырда, ә греклар б.э.к. VII гасырда чын металл акчалар чыгарган.

Безнең борынгы бабаларыбыз *уңышлы сәүдә итү өчен милекне саклау һәм юридик законнар системасы кирәклеген* бик иртә аңлаган. Инде борынгы Вавилонда һәм Мисырда ук дәүләтнең суд эшләре алып баруга һәм үлем җәзасына монополиясен беркетә торган законнарның төрле тармаклы системасы урнаштырылган. Хаммурапи патша идарә иткән чорда сәүдәгәрләр һәм ростовщиклар (бурычка акча биреп торучылар) бары тик каһиннар һәм хәрби башлыклар куәтеннән генә кимрәк булган хакимияткә ия булганнар.

*Сәүдә шәһәр мәдәниятенә юл салган һәм алар икесе дә капитализмның үзенчәлекле чыганаклары булган.* Сәүдәдә зур уңышлыкларга ирешкән җәмгыятьләр сәясәт өлкәсендә дә уңышка ирешкәннәр. Бу антик шәһәр-дәүләтләргә дә, Яңарыш дәвереңнең Милан, Флоренция, Венеция кебек итальян шәһәр-коммуналарына да кагыла.



Иртә урта гасырлар дәверендә Төньяк Италия дөньякүләм сәүдә үзәге була. Диңгезләр аша ерак илләрдән кертелгән товарлар моннан әле римлылар ук салган иске юллар буйлап Европага барып ирешә. Италиянең төньягы Европа капитализмы туу урыны була. Сәүдә һәм банк капиталы (антик заманда кирәкле финанс институтлары булмау аркасында аның саклануы берничек тә гарантияләнмәгән) хәзер инде корпорацияләр, эквивалент акча курсы һәм икеләтә бухгалтерия исәп-хисабы барлыкка килгәч үсә башлый. XVI гасыр башына эре сәүдәгәрләр һәм банкирлар инде ярты Европаны финанслыйлар.

Урта диңгез мәдәниятенең мәҗбүри элементына әверелгән Рим гражданлык хокукы зур роль уйный. Тарихчылар фикеренчә, антик хокуктан файдалану капитализмның һәм шәһәрдә, һәм авылда үсүенә ярдәм итә.

*Сәүдәнең үсүе нәтиҗәсендә өченче катлау барлыкка килә.* Сәүдә итүчеләр һәм һөнәрчеләр, вакытлар үткәч, дворяннар белән крестьяннар арасында арадашчы урынны алып, шактый саллы сыйныфка әвереләләр.

Сәүдә шәһәр белән авыл арасындагы мөнәсәбәтләрне ныгыта. Сәүдә һәм сәнәгать үсү белән, крестьяннар үз продуктларын сату өчен тотрыклы базарларга ирешә. *Сәүдә капитализмы* дәвере сәнәгать үсүенә һәм өстәмә продуктны кабаттан булүгә пролог булып хезмәт итә, чөнки җитештерүнең төп тармакларында өстәмә продукт туплана, нәтиҗәдә хезмәт базарлары киңәя, халык саны арта, тормыш дәрәҗәсе күтәрелә.

Гәрчә капитализмның беренче үсентеләре Италиянең сәүдә шәһәрләрендә шытып чыкса да, аның барлыкка килүенең төп үзәге барыбер Англия була. XVI гасырда ул Европада иң көчле дәүләтләрдән саналмый, Италия һәм Франция аннан алда була. Ләкин аларның абсолют монархлар җитәкләгән иерархия системалары капиталистик мөнәсәбәтләрнең үсүе өчен җитәрлек киңлек бирми. Англия кечерәк һәм көчсезрәк була. XVI гасырда анда якынча 4–5 млн кеше — Испания халкының яртысы һәм Франция халкының дүрттән бере яши. Ләкин XVIII гасырда зур булмаган ил бәхәссез лидерга әверелә һәм бу рольне биш-алты буын гомере дәвамында уйный. Утрау державасының коры җир армиясе булдыру кайгысы булмый. XVI гасырда инглизләр бөтен тырышлыкларын башта — хәрби, аннары сәүдә флотын үстерүгә юнәлдерәләр. Гасыр ахырына Британия диңгезләр хуҗасына әверелә. Флот аңа колониаль сәүдәгә юл ача.

***Колониаль сәүдә — сәүдә институты үсешенең сыйфат ягыннан яңа, тагын да югарырак этабы.*** Гәрчә әле борынгы греклар үз ватаннарыннан читтә күпләгән колонияләргә нигез салсалар да, яңа икътисади стройга — капитализмга нәкъ менә инглизләр тормыш бирә. Флотны тотуга средство армияне тотуга караганда шактый кимрәк китә, парламент аны гадәти салым салып җыя. Диңгездә хакимлек итү Англиягә эре колониаль держава булу мөмкинлеге бирә. Аның флоты үзенә диңгезләрне генә түгел, диңгез сәүдәсен дә буйсындыра. Колониаль табышларның Англиянең милли икътисадына күчүе сәнәгать капитализмына юл ача.

Индустриаль капитализм үсешенең икенче факторы булып авыл хуҗалыгы производствосындагы яңа мөнәсәбәтләр хезмәт итә. Авыл хуҗалыгы Англиядә базар өчен иртәрәк эшли башлый.

Киң белемнәргә һәм сәүдә элемтәләренә ия булган җирбиләүчеләр аграр җитештерү алымнарын камилләштерү белән кызыксыналар. Фермер-арендаторлар хезмәтне махсуслаштырырга һәм бүләргә омтылалар, чөнки алар шулай итеп кенә арендага түли һәм җирсез хезмәткәрләр рәтенә күчүдән котыла алалар. Сәүдә һәм һөнәрчелек даими рәвештә буш эшче куллар таләп итә.

Сәүдәне үстерүдә *күпләп сатучылар* зур роль уйный. Алар базар белгечләре һәм бер үк вакытта тәэминатчылар булалар. Берәүләрне алар — йон һәм буяулар, икенчеләрне эрләү һәм туку машиналары белән тәэмин итә. Милли сәнәгатьнең төп тармагы йон тукымалар җитештерү — акрынлап бөтен илгә, шул исәптән авыл җирләренә дә тарала. Сәнәгать җитештерүенең хәрәкәтләндерүче көче — профессияләре сату-алу белән бәйле кешеләргә яхшы таныш булган табышка омтылу була. Табыш артыннан куу аркасында хәтта ялланган эшчеләр дә барлыкка килә.

Англиядә сәнәгать үсеше башта ук базарга йөз тота. Крестьяннар, башта йонны гаилә бюджетын тутыру өчен эрләп, өйдә профессиональ эрләүгә, аннары инде туку фабрикаларында эшләүгә күчәләр. Мамык белән сату итүчеләр тукыма фабрикантларына әверелә. XVIII гасыр ахырында туку станоклары, пар машиналары, фабрикалар һәм күмер шахталары саны нык арта. Туку сәнәгате нәтиҗәсендә кешелекнең бөтен тарихында иң күп капитал туплана. XIX гасыр башына Англиянең тукыма товарлары өчен бөтен дөнья — базарга, Лондон беренче миллионер шәһәргә әверелә. 10 млн инглиз һәм ирландлы Европаны ташлап китүгә карамастан, XIX гасырда ил халкы 4 тапкыр диярлек арта.

XIX гасыр ахыры — XX гасыр башында Көнбатышның алга киткән илләрендә эре сәнәгать һәм банк корпорацияләре барлыкка килә, финанс капиталы мөһим роль уйный, базар көндәшлеге дәүләтнең икътисадны җайга салу механизмнары белән тулылана. Тотрыклы социаль структура урнаша, анда шактый урынны эре милекчеләр һәм ялланган хезмәт эшчеләре белән беррәттән, милекчеләрнең урта сыйныфы ала.

*Ә Россия сәүдә капитализмы стадиясен* үттеме соң? Әле күптән түгел, XX гасырның 90 елларында, Россия эшмәкәрләренең 70–90% җитештерүчеләр түгел, ә арадашчылар булалар, ягъни коммерсантларның төп өлеше сәүдә белән шөгыльләнә. Сәүдә капитализмы фазасы аша сикереп үтеп булмый. Аны беренчел туплау стадиясен барлык илләр дә үтә. Әлеге стадиягә еш кына тупаслык, караклык, әдәпсезлек хас. Ул Европада да, Латин Америкасында да, Россиядә дә шулай була. Ләкин, Англиядән аермалы

буларак, Россия авыл хуҗалыгында капитализм стадиясен үтми. Рус крестьяннары һәрвакыт җәмәгать әгъзасы булуга өстенлек бирә.

Сәүдә капитализмы фазасы җәмгыятькә җиңел бирелә, монда соңыннан аларны сәнәгатькә тоту өчен кирәкле капиталны туплау җиңелрәк. Ул илдә сатарга мөмкин булган ресурсларның күпме туплануына һәм үз иленнең яки чит ил товарларын сатып алу өчен халыкта күпме акча туплануына карап дәвам итә.

Үзенчәлекле ярым криминаль этикалы сәүдә капитализмы фазасының дәвамлылыгы түбәндәге факторларга бәйле:

— илдә үзендә яки чит илләрдә файда белән сату мөмкин булган әйберләрнең (файдалы казылмалар, ярымфабрикатлар, фәнни уйлап табулар һ.б.) күпме булуы;

— намуссыз сәүдә итүчеләрне урынына утыртырга сәләтсез хөкүмәтнең никадәр йомшак булуы;

— каршы килмичә һәм протест белдермичә, халыкның криминаль сәүдәгә ни дәрәҗәдә түзеп торуы;

— сатып алучыларның, барыннан да элек урта сыйныфның кыйммәт чит ил товарларын сатып алуга ни дәрәҗәдә сәләтле булуы;

— кулланучы соравы өчен чит ил белән көндәшлек итүче илгә үз сәнәгатенең ни дәрәҗәдә көчсез яки көчле булуы;

— элитаның җәмәгать милкен бүлешүгә һәм ахыргача баерга өлгерүе.

Әгәр әлеге факторларның урнашуы ил өчен файдасыз булса (элита әле туенмаган, илдән чыгара торган байлык бар, халык һәм хөкүмәт криминалга түзеп тора), президентның бернинди указлары да, Дәүләт думасы закон проектлары да, хөкүмәтнең акча кертүе дә уңыш китермәячәк. Икътисадның бөтенләй дә объектив законнары бар. Аларны белергә кирәк.

Базар реформалары үткәрү өчен хөкүмәтнең акчасы беркайчан да җитми. Әгәр үзгәртеп коруларның башында «базар» романтикларының беренче буыныннан төзелгән хөкүмәт, дәүләткә бизнеска тыкшынырга туры килмәячәк, дип өмет итсә, соңрак, икътисад таркалган һәм халык массалары хәерчеләнгән, коррупция һәм җинаятьчелек, бәяләр

һәм эшсезлек арткан саен, Россия идарәчеләренең акыллырак фикер йөртүче икенче буыны хәлне ныграк контрольгә алырга тырыша. Хөкүмәт көч алымнары белән күләме арта барган салымнарны җыярга омтыла. Ләкин гади гражданнар һәм бизнесменнар, законны урауның әллә нинди юлларын уйлап табып, аларны түләүдән кача.

Безнең ил яңа юллар уйлап тапмый. Ул башкалар үткәнне кабатлый. Европаның барлык илләре сәүдә, аннары сәнәгать капитализмы стадиясен үткәннәр, барысы да башлангыч (талау) капитализмы стадиясеннән цивилизацияле базар стадиясенә күчкән. Ләкин бу эволюция Россиягә караганда акрынрак һәм эзлеклерәк барган. Якынча XX йөз уртасыннан башлап базар мөнәсәбәтләре үскән илләр планлаштыруны киң куллана башладылар һәм икътисадта дәүләтнең ролен көчәйтәләр. Катнаш дигән модельгә күчү (көндәшлек һәм планлаштыруның, базар һәм социализмның сыгылмалы кушылуы) Скандинавия илләрендә аеруча тирәнгә китә. Биредә халыкның мул яшәве турында чынлап торып кайгыртучы социал-демократик капитализм, дип раслыйлар. Чынлап та бу илләрдә, аеруча Швециядә, халыкның тормыш дәрәҗәсе шактый югары.

Дөрес, Россия социализмда булды инде, аңа шунда ук капитализмның иң биек баскычына атларга мөмкин булыр кебек иде, ләкин беренче баскычтан башларга туры килде. Өстәвенә һәр илнең капиталистик юлдан баруының үз тәҗрибәсе бар. Россиядә интеллектуаль потенциалның югары булуы гына бераз оптимизм өсти.

Шулай итеп, бүгенге капитализм — *катнаш икътисадның* бер тибы, биредә шәхси инициатива дәүләт күзәтчелеге астында үскән, көндәшлек монополь механизмнар йогынтысы белән чикләнгән. Мондый система ике өлештән — *базар һәм планлаштырыла торган* өлешләрдән тора. Базар өлешен вак фирмалар һәм шәхси предприятиеләр тәшкил итә. Бәяләре бары тик көндәшлек тарафыннан гына җайга салына. Планлаштырыла торган системалар — вак фирмалар эшенә һәм бәяләргә контрольлек итә торган эре корпорацияләр.

Капитализмның бүгенге формаларына түбәндәгеләр керә: дәүләтнең кыска вакытлы яки озак вакытлы җайга салуы; тәкъдим характерындагы тармак һәм төбәк про-

граммалары (планнары); турыдан-туры (закон яки административ актлар) һәм читтән торып (салымнар, дәүләт бюджеты чыгымнары, амортизация сәясәте) җайга салу. Күп илләрдә акрынлап урнашкан социаль юнәлтелгән базар икътисады һәм парламент демократиясе XX гасырның икенче яртысында халыкның тормыш дәрәҗәсен һәм мәдәниятен үстерүне, социаль каршылыкларны йомшартуны һәм аларны хәл итүнең хокукый механизмнарын эшләүне тәэмин иттеләр.

Хуҗалык тормышын интернациональләштерү, трансмилли корпорацияләрнең көчәюе нәтиҗәсендә төбәк һәм дөньякүләм икътисади интеграция, икътисадны дәүләтара җайга салу үсеш ала. Бу исә махсус оешмалар — Икътисади хезмәттәшлек һәм үсеш оешмасы, Халыкара валюта фонды, Халыкара камилләштерү һәм үсеш банкы, Европа бергәлекләре һ.б. барлыкка килүдә чагылыш таба. Алар безнең илгә базар һәм демократик үзгәртеп кору юлыннан барырга актив булышлык итә. Гәрчә аларның «тәрбия» алымнары (күрсәтмәләр, кисәтүләр, җиңнән тартулар) бик үк ошап житмәсә дә, безгә барыбер базар икътисадын өйрәнергә туры киләчәк.

---

**Төшенчәләр:** *алмашу, сәүдә капиталы, катнаш икътисад.*

---

**Сораулар һәм биремнәр**

1. Базар җәмгыяте кайчан һәм нәрсәдән барлыкка килә?

2. Сәүдә капитализмы фазасының дәвамлылыгы нинди факторларга бәйле?

3. Капитализм чагылышының бүгенге формаларын санагыз.

*4. Галимнәр кешелек җәмгыятендә хезмәт бүленешен үткән берничә глобаль стадияне аерып күрсәтәләр, алар:
*Беренче стадия* — хезмәтнең ир-ат белән хатын-кыз арасында җенес билгесе буенча бүленеше (палеолит дәвере).
*Икенче стадия* — хезмәтнең терлек асраучылар һәм җир эшкәртүчеләр арасында бүленеше (иртә дәүләтләр дәвере).

*Өченче стадия* — акыл һәм физик хезмәтенә бүленеш (өлгергән дәүләтләр дәвере).
Ни өчен галимнәр, нәкъ менә өченче стадия социаль мәгънәдә хезмәт бүленешенең беренче тарихи формасы, дип исәплиләр?
5. Нәрсә ул *капиталны башлангыч туплау?* Бу әйтемне ничек аңлыйсыз?
*6. Ни өчен нәкъ менә Англиянең туку сәнәгатендә кешелекнең бөтен тарихында яңа реформация үсүгә уңышлы булышлык иткән иң күп капитал тупланган?
*7. Ни өчен, әйтик, ростовщиклар яки акционерлар түгел, ә кешелек дөньясына табыш һәм спекуляция тәмен сеңдергән сәүдә итүчеләр тарихта беренче профессиональ бизнесменнар булганнар?
8. XVII гасырдан XX гасырга кадәр Европа капитализмы эволюциясенең төп сыйфатларын тасвирлагыз.

**? Проблема.** Бүгенге Россиядә сәүдә капитализмы стадиясе икътисадта уңай үзгәрешләргә китердеме, әллә, киресенчә, аны җимердеме?

**Практикум.** Ике белгеч Россиядә капитализмның үсеше турында сөйләшә. Аларның фикерләре капма-каршы. Менә алар:

1. «Икътисадның Көнбатыш үрнәкләрен төгәл кабатларга кирәк. Һәрвакыт, алардан йөз чөереп, без төзәтә алмаслык хата ясыйбыз. Кешелек дөньясы базар икътисадының иң яхшы принципларын: шәхси милекнең өстенлеген, эшмәкәрлекнең ирекле булуын, шәхес хокукларын, демократияне саклауны сынау, дистәләрчә тапкыр тикшерү һәм сайлап алу өчен күп эшләде».

2. «Россия шартларында Көнбатыш схемаларны механик күчерү шуның өчен генә дә мөмкин түгел, чөнки ул — яртылаш Көнбатыш, яртылаш Көнчыгыш держава. Чит мәдәниятләрдә эшкәртелгән әзер схемаларны күчергәндә без үз мәдәниятебезне исәпкә алмыйбыз яки инкарь итәбез. Барлык җәмгыятьләр бер-берсенә охшаш түгел. Аларның берсендәге уңышлы тәҗрибәнең икенчесендә шулай ук уңышлы булуына гарантия кайда?»

Сез кайсы фикергә өстенлек бирәсез? Җавабыгызны дәлилләгез.

## § 11. Хезмәт белән капитал арасындагы мөнәсәбәтләр

> **КАПИТАЛИЗМ** — төп өлеше чагыштырмача азсанлы кешеләр төркеменең шәхси милкендә булган җитештерү системасы; табыш алу өчен оештырылган җитештерү системасы.

Капитализмда эш түләүле хезмәт статусына ия, ә шөгыльләр хезмәт базары аша бүленә, биредә эшчеләр үзләренең белемнәре, күнекмәләре һәм физик көчләренә бәрабәр файда өчен хезмәт хакы түләргә әзер булган эш бирүчеләрне эзли.

Кешеләрнең иң күпчелек өлеше (мәшгуль халыкның дүрттән өче) ялланган хезмәткәрләр яки яллап эшләтүчеләр булган җәмгыять капиталистик дип исәпләнә.

*Индустриальгә кадәрге җәмгыятьтә мәшгуль халыкның күпчелеге аграр секторда* (авыл хуҗалыгында) эшли: биредә мәшгуль халыкның дүрттән өче — үзләрен үзләре яллаган яки гаилә хезмәте белән мәшгульләр, эш бирүчеләр. Индустриальгә кадәр җәмгыятьтә җитештерү системасының базисы индустрия түгел, ә гаилә хезмәтенә нигезләнгән кул һөнәре системасы була. Ул урта гасырлар Европасына хас.

Һөнәрчелек һәм индустриаль система арасындагы күчеш формасы *мануфактурага* (кул хезмәтенә) нигезләнгән *иске фабрика системасы* дигән нәрсә була.

*Һөнәрчелек системасы* — иртә, *мануфактура* соңгы урта гасырлар дәвере. Машиналарга яки индустриаль хезмәткә күчү Яңа вакытка күчүне аңлата. Һөнәрчелек системасы хәерчелек, тупас изү хас булган җәмгыятьтә яши. Һөнәрчелек системасында эшче белән эш бирүче арасындагы мөнәсәбәтләр шәхси буларак квалификацияләнә. Аларның бер-берсенә карата бурычлары бүгенгегә караганда тирәнрәк һәм киңрәк.

Һөнәрче эш коралларына һәм эш урынына ия була, чималны үзе сатып ала һәм әзер продуктны кулланучыларга үзе сата. Һөнәрче — ул ирекле ялланган хезмәткәрдән шуның белән аерылып тора да, җитештерү процессының бер өлешен генә түгел, ә бөтен технологияне белә һәм ничек кенә күп булмасын, теләсә нинди операцияне эшли ала.

Һөнәрне белгечлек дип түгел, ә профессия, ягъни өлешчә түгел, ә *тулы хезмәт* дип санарга кирәк. Һөнәрнең принцибы — барлык технологик чылбырны белү, тулы хезмәт циклын башкару өчен кирәкле барлык операцияләр, белгечлекләргә ия булу бүген хезмәтнең бары тик кайбер өлкәләрендә генә сакланып калган. Бизнесмен, табиб, менеджер, юрист, укытучы һәм кайбер башкаларның эшчәнлеге әнә шундый. Аларны — профессионаллар, ә башка төрле барлык хезмәт төрләрен белгечлекләр яки һөнәрләр дип атыйлар.

Һөнәрчелек системасын әле тагын *йорт җитештерүе* дип атарга була, чөнки монда эш һәм яшәү урыннары берләштерелгән. Россиянең күпләгән крестьяннары йорт фабрикаларында — җеп эшкәртелә һәм тукыма эшләнә торган гүрнәчәләрдә, кысан биналарда эшләгән.

Фабрика системасына күчү җәмгыятькә тамырдан социаль үзгәрешләр китерә. Беренчедән, яшәү урыны эш урыныннан аерыла. Җитештерүдә барлык катнашучылар — осталар да, аларның өйрәнчекләре дә моннан соң махсус биналарда — цехларда һәм фабрикаларда эшли башлый. Икенчедән, элек булмаганча, каты режим яки хезмәтне регламентлаштыру барлыкка килә. Эшче көчләрнең бер урында тупланую күп санлы кешеләрнең көйле эшләвен, төгәл кооперацияне таләп итә. Тәртип белән беррәттән өченче элемент — хезмәтне махсуслаштыру барлыкка килә.

> **ХЕЗМӘТНЕ МАХСУСЛАШТЫРУ** — бер кешенең бөтен хезмәт циклын колачламаган бер яки берничә операция башкаруы.

Гәрчә эшчеләр юридик яктан ирекле булсалар да, икътисади һәм социаль яктан эш бирүчегә бәйле. Җил, су һәм пар, шулай ук электр көчен файдалана торган машиналарның таралуы махсуслашуны тиранәйтә. Машиналар кул хезмәтенә караганда күпкә кыйммәтрәк, шунлыктан аларны производствога кертү капитал туплауны тәэмин итә. Тәҗрибәле һәм оста һөнәрчене тулы хезмәт циклының бер өлешен, ягъни *биремнәр* башкаручы ярым квалификацияле яки квалификациясез эшчеләр алыштыра.

*Хезмәтне ваклау* эшчеләрнең бер-берсе белән шәхси аралашуын кыскартуга китерә, алар эшлеклеләргә әйләнә.

Ниһаять, эшчеләр чималга, коралга һәм хезмәт продуктына хуҗа булу хокукларын югалта.

Һәрберсе бер-ике операция белән генә чикләнгән конкрет хезмәт төрләрен хезмәт бурычларына әверелдерү тормышта элек булмаган яңа күренеш китереп чыгара. Элек осталык булса, хәзер квалификация барлыкка килә. Эшләрне гадигә һәм катлаулыга бүлү, аерым гына башкарырга тиешле бурычлар барлыкка килү квалификациянең үзен китереп чыгара.

**КВАЛИФИКАЦИЯ** — нинди дә булса хезмәткә әзерлек, аңа яраклылык дәрәҗәсе.

Квалификация дәрәҗәсе күрсәткеч буларак кертелә, ул кагыйдәләрнең билгеле бер системасы нигезендә, цехтагы эшнең катлаулылыгын һәм җаваплылыгын исәпкә алып билгеләнә. Әлеге кагыйдәләр тариф-квалификация белешмәсендә теркәлә. ***Квалификацияле һәм квалификациясез хезмәтләр бүленеше барлыкка килә.*** Фабрика системасы белән бергә физик хезмәт (төрле эштә эшләүчеләр, квалификацияле эшчеләр) һәм акыл хезмәте хезмәткәрләре (хезмәткәрләр, җитәкчеләр) арасында хезмәтнең интеллектуаль бүленеше, шулай ук эш бирүчеләр — милек хуҗалары һәм эшчеләр — милексезләр арасында ***социаль бүленеш*** килеп чыга.

Капитализм вакытында хезмәт — ул *товар*. Башкача әйтсәк, хезмәткә билгеле бер сәләтләре (физик һәм психик яктан сәламәт) һәм профессиональ квалификациясе (әзерлеге, конкрет белгечлек буенча белемнәр һәм практик күнекмәләр) булган ялланган хезмәткәр эшмәкәргә билгеле бер түләүгә — хезмәт хакына алмашка үзенең эшче көчен тәкъдим итә. Соңыннан акчага сатарга һәм шуның нәтиҗәсендә түләү алырга мөмкин булган продукция әзерләп, кеше эшли. *Эш тә — шулай ук чыгымнарның тигез дәрәҗәдә кайтуын, ягъни түләү көтеп, үз энергиясен сарыф итү ул.*

Чыгымнарга тиңдәш кайтаруны көтү — түләүне көтү инде ул. Бер кеше икенче берәүгә туган көненә бүләк биргәндә ул ачыктан-ачык булмаса да, теге кешенең үзенә кайчандыр шундый ук бүләк бирүенә өметләнә. Сату-алу бүләк бирүдән шуның белән генә аерыла, алмашына торган әйберләрнең кыйммәте алдан ук билгеле һәм алмашу



уңаеннан яклар арасында телдән яки язма, формаль яки формаль булмаган килешү төзелә. Шунлыктан бүләк бирү — сату-алуның яшерен формасы ул.

Эш сату-алудан шуның белән генә аерыла, әйбергә — әйбер түгел, ә сарыф ителгән энергия алыштырыла. Минем кыйммәтле әйберем юк, ди кеше, әмма мин теләгән кыйммәтне алу өчен аның урынына эшләргә әзер. Мәсәлән, сез хрусталь ваза алырга теләдегез, ди, ләкин сезнең ваза бәясе кадәр акчагыз юк. Сез эшләп табарга, ягъни үзегезнең физик һәм акыл энергиягезне сарыф итәргә тәкъдим итәсез. Сезнең хезмәтегезнең бәясе хрусталь ваза бәясенә тиңләшә. Өстәвенә сез, кайчак, үз мөмкинлекләрегезне һәм көчегезне бәяләп, ваза хуҗасы белән сарыф ителәчәк энергия күләме турында алдан чамалап, яки сөйләшеп куясыз, килешәсез. Ваза белән хезмәт алмашуның асылы тигез кыйммәтләрне бәяләүдә: 500 сумлык ваза өчен миңа ничә сәгать һәм ничек эшләргә туры киләчәк.

Эшләрнең барлык төрләре үзенең *сыйфаты* буенча бәяләнә, нәкъ менә шуның өчен дә *эшнең сыйфаты* дигән төшенчә яши. Бу вакытта түбәндәгеләр искә алына: ***а) сыйфат, файдаланудагы ышанычлылык, хезмәт нәтиҗәсендә җитештерелгән ахыр продукциянең конструктив һәм эстетик кыйммәтләре, б) хезмәткәрнең профессионализмы, в) ул эшләгән фирманың абруе.*** Соңгысы әлеге фирманың элеккеге эшчәнлеге (базардагы вакыты, рекламацияләр, ягъни сыйфатсыз эш турында хәбәрләр,

клиентлары төплеме, әллә юкмы, һ.б.), фирманың кулланучылар массасы (аерым кешеләр түгел) алдындагы формаль булмаган абруе, матбугаттагы хәбәрләр, капитал әйләнеше, күләме һ.б. буенча бәяләнә.

***Хезмәткәрләрнең профессионализмы а) формаль квалификация, б) чын квалификация*** нигезендә бәяләнә. ***Формаль квалификация*** мәктәптә, көллият, вуз, квалификацияләр күтәрү курсларында һ.б. алган теоретик белемнәрнең уку йорты абруена тапкырланган (яки бүленгән) җыелмасыннан тора. Эш бирүчеләрнең бәясе, кагыйдә буларак, иҗтимагый фикер, ягъни күпчелек кешеләрдә вуз турында ныгып калган формаль булмаган абруй белән билгеләнә.

***Чын квалификация*** практик эш елларында вузда алган теоретик белемнәр өстәлгән практик күнекмәләр һәм осталыклар җыелмасыннан тора. Кагыйдә буларак, вуз белемнәре киләчәк эштә бары 15–20% кына файдалы. Калганнары киләчәктә алына һәм хезмәткәрнең хезмәт потенциалын (дәресрәге, аның бер өлешен) тәшкил итә. Әлеге потенциал хезмәткәр эшен югалткач эшли башлый һәм аңа, әйтик, философтан социологка әверелергә туры киләчәк. Ешрак уку йортында алынган белемнәр квалификацияне тулысынча үзгәртү өчен җитми һәм өстәмә белем алырга туры килә. Һәр хезмәткәрнең аңа рәсми органнар биргән һәм разрядларда, ранг, дәрәҗәләрдә билгеләнә торган тиешле сертификат белән беркетелгән квалификациясе бар (6 нчы разрядлы слесарь, 2 нче ранг капитаны, техник фәннәр кандидаты — квалификация исемнәре).

Квалификация асылда сыйфат характеристикасын, ягъни хезмәткәрнең осталыгын күләм ягыннан үлчәп карарга тырышудан тора. Квалификациянең микъдари үлчәме һәрвакыт шартлы һәм якынча. Мәсәлән, ике фәлсәфә фәннәре кандидаты формаль яктан тигезләр, әмма чынлыкта алар нык аерыла: берсе 40 мәкалә һәм 3 монография бастырган, ә икенчесе конференциягә тезислар әзерләрлек хәлдә дә түгел. Башка эшләрдә дә шундый ук хәл. Мәсәлән, әгәр беренче ранг капитаннарның авария ясавы статистикасын үткәрсәк, аларның барысы да, бер үк квалификация разрядына ия булып, корабльләр йөртүдә бөтенләй дә төрле осталык күрсәтә.

Квалификация башкарыла торган эшнең катлаулыгы белән билгеләнә. 1–2 разрядлылар күпчелек акыл түгел, ә физик хезмәт таләп итә торган гади, аз квалификацияле эш башкаралар. Киресенчә, 5–6 разряд белән эшләүчеләр акыл йөге физик йөктән өстен булган катлаулы, югары квалификацияле хезмәт белән мәшгульләр. Гади һәм катлаулы хезмәт йөкләмәнең характеры белән билгеләнә.

***Шулай итеп, кеше эшчәнлеге төре буларак, эштә катнашалар:***

— ***субъект,*** яки эшне башкаручы зат;

— ***объект,*** ягъни беренчесенең эшчәнлеге аны үзгәртүгә юнәлдерелгән предмет;

— ***средстволар,*** ягъни үзгәрешне гамәлгә ашыруда ярдәм итә торган инструментлар;

— ***эш урыны,*** ягъни объектны үзгәртү процессы өчен бирелгән бина яки киңлек өлеше;

— ***эш вакыты,*** куелган максат яки бурычка ирешелгән вакыт аралыгы;

— ***бурыч,*** эшчәнлекнең төгәл максатының техник атамасы;

— ***эш процессы,*** куелган максатка ирешү өчен үзара бәйле технологик эшләр җыелмасы (аларны шулай ук операцияләр дип атыйлар).

Капиталист өчен *эшче көчнең бәясе* — табыштан тотып калулар. Милекче эш бәясен (эшче көче бәясен) киметү ягында, чөнки ул хезмәткәрләрне үзенә файдалы вакытка гына яллый.

Эштән куылудан курку һәм эшсезлек янавы — яхшы эшләү өчен өстәмә стимул. Хезмәт эшченең квалификациясенә бәрабәр рәвештә генә түгел (квалификация югары булган саен хезмәт хакы да югары), әлеге хезмәт төренең базар бәясенә бәрабәр (белгечлек дефицитрак булган саен, ул югарырак бәяләнә) бүләкләнә. Конкрет белгечлекнең һәм конкрет квалификациянең базар бәясе түләү базисы булып тора.

*Хезмәт базарының* асылы шул — югарырак квалификацияле хезмәткәр түбәнрәк квалификацияле эшчегә караганда югарырак хезмәт хакы өчен сатулашырга киңрәк мөмкинлекләргә ия. Мондый мөмкинлекләр *базар тәкъдимен контрольдә тотарга* тырышу дип атала. Димәк, ква-

лификация югарырак булган саен югары хезмәт хакын сатулашып алу мөмкинлеге зуррак һәм базар тәкъдимен контрольдә тоту шул кадәр көчлерәк.

Һөнәрченең катлаулы кул хезмәте конвейер эшчесенең гади хезмәтенә тиңләштерелә. Индустриаль җәмгыятьтә өлешчә хезмәт — иң күп таралганы. Кул хезмәте тарихын, аның барышында эшче үз белемнәре һәм осталыкларына хуҗа булуын һәм аларга контрольне акрынлап югалта барган процесс итеп күзалларга була.

Фрагментлы бурычларны һәм хезмәтнең өлешчә төрләрен бер бөтенгә оештыра һәм берләштерә торган менеджмент белемнәргә монополия һәм хезмәт процессына контроль урнаштыра.

Хезмәт белән капитал арасындагы мөнәсәбәтләр кешеләрнең — ялланган хезмәткәрләрнең үзенчәлекле яшәү рәвешен формалаштыра. Хәзерге җәмгыятьтә алар күпчелек.

---

**Төшенчәләр**: *капитализм, махсуслаштыру, квалификация.*

---

**Сораулар һәм биремнәр**

**1.** Һөнәрчелек җитештерүе фабриканыкыннан нәрсәсе белән аерыла?

**2.** Эшнең сыйфатын нинди күрсәткечләр билгели?

**3.** Формаль квалификация белән чын квалификация нәрсәсе белән аерыла?

***4.** Кеше эшләрендә ни өчендер мондый законлылык яши: аварияне компетентсыз кешеләр ясый, ә аларны компетентлы хезмәткәрләр төзәтә. Аңлатыгыз, ни өчен шулай килеп чыга? Мисаллар китерегез.

***5.** Америкада кайбер профессияләрне яка төсе белән атыйлар.

— «зәңгәр якалылар»га эшчеләрне кертәләр, чөнки алар физик кул хезмәте белән мәшгуль һәм махсус зәңгәр кием кияләр;

— «ак якалылар» — хезмәткәрләр һәм белгечләр, алар галстук белән ак күлмәк кия;

— «алсу якалылар» — хатын-кыз-парикмахерлар, официантлар һәм сатучылар (халатларның төсе буенча аталганнар).

Бездә сатучылар һәм парикмахерлар нинди халат киярләр? Эшчеләр нинди халаттан йөри?

Безнең илдә кемне «кызгылт-сары якалы»ларга кертеп була?

***6.** Белгечләр бүген хезмәткә түләүдәге кыерсытулар турында күп сөйлиләр. Нәрсә ул? Артта калган илләрдә хезмәткә түләүдә кыерсытулар бар, алдынгыларында юк дип раслау дөресме? Җавабыгызны дәлилләгез.

***7.** Билгеле булганча төрле илләрдәге эшчеләрнең таләпләре бер-берсенә туры килми. 90 елларның беренче яртысында Россиядә җитештерү түбән төшкән чорда россиялеләр чын эш вакытын кыскарту түгел, ә озынайтуны яклап чыктылар, чөнки күп кенә предприятиеләр йә ябылды, йә кыскартылган эш атнасына эшләде.

АКШта һәм Көнбатыш Европада башка хәл. Күпләгән эшчеләр эш хакының элеккеге дәрәҗәсен саклаган хәлдә, эш вакытын кыскартуны таләп иттеләр.

а) Ничек уйлыйсыз, мондый чаралар эшмәкәргә файдалымы, юкмы?

б) Ул нинди шартларда эшчеләрнең таләпләре белән килешергә һәм аларны үтәргә мөмкин?

в) Ничек уйлыйсыз, мондый хәлнең киләчәктә безнең илдә булуы мөмкинме, әллә инде ул кайчандыр үткәндә мөмкин була алыр идеме?

**? Проблема.** Бүгенге дөньяда нәрсә күбрәк таләп ителә һәм бәяләнә — тар өлкәдәге осталыкмы, әллә киң специальләшүме? Үз фикерегезне дәлилләгез.

**✍ Практикум 1.** Билгеле ки, яшьләр, өлгергән һәм өлкән яшьтәге кешеләр хезмәткә төрлечә карый. Берәүләр өчен ул — «эштә вакыт үткәрү», икенчеләр өчен — гаиләне ашату һәм эш буенча үсү чарасы, өченчеләр өчен... Таблицаны тутырыгыз

*Таблица*

| Социаль төркемнәр | Алар өчен хезмәт нәрсә ул |
|---|---|
| яшьләр<br>өлкәннәр<br>картлар | |

Ир-атлар һәм хатын-кызлар турында да шуны ук әйтергә мөмкин. Ике зур социаль төркем үз эшләрендә нәрсә эзли? Ир-атлар һәм хатын-кызлар өчен хезмәт нәрсә ул? Тагын бер таблицаны тутырыгыз.

*Таблица*

| Социаль төркемнәр | Аларның һәркайсы өчен хезмәт нәрсә ул |
|---|---|
| хатын-кызлар<br>ир-атлар | |

**Практикум 2.** Өлкән сыйныф укучысы өйгә бирелгән эшне үтәде, анда ул төрле типтагы җәмгыятьләрнең икътисади характеристикаларын сурәтләде. Әмма укытучы аңа икеле куйды. Ни өчен? Бәлкем ул нәрсәне дә булса бутагандыр? Аның тырышлыкларының нәтиҗәсе таблицада чагылган.

*Таблица*

| | |
|---|---|
| Капиталистик җәмгыятьтә | кешеләрнең күпчелеге (мәшгуль халыкның дүрттән өче) сәнәгатьтә (индустриядә) эшли |
| Постиндустриаль җәмгыятьтә | мәшгуль халыкның күпчелеге аграр секторда (авыл хуҗалыгында) эшли |
| Индустриальгә кадәрге җәмгыятьтә | мәшгуль халыкның күпчелеге сәнәгатьтә түгел, ә хезмәт күрсәтү һәм мәгълүмат өлкәсендә эшли |
| Индустриаль җәмгыятьтә | кешеләрнең күпчелеге (мәшгуль халыкның дүрттән өче) ялланган эшчеләр яки яллап эшләтүчеләр |

# 4 бүлек
# Җитештерү сферасы

## § 12. Җитештерүче базарда

***Җитештерү — киң мәгънәсендә икътисади продуктларның төрле төрләрен булдыру процессы. Таррак мәгънәдә, матди җитештерү — матди уңайлыклар, хезмәт күрсәтүләр булдыру процессы күздә тотыла. Матди җитештерүнең нигезен сәнәгать тәшкил итә.*** Аңа матди җитештерүнең төп тармакларын — чимал чыгару, материаллар һәм энергия җитештерү һәм эшкәртү, машиналар эшләү белән шөгыльләнә торган предприятиеләрне кертәләр. Сәнәгатькә чималдан әзер продукция җитештерә яисә ниндидер файдалы хезмәтләр күрсәтә торган компанияләр һәм предприятиеләр керә. Ул җәмгыять таләп иткән барлык товарларны һәм хезмәт күрсәтүләрне булдыра һәм аларны кулланучыларга тарата. Әлеге илнең матди җитештерү өлкәсендә булдырылган бар нәрсәсе тулаем милли продуктка керә.

**ТУЛАЕМ МИЛЛИ ПРОДУКТ (ТМП)** — милли керемнең статистик күрсәткече, ул ахыр товарларның һәм хезмәт күрсәтүләрнең базар бәяләрендәге тулаем бәясен чагылдыра.

ТМПга халык кулланган товарлар һәм хезмәт күрсәтүләрнең, дәүләт сатып алуларының, капиталь салымнарның бәясе һәм түләү балансы сальдосы керә.

Сәнәгать — халык хуҗалыгының бик тә мөһим тармагы, җәмгыятьнең икътисади үсеше дәрәҗәсенә хәлиткеч йогынты ясый. Ике зур — *чыгару* һәм *эшкәртү тармаклары* төркемнәреннән тора. Сәнәгать шартлы рәвештә **җитештерү**

**средстволары җитештерүгә** (А төркеме) һәм **куллану әйберләре җитештерүгә** (Б төркеме) бүленә. Мисалга, автомобиль сәнәгате — машина төзелешенең җиңел һәм йөк автомобильләре, автобуслар, прицеплар, шулай ук аларның частьләрен, узел һәм агрегатларын җитештерә торган тармагы. Ул тулаем машина төзелеше кебек үк җитештерү средстволары җитештерү белән мәшгуль. Җиңел сәнәгать кием-салым, аяк киеме, баш киеме һәм киң кулланучы башка әйберләр җитештерү белән шөгыльләнә. Ул кешеләрнең ихтыяҗын канәгатьләндерә һәм куллану әйберләре җитештерүгә керә.

Җитештерүнең ике төркеме арасындагы нисбәт шундый ки, бары тик А төркеме генә илдәге фән-техника прогрессы үсеше дәрәҗәсен билгели. Ул — илнең визит карточкасы. Ләкин халыкның тормыш дәрәҗәсен һәм сыйфатын Б төркеме билгели. Әгәр ил тегесендә дә, монысында да булдыра алган икән, аны техник яктан үскән һәм матди яктан чәчәк ата торган ил дип әйтеп була. Ләкин шулай да булырга мөмкин, дәүләтнең барлык ресурслары диярлек фәкать А төркеменә генә, әле алары да күбрәк хәрби-сәнәгать секторына юнәлдерелгән, ә Б төркеме ресурсларның бик тә аз калдыгын алган. Нәтиҗәдә, гади халык интегә. Андый илне техник яктан үскән дисәләр дә, чәчәк ата торган ил дип атап булмый.

СССРда икътисад берьяклы гына үсте: җитештерүнең дүрттән бере — халык куллану товарлары, дүрттән өче — җитештерү средстволары. Боларның барысы да бүгенге Россиягә мирас булып калды. Без матди-техник ресурсларны — чимал, ягулык, энергияне, ахыр продукция бермлегенә цивилизацияле илләргә караганда, ике-өч тапкыр күбрәк җитештердек. Кыскасы, аларны бик тә әрәм-шәрәм итеп тоттык.

Тармакның башлангыч күзәнәге булып *предприятие — законлы рәвештә оештырылган мөстәкыйль хуҗалык субъекты* хезмәт итә. Предприятие юридик зат — акционерлык җәмгыяте, җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять (ҖЧҖ) һ.б. булып тора.

Базар икътисадына күптән түгел күчкән безнең илдә ике типтагы — *дәүләт* һәм *шәхси* предприятиеләр яши. Шәхси секторга күбесенчә кече предприятиеләр, ә дәүләтнекенә

сәнәгать гигантлары карый. Чынлыкта исә предприятиене шактый киңрәк аңларга кирәк.

Формалары буенча барлык предприятиеләр дә бары тик өч типка бүленә:

— **предприятие;**
— **фирма;**
— **тармак.**

**ПРЕДПРИЯТИЕ** — товарлар җитештерү һәм бүлү буенча бер яки берничә специфик вазыйфа башкара торган фабрика, завод, ферма, шахта, вак яки эре кибет тибындагы учреждение.

Үз чиратларында, предприятиеләр җитештерү цикллары буенча специальләшкән, әмма бер үк нәрсә белән, әйтик, автомобильләр җитештерү белән мәшгуль булган күпләгән *цехлардан* (тәэминат цехы, металлургия цехы, штамплау, транспорт цехы һ.б.) тора. Цех — предприятиенең төп җитештерү бүлекчәсе. Төп, ярдәмче, хезмәт күрсәтә торган, өстәмә цехлар була.

**ФИРМА** — предприятиеләрнең хуҗасы һәм аларда хуҗалык эшчәнлеге алып бара торган оешма. Еш кына бер эре фирма каршында берничә зур, уртача һәм вак предприятие була.

Мәсәлән, автомобиль фирмасының автомобильләр җитештерү предприятиесе, аларны ташучы транспорт предприятиесе, аларны сату челтәре һәм автомобильләргә хезмәт күрсәтү станцияләре системасы булырга мөмкин. Әлеге предприятиеләр характерлары һәм цикллары белән аерылалар, ләкин предметлары — автомобильләр белән түгел. Аларның барысы да бер тармакка карый.

**ТАРМАК** — бер үк төрле продуктлар җитештерә торган, охшаш технологияләр яки бер үк чимал куллана торган фирмалар төркеме. Тармакны ике критерий билгели: 1) продуктның охшашлыгы, 2) технологиянең охшашлыгы.

Икътисадның өч категориясен — предприятие, фирма һәм тармакны бүгенгечә аңлау шулай булырга тиеш. Әгәр аларның үзара бәйләнешен схема белән сурәтләсәк, түбәндәге картина барлыкка килә.

Теләсә кайсы илнең халык хуҗалыгы матрешкалар принцибында оештырылган: вағрак хуҗалык берәмлекләре — эрерәкләренә, ә алары тагын да эреләренә керә

Базар җәмгыятендә предприятиеләр (дәүләтнекеләр, шәхсиләр, акционерлык) һәм фирмалар базарда сорау туарга тиешле товарлар җитештерәләр һәм хезмәтләр күрсәтәләр. Башкача әйткәндә, фирма нәрсәдер тәкъдим итә, ә гади гражданнар (яки башка фирмалар) шуны сорый. Димәк, *фирма — тәкъдим агенты, ә кулланучы — сорау агенты булып тора.* Әгәр продукцияне беркем дә сорамый икән, аны чыгаруның да кирәге юк. Ул сатылырга тиеш. Базарның законы шундый.

Продукция ике һичшиксез шарт булганда сорала: югары сыйфат һәм кыйммәт булмаган бәя.

**Бәя** — *базарның чын диспетчеры.* Ул бирәүләргә (сатып алучыларга) — товарны ничек арзанграк сатып алу өчен, икенчеләргә (җитештерүчеләргә) кыйммәтрәк сату өчен продукцияне кая илтергә икәнен хәбәр итә. Шулай итеп, бәяләр, авиадиспетчер кебек җитештерүчеләргә һәм кулланучыларга маршрутларны төзеп бирә, әмма бу мар-

шрутлар капма-каршы якка юнәлдерелгән. Чынлап та, сатып алучы кайда арзан, ә сатучы кайда кыйммәтрәк икәнен эзли. Аларның икътисади мәнфәгатьләре шундый. Сорау һәм тәкъдим итү юнәлешләре маршрутларын нәкъ менә алар билгели дә инде.

Шулай итеп, базар икътисадында *бәяләр сорау һәм тәкъдим нисбәте белән җайга салына.* Бу исә өч состав өлеше нәтиҗәсендә барлыкка килә:

— сорауның күләме;
— тәкъдимнең күләме;
— сорау һәм тәкъдим нисбәте законы.

***Сорау күләме дигәндә товарлар һәм хезмәт күрсәтүләрнең сатып алучы теләгән һәм әлеге бәя буенча әлеге вакытта сатып алырга сәләтле күләм аңлашыла.*** Сорау — теләктән бигрәк, кулланучының продуктны яки хезмәт күрсәтүне билгеле бер урында һәм билгеле бер вакытта сатып алу мөмкинлеге.

***Тәкъдим, ягъни базарга һаман саен күбрәк санда товар ташлау, нигездә, производство факторлары: чималның күплеге, югары җитештерүчәнлек, түбән үзкыйммәт белән билгеләнә.*** Күбрәк табыш алу һәм персоналга эш хакын күтәрү өчен җитештерүче үз продукциясен мөмкин кадәр күбрәк җитештерү белән кызыксына. Ләкин кулланучыда сорау һәрвакыт чикләнгән. Кулланучының соравына бәйле рәвештә җитештерүчегә дә үз тәкъдимен чикләргә туры килә. Базар икътисадында җитеште-

рүче — хезмәтче, планлыда хуҗа иде, дәүләт 200 мең тонна чуенга заказ бирә, заводлар продукцияне сатып алырлармы, юкмы икәне турында борчылмыйча, аны әзерлиләр, чөнки товар алдан ул дәүләт бюджеты, ягъни безнең барыбыз тарафыннан түләнгән. Без моны телибезме, юкмы, продукция көчләп тагылган кебек булган. Базарда барысы да башкача, ошамый икән — алма. Ә предприятиегә безгә яраклашырга туры килә. Сатып алучы чуен алмый башлады, ә җитештерүче аны җитештерүне туктатты. Ул башкача эшли алмый: җитештерде → сатып алмадылар → бөлде — зыянлы эшнең чылбыры шундый. Аны базарның төп өч факторны: сорау, тәкъдим, бәяләрне үзара бәйли торган билгеле законы идарә итә.

***Сорау законы бәяләрне һәм һәр бәядә сатып алыначак товарлар һәм хезмәтләр күләмен бәйләп тора.*** Ул башка шартлар тигез булганда товарларны югары бәягә караганда түбәнрәк бәя белән күбрәк сатып булачагы турында сөйли.

Товарларга бәя күтәрелсә, җитештерүчеләрдә аларны югарырак бәя белән дә күбрәк чыгару теләге туа. Өстәвенә алар эчтән генә бу товарга сорау кимемәячәк дип нык ышаналар. Чөнки һәр җитештерүче үзе турында гына уйлый (хәер, кулланучы да шулай). Ул үз көндәшләренең нинди карар кабул итүләрен белми. Ә алары нәкъ шулай ук эшли, чөнки бәянең үсүе — күпләп эш итү өчен стимул. Бер типтагы продукция җитештерүчеләр барысы да: бәяләр үсү артында сорау үсү яшеренгән дип уйлыйлар. Ул шулай да. Тузан суырткычларга сорау артмаса, бәяләр дә артмас иде. Ниндидер бер вакытта базар туена: кемгә кирәк, тузан суырткычны барысы да алган, ә предприятиеләр аларны чыгаруны дәвам иттерә. Сорау кими, продукция сатылмый, предприятиеләр зыян күрә.

Уңайсыз хәлдә калмас өчен тәҗрибәле эшмәкәр базарга тәҗрибә партиясен чыгара һәм аның ничек таралуын карый. Нашир укучыга таныш түгел авторның китабын беркайчан да 100 меңлек тираж белән чыгармаячак. Ул 2–3 меңнән башлый. Базарның реакциясен күзәтә. Әгәр сату тиз бара икән, бу — зур тираж өчен сигнал. Китап акрын таралса, ашыкмаска мөмкин, тагын бер азрак тираж биреп була.

Тәҗрибә тиражы алдыннан газета һәм журналларда кызыклы китап барлыкка килүе турында анонс бирү әйбәт. Заявкалар киләчәк, ләкин алар күп булмаячак. Әмма тираж запас белән чыгачак, чөнки заявкалар — потенциаль һәм реаль сату базарының бер өлеше генә. Сәнәгать товарлары өчен юлны **реклама** һәм продукциянең тәҗрибә серияләре сала. Реклама кампаниясе киңрәк булган саен, әлеге товар кирәк булган барлык сатып алучыларның аның турында ишетү ихтималы шулкадәр зуррак. Реклама — теге яки бу продукцияне җитештергәндә тәвәккәллекне сынау ысулларының берсе.

Капма-каршы вазыйфаны базарда **маркетинг** башкара. Реклама аша тәкъдим бик үк көчләп тагылмый, ә маркетинг аркасында сорау сак кына капшап карала.

**МАРКЕТИНГ** (инг. marketing, market — базар) — предприятиенең, базарны комплекслы анализлауга нигезләп, җитештерү-сату эшчәнлеге белән идарә итү системасы.

### Маркетинг тикшеренүләре

Маркетинг тикшеренүләре — тиз үсә торган юнәлеш. Гәрчә алар АКШта әле XX гасыр башында барлыкка килсәләр дә, Америкада һәм Европада икенче бөтендөнья сугышыннан соң гына сизелерлек урын алдылар. Россиядә алар 90 нчы елларда актив кулланыла башлады.

Бүгенге оешмалар кешеләрнең нәрсә теләве һәм ни өчен шуны теләве турындагы мәгълүмат белән һаман саен күбрәк кызыксына. Маркетинг тикшеренүе үткәрү «кулланучы фикеренә колак салу» дигән сүз. Аларны тагын базарны тикшеренүчеләр дип атыйлар. Продукцияне күпләп җитештерүче фирмаларның аларның клиентларының кем булуын беләселәре килә. Аларны каян табарга? Аларның ихтыяҗлары нинди? Соңгы ун елда бөтен дөньяда бәяләрнең әлеге чагыштырмача яңа тармагына чыгымнар өч тапкырдан күбрәккә артты һәм 5 млрд долларга җитте. Маркетинг тикшеренүләре аша сатучылар үз товарларының һәм үз рекламаларының нәтиҗәлелек бәясен алдылар. Бары тик алар аша гына кире элемтә гамәлгә ашырыла: товар клиентны канәгатьләнде-

рәме һәм ул сатып алучыны көндәшче товарына караганда яхшырак канәгатьләндерәме?

Шул рәвешле, маркетинг тикшеренүләреннән башка бүгенге базар була алмый. Алар яңа товарларны һәм хезмәтләрне проектлауда, аларны яхшырак итеп таратуда һәм рекламалауда төп рольне уйныйлар. Ә иң яхшы ысул — адреслы тарату, тырышлыкларны кулланучыларның максатчан төркемнәренә туплау, әлеге товар билгеләнгән кешеләрне эзләү. Бу — «базарны сегментлау» принцибы. Кулланучылар турында тулы мәгълүмат алу өчен алар яши торган мохит, алар кабул иткән яшәү стиле, әйләнә-тирә, дөньядагы үзгәрешләр турында белергә кирәк, үз чиратында, товарларга һәм аларның модельләренә ихтыяҗ нәкъ менә шулар аркасында үзгәрергә мөмкин. Күрегез, космоска карата арта барган кызыксыну кием һәм мебель стилен ничек үзгәртте, хром тышлык һәм ачык буяу яшьләргә мотоцикллар сатуны ничек арттырды! Шул хакта да уйлагыз: туризм һәм чит илләргә бару мөмкинлекләре арту безнең туклану рәвешенә нинди йогынты ясады. Һәм шул чакта бүгенге бизнесның маркетинг тикшеренүләреннән башка яши алмавын аңларсыз.

---

**Төшенчәләр:** *тулаем милли продукт, предприятие, фирма, тармак, сорау һәм тәкъдим законы, маркетинг.*

---

**Сораулар һәм биремнәр**

**1.** Кайсы төшенчә — предприятиеме, әллә фирмамы — киңрәк һәм ни өчен?

**2.** Нәрсә ул тәкъдим? Бер предприятие икенче предприятиегә булган бурычын каплау бәрабәренә вәгъдә ителгән акча урынына keләмнәр партиясе җибәрсә һәм, аларны сатып, алынган акчаны бурыч исәбенә исәпләвен сораса, бу тәкъдим иту буламы?

**3.** Сорау законы эчтәлеген үз сүзләрегез белән аңлатыгыз. Ә ни өчен ул бәяләр белән һәр бәя вакытында сатып алыначак товарлар һәм хезмәтләр күләме арасындагы бәйләнешне сурәтли, ә товарлар белән хезмәтләр арасындагы бәйләнешне түгел?

***4.** Сез иске диваныгызны сатарга уйладыгыз һәм белдерү элдегез, ди. Һәм берничә төрле урында. Сез нәрсә эшләдегез:
Тәкъдим формалаштырдыгызмы?
Сорауны ачыкларга телисезме?
Актив маркетинг белән шөгыльләнәсезме?
Дефицит товар сатасызмы?
Җавабыгызны дәлилләгез.
**5.** Маркетинг бурычларын сез ничек аңладыгыз? Маркетинг тикшеренүләренең үзенчәлеге нәрсәдә? Нәрсә ул базарны сегментлаштыру? Сезгә маркетинг белән очрашырга туры килдеме? Маркетинг турындагы мәгълүматны сез каян алдыгыз — матбугат һәм телевидениедәнме, туганнарыгыз һәм танышларыгызданмы?

**? Проблема.** Базар икътисады шартларында фирманың тотрыклы хәлен һәм чәчәк атуын гарантияләргә сәләтле факторлар бармы?

**Практикум.** «Безнең хуҗалык Көнбатышта искиткеч нәтиҗәләр биргән алымнарны кабул итми: иң табигый икътисади чаралар бездә көткән нәтиҗәләрнең киресенә китерә. Бәяләр арта һәм алар белән бергә сорау да; бәяләр үсә, ә тәкъдим шул урында тора; средстволар җитештерүне киңәйтергә бирелә, ә дефицит көчәя һ.б.» *(В. Данилов-Данильян)*.

Сораулар:

1. В.Данилов-Данильянның сүзләре безнең җәмгыятьнең алдагы биремдә сурәтләнгән базарга күчеш чорларының кайсысына карый? Әгәр мөмкин булса, җавабыгызны дәлилләгез.

2. Җәмгыять базарга дөрес күчкәндә нәрсә булырга тиеш?

3. Безнең илдә 90 елларда базарга күчкәндә җибәрелгән хаталар исемлеген тутыра аласызмы?

## § 13. Эшмәкәрлек һәм бизнес

Производство турында сөйләгәндә, чимал табу, техника һәм станоклар эше, продукция әзерләү технологиясен саклау, аны сыйфатка сынау, шулай ук предприятиеләр һәм цех-

ларның структурасы, хезмәтне оештыру һәм продукцияне сату, тармак үзенчәлеге һ.б. белән бәйле чиста техник күренешне күздә тоталар. Һәм монда социаль һәм икътисади караштагылар бик аз кертелә. Башкача әйткәндә, производство турында *эшмәкәрлек* буларак сөйләнми. Гәрчә совет предприятиесе директорыннан шактый *эшлеклелек* таләп ителсә дә, эшмәкәрлек социализм вакытында юк иде.

Ике төшенчәне тикшерик. ***Эшлеклелек — җитезлек, булдыклылык, катлаулы хәлләрдән чыга белү, буш урында нәрсә дә булса оештыру осталыгы һ.б. хас булган характер сыйфаты, үзеңне тоту ысулы.***

**ЭШМӘКӘРЛЕК** — җәмгыятьнең закон белән ныгытылган һәм регламентланган, төгәл оештыру һәм хокукый структурасы, парламентта үз вәкилләре, шулай ук төрле фондлары, эшмәкәрләрнең мәнфәгатьләрен яклаучы хәрәкәтләре, партияләре һәм ассоциацияләре булган социаль һәм икътисади институты.

Эшмәкәрләр — җәмгыятьнең мөстәкыйль социаль һәм икътисади төркеме. Эшмәкәрлек — барча характерлы билгеләре булган аерым эш стиле, яшәү рәвеше, аерым субмәдәният ул.

**Эшмәкәрләр** дип табыш алуны күздә тотып, үз эшен булдырган һәм аның белән идарә итүче кешеләрне атыйлар. Табышка омтылу — аларның төп максаты. Табыш алу өчен эшмәкәр кирәкле продукт булдырырга, нәтиҗәле технология эшләргә, производствоны финансларга һәм про-

дуктны үзкыйммәтеннән югарырак бәягә сатарга тиеш. Эшмәкәрләр бизнеска уңышның гарантияләнмәгәнен, эшләр планлаштырганча бармаса, акчаларын югалту ихтималын белә торып киләләр. Статистика күрсәткәнчә, өч яңа предприятиенең икесе беренче 4 елда бөлгенлеккә төшә. «Эшмәкәр» сүзе еш кына кече предприятие хуҗасын билгеләү өчен кулланыла, чөнки ул производство белән идарә итүнең күп кенә вазыйфаларын үзе башкара. Эре бизнеста оештыру һәм производствоны идарә итү бурычларын ялланып эшләүче күпләгән менеджерлар башкара.

Еш кына эшмәкәрлек белән бизнес төшенчәләрен бутыйлар. Әмма бу ике күренешнең асылы төрле. Инде әйтелгәнчә, эшмәкәрлек яңаны ачудан тора: яңа продукт, аны сатуның яңа ысулы, яңа базар, эшчәнлекнең яңа өлкәсе. Бизнеста, гомумән яңа юллар уйлап табу таләп ителми. Аңа тапталган юлдан бару уңайрак. Коммерциягә китү башкалар шөгыльләнгән һәм уңышка ирешкән файдалы эш белән шөгыльләнү дигәнне аңлата. Йөзләрчә яшь кеше дилер, брокер, коммивояжер булырга омтыла. Монда эш характеры бухгалтерныкы яки сатучыныкы кебек үк, ул билгеләне кабатлаудан тора. Табиблар, укытучылар, юристлар һәм килеп туган проблемаларны яңача хәл итәргә туры килгән башка бик күпләр эшмәкәр булмаган кебек, көтелмәгән хәлләрдә яңа карарлар кабул итүче менеджер да эшмәкәр түгел.

Акча белән эш итү эшмәкәр булу дигән сүз түгел, иске бурычларны хәл итәргә яңа юллар эзләргә кирәк әле. Үзенең идеясе дә, үз капиталы да булмаган, ләкин беренчесе белән икенчесен бергә кушуда һәм табыш алуда үзенең элек бер кем дә кулланмаган практик ысулын тапкан кеше — эшмәкәр була ала. Ул яңа идеяне һәм чит капиталларны практик гәүдәләндерүнең үзенчәлекле технологияләрен таба.

Эшмәкәрнең эшчәнлек өлкәсе — **кече бизнес**. Кече бизнес ул — такси, йөк ташу, складлар, радиостанция, иминиятләштерү, күчемсез милек, банклар, ваклап һәм күпләп сату, балык тоту, кунакханәләр, чәчтарашханәләр, реклама, типографияләр, автозаправкалар, аяк киеме, чәчәк кибетләре һ.б. Кече предприятиеләрнең күп өлеше хезмәт күрсәтү һәм ваклап сату өлкәсендә эшли.

***Кече бизнесның аерым билгеләре:***

— ***тулаем активлар*** — кулдагы средстволар, товар-матди запаслар, җирләр, машиналар, җиһазлар һәм предприятие карамагындагы башка ресурслар;

— ***шәхси капитал*** — инвесторлар биргән тулаем капитал салулар. Корпорациядә инвесторлар — акцияләр алучы гадәти акционерлар ул;

— ***сатудан кергән еллык табыш;***

— ***эшләүчеләр саны.***

Кечеләр категориясенә элэгү өчен предприятиенең билгеле бер күләмдә ялланган хезмәткәре булырга, ул бәйсез хуҗага карарга (икенче бер предприятиенең бер өлеше булмаска), мөстәкыйль идарә ителергә тиеш. АКШта яңа эшчеләр урынының 80% ын 100 һәм аннан да азрак хезмәткәр эшли торган предприятиеләр тәэмин итә. Уртача алганда вак җитештерүчеләр үз капиталларына эреләренә караганда күбрәк табыш ала. Кече бизнес зур фирмаларга караганда, бер эшләүчегә исәпләгәндә 2 тапкыр күбрәк яңалык кертә.

Кече предприятиеләрнең эреләренә караганда ни өчен уңышлырак эшләве, безнең дәүләтнең ни өчен аларны үстерүне хуплавы сәбәпләренә түбәндәге факторларны кертергә мөмкин. Беренчедән, кече предприятиеләр эреләренә караганда базар үзгәрешләренә, товарларны һәм хезмәтләрне, технологик процессларны үзгәртүгә тизрәк һәм чыгымнарны азрак тотып җавап бирә ала. Икенчедән, кече бизнес талантлы кешеләрне үзенә тагын да күбрәк җәлеп итә башлады, димәк, аның интеллектуаль потенциалы төп персоналны югары, урта һәм түбән квалификацияле эшчеләр тәшкил иткән эре предприятиеләрнекенә караганда уртача югарырак.

Өченчедән, үзләрен үстерү өчен кече предприятиеләр бюджет чыгымнары таләп итмиләр (чөнки шәхси).

Дүртенчедән, бөлгенлеккә төшкән дәүләт предприятиеләре казнадан үзләре акча алып торган бер вакытта, алар дәүләткә салымнар җыюның өстәмә чыганагы булып торалар. Бишенчедән, кече бизнес өстәмә эш урыннары бирә.

Яңа товарлар уйлап табу һәм яңа эш урыннары булдыру сәләте аркасында 80–90 елларда кече бизнесның абруе бөтен дөньяда күтәрелә башлады. Ул барлык илләрдә —

икътисадның цементы, ә җәмгыять өчен демократиянең икътисади нигезе булып исәпләнә.

Дөрес, кече бизнесның үзе хәл итү алмый торган үз проблемалары да бар, алар:

— тәвәккәллек һәм уңышсызлыкларның югары күрсәткече;

— идарә итү тәҗрибәсе булмау;

— законнарның камил булмавы;

— рәкет;

— зур салымнар;

— көчле көндәшлек;

— начар сәүдә;

— кредит бәясенең югары булуы.

Тагын шунысы да билгеле, икътисади кризислар кече бизнеска зурларына караганда авырттырыбрак суга; керемнәр тизрәк төшә, ә бөлгенлеккә төшү ихтималы югары. Бүгенге производствода кадрларны дөрес сайлау кайчак хәлиткеч рольне уйный. Ләкин кече предприятиеләрдә еш кына аңа җитди игътибар итмиләр, кадрлар туганлык критерийлары буенча сайлана. «Гаилә бизнесы» әйтеме бездә икеләтә мәгънә алды: а) туганнарның кечерәк коллективы мәшгульлеге формасы, б) эшкә читтән түгел, ә «үз» кешеләрен урнаштыру. Кече бизнеста хезмәт бүленеше дә башкача төзелә: тар белгечлекләр таләп ителгән эре предприятиеләрдән аермалы буларак, монда хезмәткәр күп профильле булырга тиеш. Тәҗрибә күрсәткәнчә, икенчеләрен табу беренчеләрен табуга күпкә караганда катлаулырак. Аның каравы аларның эш хаклары да югары.

Кече предприятиеләрдән аермалы буларак, дәүләтнекеләр эрерәк инвестицияләр таләп итә. Шул сәбәпле бүген Россиянең кайбер эре завод-фабрикалары эшсез тора. Икенче явызлык шунда яшерелгән ки, эре предприятиеләр авыр хәрәкәт итә, базарның үзгәреп тора торган шартларына һәм сорау кимүгә җайлаша алмый. «Совет тибы»ндагы эре предприятиеләргә капитал салулар турыдан-туры дәүләт бюджетыннан бирелде, шунлыктан хәзер алар мөстәкыйль яшәргә һәм көндәшлек итәргә өйрәнмәгән. Завод директорларын күп санлы инструкцияләр һәм карарлар аякларыннан бәйләп торган социализм вакытында эшмәкәрлек үсә алмады. Директорлар эшмәкәрлекнең төп ике




шартына — икътисади маневр ирегенә һәм шәхси милеккә хокукка ия була алмадылар.

Зур (корпорацияләр) һәм кече бизнес (эшмәкәрлек) куелган максатка төрлечә оешкан килеш ирешәләр. Корпорациядә тәвәккәллек катнашучылар арасында бүленә. Аның җитәкчеләре бары үз урыннарын гына куркыныч астына куя, алар шәхси капитал салуларын югалтмыйлар. Эре бизнес гаять тә зур ресурслар белән эш иткәнлектән, кече бизнестан аермалы буларак, уңышсызлык еш кына аны ябуга китерә. Күп катлы хакимият пирамидалары булган эре корпорацияләр яңалыклар кертү һәм шәхеснең ирекле эш итүе мөмкинлекләрен чикли.

**Бизнесны оештыру формалары** — ялгыз хуҗа булу, ширкәт яки корпорация.

Ялгыз хуҗа булганда, милекче предприятиенең бөтен табышын үзенә ала, ул үзенә үзе хуҗа. Барлык бурычлар һәм бизнес белән бәйле проблемалар аның җилкәсенә төшә. Әгәр бизнес бөлгенлеккә төшсә, милек хуҗасы барлык бурычларны түләргә тиеш. Бу исә шәхси милекне — машина, йорт, саклык акчаларын югалту дигән сүз. Кимчелеге — капиталның чикләнгәнлеге, чөнки эшкә салынырга мөмкин булган акчалар хуҗаның саклыктагы акчалары суммасы һәм кредит алу мөмкинлеге белән чикләнгән.

Шундый барлык предприятиеләр бик кечкенә. Аларның популярлыгы максималь гадилекләре һәм бизнесны оештыруның арзанлыгы белән аңлатыла.

**ШИРКӘТ** — ике яки берничә хуҗасы булган предприятие.

Партнерларның берләшүе өстәмә средстволар җәлеп итү мөмкинлеге бирә. Һәр партнерга чикләнмәгән милек җаваплылыгы йөкләнә, ул ширкәт йөкләмәләре буенча шәхси җавап бирә. Бизнес бөлгенлеккә төшсә, аның кредиторлары средстволарны һәр кешедән аерым да, барлык партнерлардан бергә дә кайтаруны таләп итә алалар. Ширкәтнең капитал күләме милек, партнерларның мул яшәве һәм кредитны түләү сәләте белән билгеләнә.

> **КОРПОРАЦИЯ** — предприятиене оештыру формасы, анда милеккә хокук акцияләр буенча өлешләргә бүленгән, шунлыктан корпорация хуҗалары акция тотучылар дип аталалар.

Суд корпорацияне юридик зат дип таный. Ул судка мөрәҗәгать итә, судка бирелә, контрактлар төзи, салымнар түли ала. Шәхси хуҗадан һәм ширкәт әгъзаларыннан аермалы буларак, акционерның иң күп дигәндә югалтыр нәрсәсе (ягъни аның шәхси йөкләмәләре) — ул акцияләр өчен түләгән сумма. Җаваплылыкның чикләнгәнлеге шундый да мөһим булып чыга ки, АКШтан тыш, инглиз телле илләрнең күпчелегендә корпорацияләр үз исемнәренә Ltd (чикләнгән) аббревиатурасы өстиләр. Акция тотучылар, аларны сатып алып, корпорациядән чыга яки аңа керә ала. Корпорациянең ширкәттән өстенлеге шунда. Кимчелек итеп теркәлү кыенлыкларын күрсәтәләр. Корпорацияне оештыру бик кыйммәт һәм катлаулы. Предприятиене һәм уставны теркәү еш кына юрист ярдәмен сорый. Ялгыз хуҗалар яки ширкәтләр оештырып, күпчелек кече фирмалар андый чыгымнардан качарга тырыша. Моннан тыш, корпорацияләр махсус салымнар да түләргә тиеш. Гәрчә корпорацияләрнең саны ялгыз хуҗаларныкына караганда 4 тапкыр диярлек кимрәк булса да, Америка икътисадында нәкъ менә алар өстенлек итә. Халыкка акцияләр һәм облигацияләр сатып, эре корпорацияләр үз капиталларын арттыра.

**Акционерлар** корпорацияләрнең хуҗалары булып тора. Ачык типтагы корпорацияләрдә акционерлар саны (акцияләре ачык сатуда булганнарның) йөзләрчә яки меңнәрчә булыга мөмкин. Кайбер корпорацияләр миллионнан артык акция хуҗаларыныкы булып санала.

Илнең төрле өлкәләрендә меңнәрчә милектәше булган эре корпорацияләр нәтиҗәле идарә итү механизмына мохтаҗ. Корпорациянең эшчәнлеге белән акционерлар сайлаган директорлар советы җитәкчелек итә.

*Директорлар советы* компания белән идарә итү өчен *президентны* һәм башка рәсми затларны сайлый. Гәрчә *хуҗа булу һәм идарә итү зур корпорацияләрдә бүленсә дә,* акционерлар, үзләренең тавыш бирү хокукларын гамәлгә ашырып, идарә итүдә читтән торып катнаша ала. Алар моны компания сәясәтенең принципиаль мәсьәләләре турында сүз чыкканда эшлиләр.

Акционерларда булган һәр акциягә бер тавыш туры килә. Тавыш бирү, гадәттә, корпорациянең еллык җыелышында үткәрелә. Җыелышта катнаша алмаган акционерлар башка бер кешегә үзләренең акцияләре буенча тавыш бирергә, ышаныч кәгазе тапшыра ала. Ачык корпорация директоры ел саен еллык отчетын басып чыгара, анда аның финанс хәле, ел эчендәге казанышлары, киләчәккә планнары һ.б. турында мәгълүмат була.

---

**Төшенчәләр:** *эшмәкәрлек, бизнес, кече бизнес, ширкәт, корпорация, акционерлар.*

---

**Сораулар һәм биремнәр**

**1.** Кече предприятиеләрнең чәчәк ату сәбәпләрен атагыз.

**2.** Кече бизнесның төрле формаларының төп өстенлекләрен һәм кимчелекләрен формалаштырыгыз.

**3.** Кемне эшмәкәр, капиталист һәм менеджер дип атыйлар? Алар арасындагы аерма нәрсәдә?

***4.** Бер үк төрле ике коммерция кибетендә 100 товардан торган көнлек ассортимент бар. Товарларның уртача бәясе **А** кибетендә — 150 сум, **Б** кибетендә — 300 сум. **А** көн саен 20 исемдәге, **Б** 10 исемдәге товар сата.
Кибетләрнең кайсында товар әйләнеше активрак, керем күбрәк? Аларның һәрберсе күпчелек халыкның кайсы төркемнәренә (аз тәэмин ителгән, уртача яки югары тәэмин ителгән) хезмәт күрсәтә?

**5.** Нәрсә ул эшмәкәрлек тәвәккәллеге?

**6.** Кече бизнесны оештыруның төп формаларын тасвирлагыз.

***7.** Һәр ил үзе өчен тышкы базарда да эчке базарда файдаланган монополиясен урнаштырырга омтыла. Көндәшләрне тышкы базардан кысрыклап чыгару өчен илләр бик тә төрле алымнар куллана. Матбугатны һәм телевидениене файдаланып, аларны сурәтләп бирегез.

**? Проблема.** Нинди дә булса продукцияне алып, кабат сатуны кече бизнес дип исәпләп буламы?

**Практикум 1.** Америка социологлары мәгълүматларына караганда, 1966 елдан 1973 елга АКШ халкында бизнеска һәм бизнесменнарга ышаныч дәрәҗәсе 55 тән 27% кадәр төшкән. Баштарак америкалылар, бизнес аларның икътисади хәлләрен генә түгел, ә югары әхлакый кыйммәтләрен дә саклаучы булып тора дип ышанганнар. Әмма акрынлап күңелләре кайткан (И. Берг).

Ә Россиядә эшмәкәрләргә мөнәсәбәт ничек үзгәргән? Гомумән дә үзгәргәнме? Бу темага фикер йөртегез.

**Практикум 2.** Шәхеснең эшмәкәрлек белән шөгыльләнү өчен кирәкле сыйфатлары исемлеген төзегез. Үзегез сайлаганны аңлатыгыз.

## § 14. Базар икътисады инфраструктурасы

Әгәр тиешле финанс инфаструктурасы булдырылмаса, предприятие һәм фирмалар базар икътисадында уңышлы эшли алмыйлар. Аны актив эшчәнлекне һәм базарны яклауны тәэмин итә торган үзара бәйле институтлар җыелмасы тәшкил итә. ***Инфраструктураларның нигезен өч элемент — базар, биржа, банк булдыра.***

Сатучыларның нәрсә тәкъдим итүенә бәйле рәвештә, *базарлар сату предметы буенча махсуслашалар.* Мәсәлән, халыкның ярлы катлавы *толкучка* яки *базарда* тотылган нәрсәләр — иске сәгать, иске кием, төрле кадак, ачкыч, йозак һ.б. сата. Саллы фирмалар продукцияләренең яңадан барлыкка килгән үрнәкләрен күрсәтәләр һәм, аларны рекламалап, потенциаль сатып алучыларны *ярминкәләрдә һәм күргәзмә-сатуларда* алар белән эре партия товарларга килешү төзергә чакыралар. Шәһәрнекеләр *күпләп сату базарларында* кибетләрдәгегә караганда түбәнрәк бәяләргә иң кирәкле — ярма, май, яшелчә, ит һәм балык әйберлә-

ренең зур булмаган партияләрен сатып ала. Ә *кыйммәтле кәгазьләр базарында* яисә фонд биржасында акцияләр сата һәм сатып алалар.

**Биржа** (голл. beurs, нем. Borse) — *стандартлар яки үрнәкләр буенча массакүләм товарларны күпләп сату базарының (товар биржасы), шулай ук кыйммәтле кәгазьләр, чит ил валютасы (фонд биржасы), эшче көчләр (хезмәт биржасы) базарларының даими эшли торган иң нык үскән формасы.*

Иркен һәм алдынгы җиһазлар белән җиһазланган биналарда көне буе сәер һәм аңлашылмаган телдә, ишарәләр ярдәмендә, компанияләр, товар партияләре, валюта, файдалы казылмалар, акцияләр һәм хәтта эшче көчләр белән җанлы сату-алу бара. Рәсми *фонд биржаларында* бары тик эре компанияләр акцияләре белән генә операцияләр рөхсәт ителә.

Андый учреждениеләрдә *брокерлар* һәм *дилерлар* эшли.

**БРОКЕРЛАР** (ингл., бер. с. broker) (маклерлар) — арадашчылык итү биржа операцияләренә махсуслашкан аерым кешеләр яки фирмалар; моның өчен алыш-биреш суммасыннан билгеле бер процент формасында түләү алалар.

**ДИЛЕРЛАР** (ингл., бер. с. dealer) — кыйммәтле кәгазьләрне, валютаны, төрле товарларны сатып алу, сату белән шөгыльләнә торган аерым кешеләр яки фирмалар.

Алар үз исемнәреннән һәм үз исәпләренә эш итәләр. Дилерның табышы сатучы һәм сатып алучы бәяләренең (курсларның) аермасыннан, шулай ук бәяләрнең (курсларның) вакытка карап үзгәрүеннән формалаша.

### Биржаның тууы

Борынгы заманнардан ук партнерны табу, базарның хәле турында күзаллау һәм товарларга соңгы бәяләрне белү өчен сәүдәгәрләр бер урында җыелган. Сәүдәгәр җыеннары Борынгы Римда б.э.к. II гасырда теркәлгән. Флоренциядә андый җыеннар турында XIII гасырдан телгә алына. Севильяда сәүдәгәрләр һәр көн кафедраль собор баскычларында; Лиссабонда — Яңа урамда; Генуяда — Банк урамын-

да; Ла-Рошельдә — Пти Банк һәм Адмиро урамнары чатында; Лейпцигта — нинди дә булса аркада астында, ярминкә лавкасында яки зур үлчәүләр янында ачык һавада җыелган. Биржа тибындагы бу җыеннар үзләренең актив сәгатьләрендә һәрвакыт диярлек шау-шулы тыгыз төркем тамашасын хәтерләткәннәр.

Билгеле бер урында даими сәүдә очрашулары тәртибен урнаштырып, оештыручылар товарны үзең белән алып килү зарурлыгы юк, бары тик бәя турында гына килешергә кирәк, калганы техника эше дигән нәтиҗәгә килгәннәр. Биржа җыеннарында бер үк вакытта иминиятләштерү мәсьәләләре хәл ителгән, вексельләр кабат сатылган, сәүдә алыш-бирешләре билгеләнгән. Урта гасырларның сәүдә җыеннарыннан бүгенге тип биржага акрынлап күчелгән.

«Биржа» сүзе үзе Фландриянең эре сәүдә шәһәре Брюггеда туган, анда кызыксынган кешеләр борынгы һәм намуслы ыруг вәкиле сеньор ван де Бурсе исеме белән аталган «Бурсе» кунакханәсе янында җыелганнар. Чит ил коммерсантлары, Брюггега килеп, кунакханәдә тукталганнар, анда башка сәүдәгәрләр белән танышканнар, үзара килешүләр төзегәннәр, уңышлар һәм банкротлыклар турында яңа хәбәрләр белгәннәр. Күп кенә сәүдәгәрләр килешү төзү өчен «Бурсе» кунакханәсенә килергә тиеш булганнар. «Бурсега» бару әйтеме шул кадәр гадәтигә әверелә, коммерсантлар үз илләренә кайткач та аны, гомумән, сәүдә җыеннарын аңлату өчен куллана башлаганнар, гәрчә моңа Лионда биржаның «Алдаулар мәйданы», Ганзей шәһәрләрендә — сәүдәгәрләр коллегиясе, Барселонада Лохия дип аталуы да комачауламаган. Биржа өчен беренче махсус бина 1531 елда Антверпенда төзелә.

Биржага бәяләр һәм базар конъюнктурасы турындагы мәгълүмат бөтен дөньядан агыла. Биржа маклерлары товарлар бәясенә йогынты ясый торган барлык яки күпчелек факторлар һәм товар запасы турындагы мәгълүматны системалаштыралар. Алар төрле базарларда бәяләрнең тир-




бәлүе, сорау һәм тәкъдим күләме турында белеп торалар. Бәяләргә инфляция, илләрнең һәм дөньяның төрле базарларында бер үк товарларга бәяләрнең нисбәте, аларны җитештерү дәрәҗәсе, технологиядәге үзгәрешләр, эре сәяси тетрәнүләр, мәсәлән, революция, сугыш, хөкүмәт алышыну, президентның отставкасы, шулай ук табигый бәла-казалар (мәсәлән, корылык аркасында ашлык уңмау) йогынты ясый.

Базар инфраструктурасына шулай ук *күпләп һәм ваклап сату предприятиеләре, аукционнар, ярминкәләр, арадашчы фирмалар, иминият компанияләре, фондлар, аудиторлык фирмалары, реклама агентлыклары, юридик конторалар һ.б. керә.*

Акчалар төп звеносын банклар (итал.— banco — эскәмия, алмашу лавкасы) тәшкил иткән катлаулы финанс системасы аша тупланалар һәм бүленәләр.

> **БАНКЛАР** — акча средстволарын һәм тупланмаларны җыя, кредит бирә торган, акча исәп-хисапларын, вексельләр исәбен, акчалар һәм кыйммәтле кәгазьләр эмиссиясен, алтын, чит ил валютасы операцияләрен һ.б. гамәлгә ашыра торган учреждение.

Ул алмашу өлкәсендә тагын бер икътисади институт. Халыкның иң зур күпчелеге банклар турында кертемнәр кабул итә һәм ссудалар бирә торган теләсә нинди финанс институтын күзаллап сөйли. Банкларның төп вазыйфасы — кертемнәрнең, фондларның саклануын тәэмин итү һәм ссудалар чыганагы булу.

Банклар — кертемнәр кабул итә һәм кредитлар бирә торган финанс арадашчылары. Алар бу рольне акчаларын кертемчедән бурычка алучыга, ягъни акчаларын киләчәккә калдырырга теләүчеләрдән аларны хәзер файдаланырга теләүчеләргә биреп үти. Кешеләр үз акчаларын банкка алар моны теләгән минутта ук кире кайтарып алачакларын белеп салалар. Алар тагын шуны да белә: акчаларның янгыннан һәм талаудан физик саклануыннан тыш, банклар кертемнәр буенча страховка да бирә.

Безнең организмыбызда кан аны тереклек көче белән тутырып, барлык тамырлары буйлап үткән кебек, банклар акчаларны икътисадның барлык финанс артерияләре буенча куалар, аңа көч һәм сәламәтлек бирәләр. Түләүләрнең һәрбер туктатылуы тамырлар томалануга тиң, бу исә, билгеле булганча, кире төзәтә алмаслык нәтиҗәләргә китерә. Шунлыктан банкларның эшчәнлеге икътисадның нормаль эшләве өчен бик тә мөһим. Коммерция кредитлары фирмаларга агымдагы счетларны түләү һәм чыгымнарны финанслау мөмкинлеге бирә. Ссудалар халыкка товарларны, алар өчен булачак эш хакларыннан түләп, хәзер сатып алырга ярдәм итәләр.

Банклар һәм саклау институтлары керемендә төп статьяларның берсе — кредит һәм ссудалардан килгән *процент*. Икътисадны акча белән тәэмин итә торган банклар аны предприятиеләргә һәм шәхси кешеләргә процентлар өстәп бирәләр. Соңгыларга бу һич тә файдалы түгел, чөнки бер елдан алып торган сумманы өстәлгән процентлар белән түләргә туры киләчәк. Бурычка алучылар моңа ни өчен бара соң? Аларга бәлага тарган кеше кебек ук, яңа канны иртәгә түгел, бүген кертергә кирәк. Кыйммәтле акчаларны банктан, әйтик, бер елга алып, фирма үзенең эшләре алга китәр һәм ул барысын да түләр дип өметләнә. Шулай итеп, банк кредитларына фәкать бәлагә тарган бурычка алучылар гына мөрәҗәгать итә.

*Банклар ике юл белән барлыкка килгән: а) акча алыштыру, б) ювелирлар һәм саклау, ягъни бүгенге ломбард аша.* Банкларга башлангыч әле XII гасырда ук ул вакыттагы иң көчле сәүдә иле — Төньяк Италиядә акча алыштыручылар эшчәнлеге белән салына. Ул вакытта һәр шәһәрнең үз металл акчасы (монетасы) була. Сәүдә әйләнеше өчен даими

алмашу кирәк була һәм моның белән билгеле бер бүләк өчен акча алыштыручылар шөгыльләнә. Алар еш кына акча алыштыру вазыйфасын тиешле монетаны билгеле бер вакытта бирү шарты белән ала. Аларга үз клиентларыннан кредит алырга туры килә. Соңрак алар, кертемнәрне саклауга алып, үз эшчәнлекләрен киңәйтәләр. Шуннан соңгы баскыч вексельләр чыгару һәм акчалар күчерү була.

Кәгазь акчаларны Көнбатыш цивилизация әле урта гасырларда ук куллана башлый. Ул вакытларда акчаларның төп формасы транспортлау өчен уңайсыз, әмма каракларны җәлеп итә торган алтын һәм көмеш акчалар була. Эшлекле операцияләрне куркынычсыз итү өчен сәүдәгәрләр үз монеталарын җирле ювелирларга китерә башлаган, тегеләре аларга ышаныч язуы (ышанычнамә) биргән. Шулай итеп, ювелирлар урта гасырларның банкирларына әверелгән. Сәүдәгәрләр товарларга түләгән өчен ышаныч язуларын теләп кабул иткәннәр, чөнки аларны ювелир остаханәләрендә алтынга алыштыра алганнар. Вакытлар үтү белән ювелир эшләре осталарының ышаныч язулары бик тә зур акчалар белән эш итүче сәүдәгәрләрдә һәм сәяхәтчеләрдә популярлык казана. Нәтиҗәдә, бу язулар Көнбатыш Европада кәгазь акчаларның иң беренче формасы булган.

Баштарак ювелирларның ышаныч язулары тулысынча алтынга алыштырылган, ягъни резервларда билгеле бер күләмдә алтын булуын белдергән. Шулай да, вакытлар үткәч ювелирлар, салына торган акчалар күләменең алар ала торган суммалардан артып китүен сизгәннәр. Бу исә кертем салучылары алтынының бер өлешен процентлар белән биреп тору уена китергән. 1587 елда Венециядә беренче җәмәгать банкы ачылу — шундый банкларны бөтен Европада булдыруның башлангычы була. Кертемчеләр өчен ихтимальый тәвәккәллекне киметеп, банклар сәүдә операцияләренә җанлылык кертә. Банкларның капиталы кертемнәрдән тора, ә аларның күләме игълан ителми. Банклар үз кертемчеләренең счетларын алып баралар, вексельләр кабул итәләр һәм кредитлар бирәләр. Амстердам банкы XVIII гасыр ахырынача эшли һәм Европа илләренең купчелегендә сәүдәгәр һәм сәнәгатьчеләрнең тулы ышанычын казана.

Россиядә беренче кредит банкы 1863 елда Санкт-Петербургта ачыла, ә беренче дәүләт банклары әле Елизавета вакытында 1754 елда барлыкка килә. АКШта беренче дәүләт банкы 1781 елда ачыла, ә XX гасыр башында шәхси коммерция банклары өстенлек итә. Россиядә бу вакытта кире процесс бара: вак шәхси банкларны эреләре йота. Англиядә беренче эре кредит учреждениесе — Англия банкы — 1694 елда булдырыла. Ләкин банкларның ватаны булып Италия санала: Италия банклары — дөньяда беренчеләр, ә Италия банкирлары — дөньядагы барлык банкларны башлап җибәрүчеләр. Алар моннан Англиягә үтеп керәләр, аннары инде бөтен дөньяга тарала.

Банклар илдә булган ирекле капиталларның шактый өлешен үзләрендә туплый (пассив операцияләр) һәм аларны үз әйләнешләрен киңәйтүгә мохтаҗ эшмәкәрләр кулына бирә (актив операцияләр). Банклар аерым фирма һәм эре бизнесменнар кассаларында булган, шулай ук гади гражданнар кулында хәрәкәтсез яткан барлык капиталларны җыярга тырышалар. Акча акча «эшләргә тиеш» дигәнне истә тотып, банклар аларны процент белән саклауга, ягъни үстерә барып бирергә тәкъдим итәләр. Акчалар 3 яки 5% арта, чөнки алдан билгеләнгән срок эчендә банклар аларны берничә тапкыр «әйләндерә». Аңлашыла ки, банклар үз кертемчеләренең барлык акчаларын займга бирә яки «әйләндерә» алмый, чөнки беренчеләр үз средстволарын теләсә-кайсы моментта кире сорарга мөмкин. Мондый очракта страховка өчен *банк резервлары* була. Аларның күләме депозитларның тулаем күләменә процент нисбәтендә чагыла һәм *резерв нормасы* дип атала. Ул 15–20% тәшкил итәргә мөмкин.

Банклар ничек баый? Алар кертемчеләрнең акчасын мохтаҗларга — гражданнарга яки фирмаларга бирәләр, ләкин срок ахырында вәгъдә иткәннәреннән тагын да югарырак процентка кире кайтаралар. Ссуда бирү «акча җитештерү» өчен кирәк. Банк эшли ала торган акчалар суммасы вакытның һәрбер билгеле моментында ул күпме акча бирергә ихтимал булган резерв нормасы белән чикләнә. Һәм монда: *арзангарак алдым, кыйммәткәрәк саттым* формуласы эшли. Банклар әнә шул аермага яши дә.

Банклар күпләп акцияләр сатып алу һәм сату белән шөгыльләнә. Сәнәгать эшмәкәрләре дөньясы белән элемтәләреннән файдаланып, алар бик теләп яңа барлыкка килгән сәнәгать предприятиеләренең акцияләрен урнаштыралар, шулай ук аларның хуҗасы булырга теләгән кешеләр өчен акцияләр сатып алалар. Банклар акцияләр чыгару белән эчкерсездән шөгыльләнми. Һәр чыгарылыштан алар *оештыру кереме* калдыра.

Банклар биржа уенында (банкара биржа) мөстәкыйль катнашалар һәм, асылда, биржаның төп җитәкчеләре булалар. Алар предприятиеләрдәге чын хәлләр турында барысыннан да яхшырак белә, ясалма сорау тудырып, теге яки бу кәгазьне сатып алу өчен зур суммалар бирә, бәяләрне күтәрә яки аларның биржа курсын төшереп, үз портфельләреннән зур күләмдә кәгазьләр чыгара ала.

Күтәрүгә һәм төшерүгә биржа уены — банклар өчен иң кыйммәтле кәгазьләрне һәм акцияләрне үзендә туплау ысулы. Банклар бизнесменнар арасында арадашчылар булу белән генә чикләнми, алар үзләре сәнәгать предприятиеләренә хуҗалар яисә аларда күпмедер күләмдә катнашалар. Мәсәлән, революциягә кадәр Россия металлургия заводларының гомуми җыелышларында тавышларның иң күпчелеге берничә коммерция банкына туры килә. Аларның портфельләрендә шул юл белән банклар милегенә әверелгән дистәләрчә сәнәгать предприятиесе акциясе ята. Банклар сәнәгать предприятиеләре акцияләренә салган капитал — финанс капиталы дип атала. Ул сәнәгатьне банкларга тулы буйсынуга куя.

Банклар тулы канлы һәм тынгысыз тормыш белән яши. Алар кушылалар һәм ереләнәләр, бөләләр һәм йотылалар, киңәяләр (филиаллар оештыралар), халыкара мәйданга чыгалар, аларның счетларына арест салырга мөмкиннәр, дәүләт аларга бөтен җитәкчелекне үз кулына алган вакытлы администрация билгеләргә мөмкин. Банклар файдалы сәяси һәм криминаль элемтәләр яклавына таяналар, берберсе артыннан шпионлык итәләр, компьютер хакерларыннан камил электрон яклану булдыралар, финанс пирамидалары төзиләр, бурычка алалар һәм түләмиләр, алдыйлар, базар җәмгыятендә гадәти кешеләр эшләгәннең барысын да, әмма шактый зуррак күләмнәрдә эшлиләр.

Үзләрен тотуның барлык модельләреннән банклар кушылуга өстенлек бирәләр. Алар фирмалар, предприятиеләргә караганда үзара азрак көндәшлек итә. Производствога үтеп кереп, банклар үзләренә караган бер үк төрле сәнәгать предприятиеләре арасында бернинди көндәшлек булмасын өчен тырышалар. Алар элек төрле хуҗаларныкы булган бер иш предприятиеләрне бер хуҗалык берәмлегенә кушарга тырышалар. Шуның белән банклар сәнәгатьнең синдикатлар һәм трестлар оештыру омтылышларын яклыйлар.

---

**Төшенчәләр:** *базар, биржа, банк, брокерлар, дилерлар.*

---

**Сораулар һәм биремнәр**

1. Базар икътисадының инфраструктурасын тасвирлагыз. Аңа нәрсәләр кирәк?
2. Биржаның төрләрен тасвирлагыз.
3. Бүгенге банкларның төп вазыйфаларын һәм операцияләрен атагыз.
4. Банклар ничек баый?

*5. Ни өчен кайбер кешеләр акчаларын өйдә саклауга өстенлек бирәләр? Мондый караш нигезлеме?

*6. 1917 елда хакимияткә большевиклар килгәч, беренче декретларның берсе банкларны национальләштерү турында була. Бу ни өчен эшләнә? Әлеге декретның мөһимлегенә бәя бирегез.

**? Проблема.** Икътисади реформалар дәвере банкларның үсүенә ярдәм итәме яки аларны бөлгенлеккә илтәме?

**Практикум.** 1903–1914 елларда башкала банклары провинция банкларын бик тиз үзләренә буйсындыралар һәм аларны үз филиалларына әвереләдерәләр. Шундый ук процесс 1995 елда башлана, барлык шәһәрләрдә периферия банкларының кыска вакытлы үрчүеннән соң, аларны башкала гигантлары йота башлый. Россиянең Үзәк банкы кредит каналларын яба. Сәбәбе: йөзләрчә ялган банклар берничә миллион россияленең ышанычын алдый һәм аларның шактый средстволарын җыеп, таркалалар, ә җитәкчеләре чит илләрдә яшеренергә тырыша. Статистикага караганда, финанс пирамидалары һәм

төрле мошенниклар эшчәнлеге нәтиҗәсендә безнең илдә 90 елларда 82 млн нан артык кеше зыян күрә.

Әлеге процесс турында сез нәрсә беләсез? Бу сорауга язмача җавап бирегез.

## § 15. Икътисадта дәүләтнең роле

***Дәүләт сәяси генә түгел, ә бәлки икътисади субъект булып тора.*** Элегрәк икътисадчылар, дәүләт шәхси эшмәкәрләр алына алмаган яки теләмәгән кайбер товарлар һәм хезмәт җитештерүләрне үз өстенә алырга тиеш дип исәпли. Һәм шуның өстенә алар бу минималь катнашу дип исәплиләр. Ләкин бүгенге икътисадчылар, бер яктан, шәхси бизнеска артык күп бурыч йөкләргә ярамый, икенче яктан, аңа сәламәтлекне саклау, мәгариф, сәнәгый пычрануны ышанып тапшырырга ярамый, чөнки алар сорау һәм тәкъдим законы гамәле астына эләкмиләр дип раслыйлар. Димәк, дәүләт үз өстенә икътисад максатларын билгеләүне алырга һәм аларга ирешү өчен үз көчен кулланырга тиеш.

Дәүләтнең бүгенге җәмгыятьтәге төп икътисади вазыйфалары түбәндәгеләргә кайтып кала:

— илнең акча хуҗалыгын җайга салу;

— көндәшлек механизмын яклау, монополияләргә каршы эшне җайга салу;

— халыкның социаль якланмаган катлауларына булышлык итү, керемнәрне бүлү өлкәсендәге эшчәнлек;

— икътисадның законлы нигезен формалаштыру, гражданнарның һәм коммерция фирмаларының милек мәнфәгатьләрен суд белән яклауны тәэмин итү;

— кулланучыларның мәнфәгатьләрен саклау, товар һәм хезмәт күрсәтүләрнең сыйфатына контрольлек итү;

— илнең табигый ресурсларын файдалануны җайга салу һәм әйләнә-тирә мохитне саклауны оештыру;

— тышкы сәүдә һәм валюта операцияләре өлкәсен контрольдә тоту, шулай ук халыкара мөнәсәбәтләрдә илнең икътисади мәнфәгатьләрен яклау.

Дәүләтнең икътисадка йогынтысының иң нәтиҗәле ысуллары итеп *бюджет* һәм *салым салуны* исәпләргә кирәк. Салымнар рәвешендә бюджетка шактый суммалар керә.

*Салым салу* сәнәгать һәм бизнес эшчәнлегенең зыянлы нәтиҗәләрен чикләү өчен кулланылырга мөмкин. Хөкүмәт сәнәгать калдыкларын елгага ташлаган яки атмосфераны пычратканнарга салымнарны күтәрергә мөмкин. Шул рәвешле ул предприятиеләрнең чистарту җиһазларын камилләштерүен хуплый.

**САЛЫМНАР** дип дәүләтнең (хакимиятнең үзәк һәм җирле органнарының) физик һәм юридик затлардан җирле һәм дәүләт бюджетына ала торган мәҗбүри түләүләрен атыйлар.

Салымнар милли керемне икътисади һәм социаль бурычларга туры китереп бүлүне һәм кабаттан бүлүне тәэмин итә торган финанс мөнәсәбәтләре формаларының берсе булып тора. Салымнар — федераль хөкүмәт керемнәренең иң мөһим чыганаклары ул.

*Салымнарның төп төрләре икәү — турыдан-туры һәм читләтелгән салым.* ***Турыдан-туры салым — керемнәренең күләменә һәм милекләренең бәясенә бәйле рәвештә һәр гражданнан яки хуҗалык оешмасыннан дәүләт файдасына алына торган җыем.*** Гражданнарга керем салымы (Россиядә ул 13% тәшкил итә) һәм хуҗалык оешмаларының табышына салым турыдан-туры салымга керә. ***Читләтелгән салым — гражданнардан яки хуҗалык оешмаларыннан фәкать алар билгеле бер гамәл кылганда, мәсәлән, кайбер төр товарлар сатып алганда дәүләт файдасына алына торган җыем.***

Хәзерге россиялеләр, кулланучылар һәм җитештерүчеләр, башка илләргә караганда күбрәк — 40 төрдән артык салым түли. Кайберләре шулкадәр аңлаешсыз ки, алар салымнар буенча рекордсмен булган Борынгы Римның теләсә кайсы кешесен аптырашта калдырыр иде.

**ДӘҮЛӘТ БЮДЖЕТЫ** — дәүләтнең керемнәрен һәм чыгымнарын билгеле бер вакытка (бер елга) бүлеп билгеләү.

Ул нигездә салымнар ярдәмендә тупланган һәм икътисадны дәүләт җайга салуы, хуҗалык конъюнктурасын стимуллаштыру, социаль программаларны, фәнне һәм мәдәниятне, коралды көчләрне, финанс һәм матди резервлар берәмлекләрен финанслау, дәүләтнең идарә итү органнарын тоту өчен файдаланыла торган акча средстволарының үзәкләштерелгән фондларыннан тора.

***Дәүләт бюджеты рәсми закон статусына ия***, әлеге мөһим хокукый һәм сәяси документ буенча бөтен ил тулы бер ел яшәячәк. Ул илнең югары закон чыгару органы — ***парламент тарафыннан раслана***, ә ***хөкүмәт тарафыннан үтәлә***, чөнки ул керемнәр җыюны (финанс министрлыгы һәм салым хезмәте аша), парламент билгеләгән юнәлешләрдә һәм күләмнәрдә чыгымнар тотуны (дәүләт хезмәтләре аша) оештыра. Хокукларны һәм бурычларны болай бүлү — салым түләүчеләрнең средстволарын тотуны сайлап куела торган югары хакимият күзәтүе астына кую һәм дәүләт түрәләренең акчаларны контрольсез тотуын булдырмауны тәэмин итү дигән сүз.

Дәүләт бюджетлары, шәхси бюджетлар кебек үк, көтелә торган керемнәрне һәм чыгымнарны чагыштыра торган финанс планнары булып торалар. ***Көтелгән керемнәр көтелгән чыгымнарга туры килсә, бюджет балансланган дип атала.*** Керемнәр чыгымнардан артып китсә, бу аерма — **уңай сальдо (профицит бюджет)**. Бюджет чыгымнары керемнәрдән артык булса, аерма тискәре сальдо, яки **бюджет дефициты** дип атала. Бюджет дефициты **дәүләт бурычы** булып тора.

**ДӘҮЛӘТ БУРЫЧЫ** — дәүләтнең түләнмәгән займнар һәм аларга карата түләнмәгән процентлар буенча бурычларның гомуми суммасы.

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Балансланган бюджет | → | керемнәр | = | чыгымнар |
| Уңай сальдо | → | керемнәр | > | чыгымнар |
| Тискәре сальдо | → | керемнәр | < | чыгымнар |

Займнарны урнаштыру өлкәсен исәпкә алып, дәүләт бурычы *эчкегә* һәм *тышкыга* бүленә. Тышкысы — чит ил дәүләтләре каршындагы, эчкесе — үз халкы алдындагы бурыч. Икенчесе дәүләт халыктан даими рәвештә бурычка акча ала һәм аңа кайтарып бирми дигәнне аңлата. Моның иң таралган ысулы — кыйммәтле кәгазьләр чыгару һәм алар өчен түләмәү.

Дәүләт бурычы — бик үк гөнаһсыз нәрсә түгел. Күп кенә дәүләтләр даими рәвештә кирәкле чыгымнары ихтимал керемнәрдән күбрәк булган хәлдә калалар. Мәсәлән, 1557 елда Испания һәм Франция дәүләт банкротлыгы турында белдерәләр, чөнки кредитлар буенча процентларны түли алмыйлар. 1787 елда король Людовик XVI финансларның генераль контролеры Ш. де Калонны отставкага җибәрә, чөнки ул дәүләт бурычы артуны туктата алмый, нәтиҗәдә Франциягә банкротлык яный. Әлеге проблеманың бик җиңел хәл ителмәве турында безнең ил тарихыннан да мисал китерергә була.

Рус икътисадчысы Л. Н. Яснопольский 1908 елда дәүләт бюджетына җентекле анализ ясый һәм хөкүмәт, ниһаять, тышкы займ алмыйча дефицитны кыскарта ала. Ләкин хәтта шушы уңышлы финанс елында да Россиядә бер кеше башына дәүләт чыгымнары Англиягә һәм Пруссиягә караганда шактый ким була. Мәсәлән, 1896 елда дәүләт бюджетыннан Пруссиядә бер кешегә — 27 сум, Англиядә 23,4 сум, Россиядә 8,2 сум түләнә. Ун елда, ягъни 1906 елга бу чыгымнар Пруссиядә — 36,2 сумга, Англиядә — 33,6 сумга, Россиядә 9,8 сумга кадәр арта. Процент белән исәпләгәндә бу еллардагы үсеш 34, 43 һәм 19,5% була (*Русская мысль, 1908, февраль. 120*).

Дәүләт чыгымнары илдәге товар-акча мөнәсәбәтләре үсеше дәрәҗәсен генә түгел, ә бәлки, Л. Н. Яснопольский төгәл әйткәнчә, «матди чыгымнарның дәүләт халыкка аның иҗтимагый, мәдәни һәм сәяси тормышын оештыру рәве-

шендә кайтара торган суммасын да чагылдыра. Рус дәүләт оешмасы үсешнең бик тә түбән баскычында тора. Һәртөрле примитив оешма кебек үк ул биргәненә караганда чагыштыра алмаслык дәрәҗәдә күп ала».

Тарихи тәҗрибә күрсәткәнчә, зур дәүләтнең эчке һәм тышкы бурычыннан хафага төшеп куркырга ярамый. Гәрчә ул кайбер илләрне банкротлыкка китерсә дә, бу илләрдә яшәүчеләрне коллыкка сатмаганнар, читкә кагылган мәртәтләргә әвереләдермәгәннәр, ватаннарыннан мәхрүм итмәгәннәр. Бүген дә дөньяның күпчелек илләре зур эчке бурыч белән яши. АКШта ул 3 трлн доллардан артып китә. Өченче һәм дүртенче дөнья илләренең, аерым алганда, Бразилия, Мексика, Аргентина, Венесуэла, Нигерия һ.б. ның Көнбатышка бурычлары 800 трлн доллардан артык, шулай да беркем дә хәер эстәргә чыгып китмәгән. Шулай да Көнбатышка стратегик яктан хәерче һәм агрессив Россиягә караганда бай һәм демократик Россия файдалырак. Өченче дөньяның кайбер илләре, аерым алганда, Гыйрак, Мисыр, Ливан Россиягә дистәләрчә миллиард доллар бурычлылар, ләкин түләргә җыенмыйлар, ә мәҗбүр итеп булмый. Өстәвенә патша Россиясенең һәм СССРның хокукый варисчысы буларак Россиягә тиешле чит илләрдәге күчемсез милек, экспертлар бәяләгәнчә, 300 млрд долларга кадәр җитә. Бу безнең чит илләргә бурычыбыздан ике тапкыр артыграк.

---

**Төшенчәләр:** *дәүләт бюджеты, салым салу, турыдан-туры салымнар, дәүләт бурычы.*

---

**Сораулар һәм биремнәр**

***1.** Ни өчен соңгы елларда дәүләтнең Россия икътисадына катнашуы шулай тиз үсте?

**2.** Дәүләт бюджетының төп элементлары нинди?

**3.** Федераль хөкүмәт акчалар белән ничек эш итә?

***4.** Ни өчен федераль бюджет һәм милли бурыч өйрәнүнең мөһим предметы булып торалар?

***5.** Хөкүмәт:

— базар системасын саклау;

— җәмәгать товарларын һәм хезмәт күрсәтүләрне тәэмин итү;

— халыкны зарарлы икенчел нәтиҗәләрдән саклау;
— керемнәрне бүлү;
— икътисадны тотрыкландыру өчен нәрсәләр эшли?

6. Салым салуның төп төрләрен санагыз һәм аларга характеристика бирегез.

**? Проблема.** Салым җыю өчен нинди юллар һәм алымнар нәтиҗәлерәк?

**Практикум 1.** 1992 елда базарга актив күчү башланды. Иске система әле ватылмаган, ә яңасы булдырылмаган. Гыйнварда өстәмә бәягә 28% салым кертәләр. Заводлар исә продукциягә шул ук күләмдә бәяне арттырып та куя, һәм бер генә тапкыр да түгел. Дәүләт шул рәвешле үз эшләрен рәтләргә уйлый. Ләкин февраль ахырында яңа салымның предприятиеләрнең 20% гына биргәне ачыклана. Җитмәүчелек — 80%. Бәяне күтәреп, предприятиеләр оттырышта калмый. Оттыручылар исә, кулланучылар һәм хөкүмәт. Ни өчен? Дәлилле җавап бирегез.

**Практикум 2.** Билгеле булганча, Чыңгыз хан үзе буйсындырган халыклардан уннан бер өлеш, ягъни 10% ясак алган. Чыңгыз ханнан, ни өчен бик аз, дип сорагач, күбрәк ярамый, юкса ясак түләүче халык үсә алмаячак, дигән. Халыкның хәзер яшәүчеләргә генә түгел, оныкларга да түләрлек хәле булырга тиеш. Ничек уйлыйсыз, хәзерге Россия хөкүмәте дә шулай эшлиме? Дәлилле җавап бирегез.

5 бүлек

# Җәмгыятьнең сәяси системасы



## § 16. Сәяси хакимият

8–9 нчы сыйныфлар өчен җәмгыять белеме курсыннан ачыклавыбызча, ***көч, хакимият һәм абруй — йогынты ясауның өч формасы.*** Көч һәм абруй хакимият чыганаклары булып торалар һәм ул кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр ниндидер иерархиягә тезелгән, җитәкчеләр һәм алар кул астындагылар булган, теге яки бу дәрәҗәдә абруйлы (йогынтылы, өстенлекле, хакимлек итүче) вазыйфаларга бүленгән урыннарда мөмкин. Хакимлек бер кеше тарафыннан башкаларга мөнәсәбәттә тормышка ашырылганлыктан, ул социаль мөнәсәбәтләргә кагыла һәм үзе дә аларның — **хакимлек мөнәсәбәтләренең** махсус төрләренең берсе булып тора.

***Хакимият — өч төр йогынтының ныграк үскәне һәм иң катлаулысы.*** Ул берничә төрлегә таркала. Хакимият төрләре типологиясен XX гасыр башында немец политологы ***М. Вебер*** (1864–1920) төзегән. *Хакимият а) шәхси сыйфатларга; б) традицияләргә һәм гореф-гадәтләргә; в) формаль законга нигезләнә ала.* Барлык өч очракта да хакимият социаль хупланган, ягъни легитим була.

Хакимиятнең бу өч чыганагына туры китереп, **харизматик, традицион** һәм **легаль** хакимиятләрне аералар. Ике төшенчәне — легитимлык һәм легальлекне конкретлаштырыйк.

**ЛЕГИТИМЛАШТЫРУ** (лат. legitimus — законлы) — әлеге җәмгыятьтә кабул ителгән кыйммәтләргә таяна торган дәүләт хакимиятенең, нинди дә булса институт, статус, вәкаләтләрнең законлылыгын тану яки раслау. Легитимлаштыруның нигезе традицияләр һәм гореф-гадәтләр, харизма, конституцион нормалар, демократик сайлаулар, референдум яки плебисцит булырга мөмкин.

**ЛЕГАЛЬЛӘШТЕРҮ** (лат. legalis — законлы) — 1) нинди дә булса оешма эшчәнлегенә рөхсәт бирү, аны законлаштыру, нинди дә булса актка, эшкә юридик көч бирү; 2) документлардагы имзаларның чынлыгын раслау.

Легитим хакимият гадәттә хокуклы һәм гадел буларак характерлана. Хакимиятнең легитимлыгы аның: 1) абруе; 2) гражданнарының күпчелеге хуплый торган идеалларны һәм кыйммәтләрне яклавы; 3) хакимиятнең һәм халыкның төп сәяси принциплар, мәсәлән, сүз иреге, гражданлык хокукларын яклау яки халыкның ярлы катлавына социаль ярдәм күрсәтү буенча килешүе белән характерлана.

Шулай итеп, бер тамырлы ике латин сүзеннән ике төрле атама килеп чыккан. Беренчесе икенчесеннән киңрәк. Легитимлык традицияләр, харизма һәм закон, ягъни законлы хикимиятнең югарыда күрсәтелгән барлык өч чыганагы аша законлаштыруны аңлата. Легаль сүзе законлы хакимиятнең юридик документлар, формаль закон ярдәмендә билгеләнгән бер генә төрен аңлата. Шунлыктан легитим хакимиятнең өч төре һәм араларыннан берсе — легаль хакимият турында сөйләргә була.

Хакимиятнең өч тибына тулырак тукталыйк.

**Харизматик хакимият.** ***Иле яки кешеләр төркеме белән искиткеч шәхси сыйфатлар нигезендә идарә итү харизматик идарә дип атала.*** Шәхеснең гадәттән тыш сыйфатларына — акылына, батырлыгына, «изге»легенә нигезләнгән харизма (грек. charisma — мәрхәмәт, Ходай бүләге) формаль булмаган абруйның югары дәрәҗәсен гәүдәләндерә. «Акыллы баш», «гаделлек өчен көрәшүче», «изге җан» (намуслы кеше) уртача кешедә булмаган сыйфатларга ия. Ләкин алар харизматик лидер булу өчен җитми. Искитәрлек сыйфатлар гына түгел, әлеге кешене бөек һәм даһи дип исәпләү өчен гадәттән тыш сыйфатлар кирәк.

Андый кешеләр абруйлы гына түгел, алар — җәмгыять өчен бәхәссез авторитетлар. А. Эйнштейн һәм И. Ньютон шулар рәтенә керә. Фән мохитендә алар харизматик лидерлар булган дип әйтергә мөмкин.

*Таблица*

**Легитим хакимият**

| *Харизматик хакимият* | *Традицион хакимият* | *Легаль хакимият* |
|---|---|---|
| *Кешеләр лидерга (юлбашчыга, корольгә, президентка) аның гадәттән тыш сыйфатлары өчен буйсыналар. Андый лидерлар, гадәттә, бөек социаль тетрәнүләр вакытында барлыкка килә. Алар йә игелек, йә явызлык гәүдәләндереп, яшәп килә торган тәртипләргә каршы чыга. Мисал: Иисус Христос, В.И.Ленин, А. Гитлер.* | *Кешеләр лидерга (юлбашчыга, корольгә, президентка) урнашкан традицияләр һәм гореф-гадәтләр нигезендә буйсыналар. Халык аларны нәкъ менә урнашкан стройны яклаганнары өчен хөрмәт итә. Мисал булып антик дәвердәге, Урта гасырлардагы һәм Яңа вакыттагы король һәм патша династияләре хезмәт итә.* | *Кешеләр лидерга (юлбашчыга, корольгә, президентка) аларга приказ бирү хокукын нинди дә булса закон чыгару органы, мәсәлән, парламент биргәне өчен буйсына. Лидерлар өчен ил белән җитәкчелек итү җәмгыятькә хезмәт итү генә түгел, ә эш тә. Дәүләт аппараты түрәләре — законга гадәти хезмәт итүчеләр.* |

Харизматик хакимлек ниндидер югары мистик көчкә ия булган кешегә тугрылыкка нигезләнә. В. И. Ленин, И. В. Сталин, Аятулла Хомәйни, Мохандас Ганди — харизматик лидерларның берничәсе.

Харизматик хакимият ышануга һәм юлбашчы белән массаларның хисси, шәхси мөнәсәбәтенә нигезләнә. Ул аеруча еш революцион үзгәрешләр чорында, яңа хакимият традиция яки закон абруена таяна алмаган вакытта барлыкка килә. Чөнки әле генә ул үзе яки аның җитәкчелегендә халык законлы хакимиятне бәреп төшерә, ә яңа традицияләр әле барлыкка килми. Шунлыктан юлбашчы шәхесен күтәрергә туры килә, ә аның абруен хакимиятнең



яңа институтлары изгеләштерә. Бу күренешне шәхес культы дип атыйлар. *Шәхес культы* (лат. cultus — хөрмәтләү) — *хакимнең, юлбашчының шәхесен дини табынуга кадәр диярлек артык күтәрү.*

**Традицион хакимият.** ***Ул хакимияткә буйсыну гадәтләренә, күнегүгә, борынгыдан ук яшәп килә торган тәртипләрнең какшамаслыгына һәм изгелегенә инануга таянып тора. Классик мисал — абсолют монархия.*** Дәүләтнең абруен хакимияткә баш июнең күп гасырлык традицияләре белән ныгыта торган факт — монарх хакимиятенең нәселдән күчүе институты, шуның аркасында традицион хакимият үзенең ныклыгы белән аерылып тора.

Гражданнар элек урнашкан гадәт буенча хакимлек бирелгән идарә итүчеләргә тугрылыкларын күрсәтәләр. Юлбашчыга тугрылык һәм аның эшен дәвам иттерүчеләр ягыннан булышлык буыннан буынга тапшырыла. Әфәнде белән хезмәтче арасындагы мөнәсәбәт моңа мисал булып тора. Европа аристократиясенең нәселдән килүче алпавыт җирләрендә шулай килеп чыккан: әфәнделәр династияләре белән хезмәтчеләр династияләре вакытлар дәвамында параллель рәтләр булып барган. Әфәнделәрнең балалары — яңа әфәнделәр, хезмәтчеләрнең балалары әфәнденең шул ук гаиләсендә яңа хезмәтчеләр булганнар. Традиция җанга һәм тәнгә шулкадәр тирән сеңгән ки, үзенең әфәндесеннән аерылу үлемгә тиң булган.

**Легаль хакимият.** ***Ул әле тагын акыллы законлаштырылган дип тә атала, чөнки юридик нормаларның***

***дөреслегенә ышану һәм аларны үтәү зарурлыгы белән бәйле.*** Буйсынучылар гадәти нормаларны, принцип һәм кагыйдәләрне тоталар, шунлыктан алар бары тик тиешле вәкаләтләре булган кешеләрне генә тыңлыйлар. Бер җитәкче үзен күренекле шәхес буларак күрсәтергә, хәтта харизматик та булырга мөмкин, әмма ул башкага — күренекле булмаганга, өстән куелганга буйсынырга тиеш. Еш кына шулай да була, иске башлык белән озак еллар эшләп, ул алар өчен традицион башлыкка әверелсә дә, яңа башлык куйгач, аның кул астындагылар шундук үзгәрә. Эштән җибәрелгән яраткан башлыкка кызгану хисе, кайнар яклау белдерәләр, ләкин беркем дә фәрманга каршы бармый.

*Демократик дәүләттә җитәкченең шәхесенә түгел, ә хакимият вәкилләрен сайлый һәм эшләтә торган законнарга буйсыналар.* Монда легитимлык аерым шәхесләргә түгел, ә гражданнарның дәүләт төзелешенә ышанычына нигезләнгән.

**Хакимият типларының комбинацияләре.** Күрсәтелгән дәүләт типлары саф рәвештә сирәк очрыйлар. Еш рак аларның комбинациясен күрергә мөмкин. Католик һәм православие чиркәүләре башлыклары, шулай ук иерархия баскычында түбәнрәк торучы дин әһелләре — приход кешеләре өчен бер үк вакытта: а) харизматик лидерлар, б) традицион җитәкчеләр, в) легаль хакимнәр булып тора. Чиркәүнең югары иерархларын харизматик лидерлар итеп шуның өчен саныйлар, чөнки аларның аерым сыйфатларына, Аллаһ белән турыдан-туры аралаша алу сәләтләренә чын күңелләреннән ышаналар. Бу бик тә борынгы һәм традицион институт булганлыктан, түбәнгеләрнең югары дин әһелләренә буйсынуы гадәткә һәм традициягә кергән. Ниһаять, хакимиятнең мондый тибын аларның дөньяви түрәләр кебек үк указлар, карарлар һәм директивалар ярдәмендә идарә итүе дә легаль итә.

Чиркәү хакимиятнең өч тибы тулы күләмдә күрсәтелгән бердәнбер җәмгыять институтыдыр, мөгаен. Еш кына шулай да була, легаль идарә иерархиянең нигезе булып тора, ә традиционлык һәм харизматиклык төрле пропорциядә өстәлә. Читкә куылып яшәгәндә дә Аятулла Хомәйни Иран мөселманнарының харизматик лидеры була. Иленә кайтып, дәүләтне җитәкләгәч, әле тагын легаль хаким сый-

фатларын да ала. *Аятулла* статусы («Аллаһ билгесе» дигәнне аңлата) аны мөселманнарның традицион җитәкчесе итә.

Дәүләт башлыклары турында сөйләгәндә, һәр йөзьеллыкта биш-алтыдан артык булмаган чын харизматик лидер табылачак. Гәрчә тарихның кайбер чорларында, мәсәлән, XX гасырда алар шактый күбрәк иде.

АКШның сәяси системасында легаль бюрократия өстенлек итә, ләкин анда да башка элементлар бар. Мәсәлән, суд бәхәсләрен җайга салу өчен Югары суд Конституциягә мөрәҗәгать итә. Бу Американың сәяси системасының традицион аспекты, анда шулай ук харизматик элементларны да табып була. Франклин Делано Рузвельт һәм Джон Кеннеди кебек президентлар харизматик лидерлар була. Яшь демократияләрдә хакимиятнең легитимлыгы сайланулы институтларга хөрмәткә караганда дәүләт җитәкчесенең абруена нигезләнә. Бүгенге дәүләтләрнең сәяси системасы үз эченә хакимиятнең барлык өч тибы элементларын да ала.

---

**Төшенчәләр:** *харизматик хакимият, традицион хакимият, легаль хакимият, легитим хакимият.*

---

**Сораулар һәм биремнәр**

1. Легитим хакимиятнең һәр өч тибына мисаллар китерегез.

2. Хакимиятләрнең типларын (харизматик, традицион, легаль) чагыштырыгыз һәм гомумиләштерелгән нәтиҗәләр ясагыз.

*3. В. И. Ленин, А. Гитлер һәм Л. И. Брежнев сәяси режимы вакытында халыкның буйсынуы нигезендә аерымлыклар бармы? Үз җавабыгызны дәлилләгез.

*4. Россиядәге президентлык республикасы һәм АКШтагы дәүләт төзелеше легитим хакимиятнең өч төренең кайсысына керәләр?

5. Хакимият типлары комбинацияләренә мисалларын китерегез.

**? Проблема.** Россия өчен хакимиятнең кайсы тибы күбрәк туры килә һәм ни өчен?

**Практикум.** Түбәндәгеләр хакимиятнең кайсы тибы (харизматик, традицион яки легаль) вакытында була:

Гражданнар хакимият бирелгән хакимнәргә гадәтләр нигезендә тугрылык күрсәтәләр.

Гражданнар гадәти нормаларны, принцип һәм кагыйдәләрне тоталар, шунлыктан алар тиешле вәкаләтләре булганнарга гына буйсыналар.

Юлбашчыга тугрылык һәм дәвамчыларның яклавы буыннан буынга күчә.

Хакимлек юридик нормаларның дөреслегенә һәм аларны үтәү зарурлыгына ышану белән бәйле.

Абруен хакимият институтлары изгеләндергән юлбашчының шәхесен күтәрергә туры килә.

Хезмәткәрләр төгәл билгеләнгән хезмәт хакы алалар.

Хакимлек ниндидер югары мистик көчкә ия булган кешегә карата тугрылыкка нигезләнә.

Җитәкче шәхесенә түгел, ә хакимият вәкилләре аның кысаларында сайлана һәм эш итә торган законнарга буйсыналар.

## § 17. Дәүләтнең асылы һәм оешуы

Дәүләт — җәмгыятьнең сәяси системасының мөһим состав өлеше. ***Җәмгыятьнең сәяси системасы дәүләти-оешкан җәмгыятьнең билгеле бер сәяси вазыйфалар башкара торган социаль институтлары җыелмасын гәүдәләндерә.*** Борынгы заманнардан ук фикер ияләре дәүләтнең асылы һәм эш итү механизмнары, аның җәмгыятьтәге һәм сәяси системадагы роле турында уйланганнар. Алар эшләгән концепцияләрне бүген бөтен дөньяның уку йортларында өйрәнәләр. Аларның кайберләре белән сез бу китапның беренче бүлекләрендә таныштыгыз.

«Дәүләт» атамасы гадәттә ике мәгънәдә кулланыла. ***Киң мәгънәдә дәүләт илгә һәм әлеге территориядә яшәүче сәяси оешкан халыкка тәңгәл.*** Бу мәгънәдә, мәсәлән, аларның бөтен җәмгыятен күздә тотып, Россия, Америка, немец дәүләте турында сөйлиләр. Якынча XVII гасырга кадәр дәүләт гадәттә киң аңлатылган һәм җәмгыятьтән аерылмаган. Дәүләтне аңлату өчен «кенәзлек», «корольлек», «империя», «республика», «патшалык» һ.б. кебек төгәл атамалар кулланылган.

***Тар мәгънәдә дәүләт җәмгыять өстендә тора торган югары хакимият оешмасын гына аңлата.*** Бу очракта дәүләт һәм җәмгыятьне төгәл аерырга кирәк. Дәүләтнең шартнамә теориясен булдырган XVIII гасыр француз мәгърифәтчеләре, тарих таңында кешеләр берничек тә оешмаганнар дип уйлый. Ләкин тормыш ихтыяҗы аларны башта — җәмгыятьнең, аннары үз иминлеген тыштан (дошманнардан) һәм эчтән (җинаятьчеләрдән) саклау өчен дәүләт төзергә мәҗбүр итә.

Бүгенге фәндә дәүләт тар мәгънәдә билгеле бер территориядә югары хакимияткә ия булган оешма, учреждениеләр системасы буларак аңлана. Ул башка сәяси оешмалар: партияләр, профсоюзлар һ.б. белән янәшә яши. Башкача әйткәндә, *дәүләт — җәмгыятьнең сәяси системасының үзәк, ләкин бердәнбер булмаган институты.*

8 һәм 9 сыйныфлар өчен җәмгыять белеме курсында дәүләтнең билгеләре, бурычлары һәм барлыкка килү сәбәпләре җентекләп тикшерелде. Дәүләтнең территориаль оешуын карыйк.

*Дәүләтләр, җәмгыятьнең сәяси оешмасы буларак, идарә итү формасы белән генә түгел (монархия, республика), территориаль төзелеш формалары белән дә аерыла.*

**Дәүләтнең территориаль төзелеше** бербөтен һәм өлешләрнең, өлкә, төбәк, штат, кантоннарның һ.б. үзара ничек эш итүен аңлата. Башкача әйткәндә, үзәк җирле хакимиятләргә күпме яки азмы автономия, хокук һәм мөмкинлекләр калдырган яисә ул боларның барысын да бердәм сәяси киңлектә тулысынча эретеп бетергәнме?

*Территориаль төзелеш күзлегеннән караганда, дәүләтләр **унитарга** (бердәм дәүләт берәмлеге), **федерациягә** (юридик яктан чагыштырмача мөстәкыйль дәүләт берәмлекләре: штат, кантон, җирләр, союздаш республикалар һ.б. берлеге); **конфедерациягә** (дәүләти-хокукый берләшмәләр)* бүленәләр.

**Унитар дәүләттә** административ-территориаль берәмлекләрнең үз дәүләтчелекләре юк. Барысы өчен дә бер конституция һәм гражданлык.

Үзәк хөкүмәт һәм гомуми парламент кабул иткән карарлар дәүләтнең бөтен территориясе өчен бер үк көчкә ия.

Унитар форма бер миллэтле илләргә яхшырак туры килә һәм ул нәкъ аларда формалашкан да.

**Федератив дәүләттә** үзәк хөкүмәтнең роле җитди чикләнгән. Хакимият чыганаклары — эре территориаль берәмлекләр — республика, өлкә, край, штат, җир, кантоннар.

> **ФЕДЕРАЦИЯ** — үзләренең закон чыгару, башкарма һәм суд органнары һәм, кагыйдә буларак, конституцияләре, еш кына ике гражданлыклары да булган мөстәкыйль диярлек дәүләтләрнең тотрыклы берлеге.

Мондый төзелеш берничә халыкның күптәннән урнашкан мәдәни традицияләре һәм яшәү рәвеше булган, төрле телдә сөйләшкән, төрле нормаларга буйсынган, төрле дин тоткан, ә иң мөһиме үзләренең үзенчәлекләрен югалтмаган һәм аны якларга әзер торган күп миллэтле илләргә яхшырак туры килә. Мондый федератив төзелеш — акыллы килешеп яшәү һәм төрле хәлләрдән чыгуның бердәнбер диярлек юлы. Килешеп яшәү, чөнки дәүләткә бердәм булу яхшырак, акыллы, чөнки милли азчылыклар үзләренең үзенчәлекләрен саклыйлар, ә күпчелек аларга демократик күзлектән карарга өйрәнә, аларның хокукларын хөрмәт итә. Ахыр чиктә түземлелек мәктәбе нәкъ менә күпчелеккә бик тә зур файда китерә, ул акрынлап тагын да цивилизациялерәк була бара.

Федератив дәүләттә барлык территориаль субъектлар, мәсәлән, штатлар, бергә җыелалар һәм үзәк белән урыннардагыларның вәкаләтләрен бүлешә торган уртак конституция кабул итәләр. Алга таба конституциягә теләсә нинди төзәтү бары тик федерация субъектлары ризалыгы белән генә кертелә. Өстәвенә мәсьәләләрнең бер өлеше фәкать берлек органнары карамагында, икенчесе федерация субъектлары, өченчеләре берлек һәм аның әгъзалары карамагында була.

АКШта һәм Россиядә нәкъ шулай. Әмма күптөрле аерымлыклар да бар. Штатлар Россиядәге федерация субъектларына караганда зуррак хокукларга ия. Тарихны искә төшерсәк, АКШ астан формалашты, штатлар озак вакыт мөстәкыйль булдылар, берләшүгә сак, һәрберсе үзенә күбрәк мөстәкыйльлек алырга тырышып килделәр. Вакыт-вакыт әле бер, әле икенче штатта аның гомуми берлектән чыгуы

турында турыдан-туры белдерүче радикаллар төркеме барлыкка килә иде.

Россиядә федеративлык өстән төште. Безнең ил һәрвакыт унитар дәүләт булды, федерализм тәҗрибәсе зур түгел, урыннарга нинди хокуклар бирүне үзәктә хәл итәләр. Вакыт-вакыт федерациянең көчлерәк субъектлары ризасызлык белдереп карый, үзәктән бик тә аз хокуклар алынган дип исәплиләр. Әле көч басымы белән, әле аерылып чыгу белән янап, әле башкача, алар үзләренә күбрәк вәкаләтләр алырга тырыша. Без, күрәсең, акрынлап АКШ хәленә килербез, ул чакта һәр субъект үзен канәгатьләндергән кадәр хокук алачак һәм берлекне җимермәячәк. Дөрес, «алтын урталык»ны табу авыр. Монда чит модельләр ярамый, үзебезнекеләрне эзләргә туры киләчәк, билгеле инде, шактый күп хаталар өстәләчәк.




XX гасыр ахырында Россия җәмгыяте һәм дәүләте структурасы




Федерация әгъзалары берлек дәүләтеннән берьяклы гына чыгу хокукына ия түгелләр. Берлек конституцияләренең күпчелегендә федераль органнарның федерация әгъзаларының эчке эшләренә анда гадәттән тыш хәлләр: табигый бәла-каза һәм массакүләм тәртипсезлекләр булганда тыкшыну хокукы беркетелгән.

Федератив дәүләт тә, унитары да үзләренең яшәргә сәләтле икәнлекләрен исбат иттеләр һәм дөньяның күпчелек илләре тарафыннан кабул ителделәр. Ә менә **конфедерацияләр** тотрыксызлар һәм тиз таркалалар. 1695 елда ашанти халкы күрше кабиләләрне җиңгәч, Осаи Туту Африканың Алтын Ярында Ашанти конфедерациясе дигән исем алган дәүләткә нигез сала. Күрше территорияләрне буйсындырып, Ашанти конфедерациясе куәтле сәяси берлеккә әверелә. Дәүләт башында баш юлбашчы (ашантихене), аның еш кына королева-ана дип йөртелүче ярдәмче идарәчесе, аксакаллар советы тора. Конфедерация иерархия принцибы буенча төзелә, аерым вазыйфалар нәселдән нәселгә калдырыла. Басып алынган территорияләр белән идарә итү генә искәрмә булып тора, аны җирле юлбашчылар (ашанти корольләре) башкара.

Конфедерацияләр АКШта (1776–1787), Швейцариядә (1848 елга кадәр), Германиядә (1815–1867) һәм башка кайбер илләрдә төзелә, ләкин таркалалар. Аларның нигезендә йә федерацияләр, йә унитар дәүләтләр барлыкка килә.

Безгә таныш мисал — БДБ (Бәйсез Дәүләтләр Берлеге — СНГ — Содружество Независимых Государств) — үз эшчәнлеген фәкать гомуми мәсьәләләр буенча гына координа-

цияли торган суверен дәүләтләр берлеге. Ул — мөстәкыйль дәүләтләрнең конкрет уртак максатларны тормышка ашыру өчен даими берлеге. Аның әгъзалары дәүләт суверенитетын тулысынча саклыйлар һәм берлек хокукына бары тик чикләнгән сандагы мәсьәләләрне, ешрак оборона, тышкы сәясәт, транспорт һәм элемтә, акча системасы өлкәләренә кагылганнарын бирәләр. Россиянең БДБне сакларга тырышуы бик үк уңай нәтиҗәләр бирми. Мәсәлән, дәүләт башлыклары очрашуында кабул ителгән таможня берлеге турындагы карарларны йә барысы да, йә бер өлеше инкарь итә, ләкин теләсә нинди изге ниятне юкка чыгару өчен шул җитә. Мондый конфедерациянең ясалмалыгын барысы да тоя, яңа үзгәрешләргә барысы да әзер, ләкин аларның ничек буласын белүче генә юк. БДБ элеккеге СССРның союздаш республикаларыннан барлыкка килде. Алар 1920 елларда, СССР барлыкка килгәнче, дәүләт суверенитеты алырга, мөстәкыйль булырга тырыштылар. Ләкин хәрби көч белән мондый омтылышлар тиз бастырылды, ә аннары 70 ел дәвамында аларны суверенитет турында хәтта уйлаудан да читләштерергә тырыштылар. Ә көчләү беткәч үк, ә бу Горбачев үзгәртеп коруы ахырында (1991 елның декабре) булды, СССР шундук таркалды. Суверенитетлар парады башланды. Анда күп кенә үзара гаепләүләр, үпкәләүләр, ялгышлар булды. Ләкин яшь демократияләр һәрвакыт шуның аша узалар.

Конфедерациянең бөтенләй дә яңа тибы — ***Европа Берлеге.*** Ул 1993 елда Маастрихт шартнамәсе нигезендә Европа берлекләре базасында оештырылды. Ул чакта ул 12 илне берләштерде: Бельгия, Бөекбритания, Германия, Греция, Дания, Ирландия, Испания, Италия, Люксембург, Нидерландия, Португалия, Франция. 2007 елның 1 гыйнварына бу берлектә 27 ил-әгъза исәпләнде. 2000 елның көзендә катнашучы илләр вәкилләренең Ниццада үткән киңәшмәсендә берлектә катнашырга дәгъва итүче илләр вәкилләре дә, алар арасында Балтыйк илләре дә бар иде. Бердәм Европа идеяләрен үстерү Шартнамәсе сәяси, икътисади һәм валюта берлеге («Чикләрсез Европа») булдыруны, бердәм эчке базар формалаштыруны тәмамлауны — товарларның, хезмәт күрсәтү, капитал, кешеләрнең ирекле күчеп йөрүе юлындагы барлык каршылыкларны бетерүне күздә тота.

ЕБ илләре тышкы сәясәт һәм иминлек, эчке икътисади сәясәтнең төп юнәлешләре өлкәсендә уртак курс үткәрергә, әйләнә-тирә мохитне саклау, җинаятьчелеккә каршы көрәш, юстиция өлкәсендәге һ.б. мәсьәләләрдә сәясәтне җайга салырга йөкләмә алдылар. Биредә Европа гражданлыгы урнаштырыла. Европа валюта институты һәм Европа үзәк банкы булдырыла, ә 1999 елда бердәм валюта — *евро* барлыкка килә (2002 елдан кулда әйләнештә). Яңа конфедерация әле бик яшь. Ихтимал, аңа башка конфедерацияләр язмышы тимәс, ә бәлки ул әле андый берәмлекләрнең ныклы булмавы турындагы фикерне нигытыр гына.

---

**Төшенчәләр:** *дәүләт, унитар дәүләт, федерация, конфедерация.*

---

**Сораулар һәм биремнәр**

**1.** Нәрсә ул дәүләтнең территориаль оешуы?

**2.** Унитар һәм федератив дәүләтләр нәрсәләре белән аерылалар?

**3.** Милли дәүләт һәм федератив дәүләт үзара нәрсәләре белән аерыла?

***4.** Ни өчен конфедерация тарихи яктан перспективасыз төзелеш тибы булып чыккан? Дәлилләгез һәм мисаллар китерегез.

***5.** Илнең иң мөһим билгеләренең берсе — дәүләт чикләре булу. 70 елдан артык СССРның чикләре үзгәрешсез калды, әмма ул таркалгач, суверен дәүләтләр барлыкка килде.

а) Элеккеге СССР территориясендә ничә яңа дәүләт барлыкка килде?

б) Элеккеге совет җирендәге дәүләтләрнең чикләре ничек урнаштырылган булган:

— сәяси җитәкчеләрнең субъектив башбаштаклыгы буенча;

— тарихи чикләр буйлап;

— башкача.

**? Проблема.** Федератив дәүләттән аның бер өлешенең ирекле чыгуы мөмкинме?

✍ **Практикум 1.** Территориаль төзелеш күзлегеннән карганда, барлык дәүләтләр дә унитарга (бердәм дәүләт берәмлеге); федерациягә (юридик яктан чагыштырмача мөстәкыйль дәүләт берәмлекләре: штатлар, кантон, җирләр, союздаш республикалар һ.б. берлеге); конфедерацияләргә (дәүләти-хокукый берләшмәләр) бүленә.

Уйлап карагыз һәм әйтегез, сез түбәндәге илләрне боларның кайсы тибына кертер идегез: АКШ, Канада, Бразилия, Украина, Португалия, Россия, Казакъстан, Бельгия, Уругвай, Һиндстан, Германия, Мексика, Италия, Кытай?

✍ **Практикум 2.** Федератив дәүләттә, аерым алганда, Россиядә, конституция үзәк вәкаләтләрен һәм җирле вәкаләтләрне аера.

Әдәбияттан файдаланып җавап бирегез, мәсьәләләрнең кайсы өлеше:

— фәкать берлек органнары хокукында гына,

— федерация субъектлары хокукында,

— берлек һәм аның әгъзаларының уртак хокукында.

## § 18. Җирле үзидарә

Социаль фәннәрдәге күпчелек атамалар кебек үк, «үзидарә» атамасының да тулы һәм бердәм фәнни мәгънәсе юк. Төрле илләрдә төрле авторлар аны үзенчә аңлый. Аңа тулырак һәм киңрәк аңлатма әле XVII гасырда ук Англиядә бирелә; аннан ул XIX гасырның 50 елларында — Германиягә, 60 елларда Россиягә керә. Юридик һәм социаль-хокукый әдәбиятта үзидарәнең профессиональ вазыйфаи затларга кермәүче кешеләр тарафыннан тормышка ашырылучы дәүләт идарәсенең төрле төрләреннән алып халыкның аның сайланулы вәкилләре тарафыннан гамәлгә ашырыла торган хакимиятне белдерү формасына кадәр 30 дан артык билгеләмәсе бар.

РФ Конституциясендә һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законда ***җирле үзидарә, халык мәнфәгатьләреннән, аның тарихи яки башка җирле тра-***

***дицияләреннән чыгып, турыдан-туры яки җирле үзидарә аша хәл иту буенча халыкның мөстәкыйль һәм үз җаваплылыгындагы эшчәнлеге буларак билгеләнә.***

Дөньякүләм фәнни фикер үзидарәнең берничә теориясен эшләгән («ирекле сөрүлек», иҗтимагый-хуҗалык, дәүләти, юридик, сәяси). Аларның икесе Россия земстволары мисалында тикшереп каралган. Беренче земство реформасы (1864 ел) үзенең теоретик нигезләмәсен *иҗтимагый үзидарә концепциясе* яклылар (В. И. Лешков, А. В. Васильчиков һ.б.) хезмәтләрендә таба. Әлеге теория нигезендә, земствога, сәяси төзелеш эшләренә катнашмыйча, җирле хуҗалык һәм мәдәният эшләре белән чикләнү каралган. Үз чиратында, дәүләт земство эшләренә катнашмый. Земство ныгып урнаша барган саен администрация ягыннан кысуларга карата да дәгъвалар арта. Җирле үзидарә органнарының хакимият вазыйфаларын арттыру файдасына фикерләр үзидарәнең «дәүләт теориясе» булып формалаша (А. Д. Градовский, Н. М. Коркунов һ.б.).

Россиядә үзидарә менә ничә йөз еллар инде *җир идеясе — җирдән, халыктан чыга торган халыкчанлык, хакимият идеясе белән бәйле.* «Земство» төшенчәсе Россиянең сәяси лексиконында әле 1864 елга кадәр үк барлыкка килә. X гасырда «җир» билгеле бер территориаль-сәяси бердәмлек булып фикерләнә. Үзәкләштерелгән дәүләт барлыкка килгән чорда «земский» атамасы җирле түгел, ә дәүләт характерында була. XV–XVI гасырларда «земляне» («җирдәшләр») атамасы аларга хас җирле мәнфәгатьләр белән җирле кешеләр җыелмасын аңлата. *Иван IVнең земство реформасы* җирле идарәдәге үзәктән билгеләнеп куела торган түрәләрне җирле бергәлек вәкилләренә алыштырырга һәм шуның белән ашап ятучыларның законсызлыкларына чик куярга тиеш була. «Земство ополчениеләре»нең эшчәнлеге бөтен Россиянең язмышы белән бәйләнгән була.

*Петр I реформалары* җирле үзидарә идеяләрен үстерүгә караганда дәүләтнең ролен арттыралар. *Екатерина II реформалары* җирле идарә өлкәсендә тирәнрәк эз калдыралар. Аның вакытында земство судлары һәм земство полициясе, иҗтимагый күзәтчелек приказлары, земство повинностьлары барлыкка килә; дворяннар һәм шәһәр сословиесе үзидарә алалар. Гаделлек сословие мәнфәгатьләре систе-

масы гармониясе аша ирешелгәндә, земство тормышны «дәреслек һәм намус буенча» оештыру белән тәңгәлләштерелә. Шул вакыттан бирле земство идеясе Россиянең барлык реформаларында даими урын алып килә.

*1861 елда крепостнойлык хокукы бетерелгәннән соң ул яңа үсеш ала.* Земствоны керткәнгә кадәр илдә бары тик сословие үзидарәсе генә була. Әмма хәзер беренче тапкыр бөтенсословие үзидарәсе — гражданлык үзидарәсе булдырыла: земство корпоратив берләшмәләр түгел, гражданнар тарафыннан сайлана. 1864 елдан алып 1917 елга кадәр өч земство реформасы үткәрелә (1864, 1890 һәм 1917 ел). Аларның барысы да үзәктән идарә итүне йомшарту максатын күздә тота. Земство учреждениеләренә *җитәкчелек итүче (земство җыены) һәм башкарма орган (земство идарәсе) керә. Земстволар җитәкче органнарны үзләре сайлыйлар, үз эшчәнлекләренең юнәлешен билгелиләр, кадрларны сайлап алалар һәм укыталар.* Земство органнарының шәхси составы профессиональ түрәләргә керми (чөнки үз вазыйфаларын хөкүмәт билгеләп куйганга түгел, ә җирле халык сайлаганга башкара). Земство учреждениеләре җирле әһәмияттәге практик бурычларны хәл итәләр, алар: халык мәгарифе, сәламәтлекне саклау, мәдәни-агарту эшләре, янгын-иминият һәм юл эшләре, авыл хуҗалыгы, ветеринария, юллар һәм аралашу чаралары, азык-төлек эше, статистика һ.б.

Ихтыяҗлары карала торган төркем һәм затларны турыдан-туры эшкә катнаштыру земство үзидарәсенең принципиаль нигезе була. Шул рәвешле Россия җәмгыятенең катгый тар төркемчелеге ватыла һәм гражданнар җәмгыяте урнаша. Земстволар илне үстерүнең, аны тулаем бердәм итеп саклауның мөһим факторларының берсе була.

Земство идеяләре турында яңадан бары тик 90 елларда гына искә төшерәләр. *«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы, 1995 елның 1 сентябрендә көченә кергән Федераль закон җирле үзидарә реформасының гомуми концепциясен билгеләде.* Анда җирле үзидарә өлкәсендә федераль законнар белән җайга салынырга тиешле мәсьәләләр исемлеге бар.

Җирле үзидарә Россиядә генә түгел, башка илләрдә дә бар. Җирле үзидарәнең Европа Советы кабул иткән һәм

дөнья практикасына гомум кертелгән билгеләмә җирле үзидарәнең **Европа хартиясендә** бирелгән. Хартиядә җирле үзидарә турында ул органнарының, закон кысаларында эш итеп, үз җаваплылыгында һәм җирле халык мәнфәгатьләрендә дәүләт эшләренең шактый өлешен регламентларга һәм аның белән идарә итәргә хокуклы һәм реаль сәләтле диелә. Бу хокук ирекле, яшерен, тигез, туры һәм гомуми җавап бирү юлы белән сайланган әгъзалардан торган советлар яки җыеннар тарафыннан тормышка ашырыла. Советларның яки җыеннарның аларга буйсынган башкарма органнары булырга мөмкин. Җирле үзидарә органнары Хартия тарафыннан демократик стройның нигезе буларак игълан ителәләр, шунлыктан җирле үзидарә принцибы аңа кул куйган барлык илләрнең конституцияләре тарафыннан танылырга тиеш.

*Җирле үзидарә демократик җәмгыятьтә берничә мөһим вазыйфа үти:*

— демократиянең иң борынгы институтларының берсен һәм җәмгыятьнең сәяси системасының мөһим элементын гәүдәләндерә;

— халык белән дәүләт структуралары арасында бәйләп тора торган буын булып тора;

— федераль һәм төбәк программаларын тормышка ашыруның җирле дәрәҗәдәге база буыны булып тора;

— дәүләтне ныгытуга булышлык итә (аның территориаль бөтенлегенә, социаль киеренкелекне һәм милли конфликтларны киметүгә; җирле үзенчәлекләргә ярашкан икътисад формалаштыруга һ.б.);

— халыкның үзенең гражданлык хокукларын һәм ирекләрен тормышка ашыру механизмы булып тора;

— халыкка аеруча якын булган социаль проблемаларның киң даирәсен хәл итү һәм социаль өлкәдә иң мөһим ихтыяҗларны канәгатьләндерү чарасы булып тора;

— җирле органнар көче белән, аларга кайбер дәүләт вәкаләтләре биреп, дәүләт бурычларын хәл итүгә булыша.

Җирле үзидарә белән дәүләт идарәсе арасында дөньяның күпчелек илләрендә танылган характерлы аерымлыклар түбәндәгеләр.

Беренчедән, бу хакимият характеры: дәүләт хакимияте — суверен, югары хакимият, җирле үзидарә органнары — законга буйсынган хакимият, ягъни бирелгән вәкаләтләр чикләрендә эш итә.

Икенчедән, бу — үзәк һәм җирле хакимиятләргә караган эшләр өлкәсен аеру, ягъни җирле үзидарәгә бирелгән эшләр даирәсенең чикләнгәнлеге.

Өченчедән, җирле үзидарәнең мөстәкыйль финанс чыганаклары булырга тиеш.

Дүртенчедән, җирле үзидарә чикләнгән территорияләрдә төзелә.

Бишенчедән, җирле үзидарәгә һәрвакыт сайлау принцибы хас, вәкаләтле яки җитәкчелек органы булу мәҗбүри.

Хәзерге Россиянең үзидарә турындагы гамәлдәге законнары нигезендә, кешеләр *территориаль община* — микрорайонда, квартал, урам, ишегалды, йортта һ.б. яшәүче гражданнарның ирекле, үзидарәле, коммерциячел әгъза булып тормаган оешмасын оештыралар. Алар уставта билгеләнгән уртак максатларны тормышка ашыру өчен мәнфәгатьләр берәмлеге нигезендә ирекле берләшәләр. Аларның берләшмәсе гамәлдәге законнар нигезендә теркәлә. Территориаль общинаның югары җитәкче органы — җыен яки конференция. Общиналарның билгеле бер вәкаләтләре була, аларга шунда яшәүчеләрнең уртак мәнфәгатьләренә кагылган җирле мәсьәләләр, аерым алганда, түбәндәгеләр керә: а) җирле хакимият органнарында бирелә яшәү

челәрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау; б) мәрхәмәтлек һәм хәйрия акцияләре оештыру; в) сәүдә һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү предприятиеләренең кулланучыларның хокукларын саклавына, территорияне чистарту сыйфатына, чүпне чыгаруга, йортларны карап тоту буенча тиешле хезмәтләр эшенә, авария хәлләрен бетерүгә иҗтимагый контрольлек итү; г) балалар һәм үсмерләр белән эшләү, мәдәният-спорт, дәвалау-сәламәтләндерү һ.б. чаралар үткәрүдә булышу; д) яшәүчеләргә торак проблемаларын хәл итүдә ярдәм итү һ.б. Җирле үзидарәнең барлыкка килүе һәм киң таралуы хакимиятне үзәкләштерүнең кире процессы башлануын дәлилли. Аның асылы хакимият вазыйфаларының бер өлешен түбәнрәк дәрәҗәләргә бирүдән гыйбарәт. Урындагы эшләр белән идарә итүгә гражданнарның үзләрен катнашырга җәлеп итү гражданлык җәмгыятендә мәҗбүри рәвештә булырга тиешле социаль контрольнең бик тә зур һәм катлаулы төзелгән механизмының элементы булып тора.

*Җәмгыять өчен җирле үзидарәнең файдасы нәрсәдә?*

Беренчедән, урындагы ихтыяҗлар анда яшәүчеләрнең үзләренә яхшырак таныш.

Икенчедән, җирле үзидарә гражданнарда мөстәкыйльлекне, энергия һәм эшлеклелекне үстерә, алар, үзләренә таянырга күнегеп, хөкүмәттән барлык уңайлыкларны көтеп ятудан туктыйлар.

Өченчедән, җирле үзидарә булганда, иҗтимагый тормыш бөтен дәүләт буенча тигезрәк бүленә, үзәккә тартылмый.

Дүртенчедән, җирле үзидарә администрацияне халык белән бәйли. Гражданнарда шәхси мәнфәгатьләр белән бергә иҗтимагый мәнфәгатьләр барлыкка килә.

Бишенчедән, җирле үзидарә гражданнарга иҗтимагый эшләр белән якыннан һәм практик танышу мөмкинлеге бирә. Һәм, ниһаять, соңгысы, җирле үзидарә югары категория дәүләт эшлеклеләре өчен җирле әзерлек мәктәбе булып тора — алар аның аша гади гражданнарның социаль проблемалары белән танышалар.

---

**Төшенчәләр:** *җирле үзидарә, земство, территориаль община.*

---

**Сораулар һәм биремнәр**

***1.** Белгечләр идарә итүнең цивилизацияле институтлары үз эченә ике системаны: 1) «югарыдан түбәнгә» принцибындагы дәүләт идарәсен һәм 2) «түбәннән югарыга» җирле үзидарәне ала дип исәплиләр. Земство, дәүләт думалары, мәрияләр бу ике системаның кайсысына карыйлар? Җавабыгызны дәлилләгез.

***2.** Тарихи тәҗрибә шуны күрсәтә: конституцион стройга, хокукый дәүләткә, гражданлык җәмгыятенә юл дөрес оештырылган җирле үзидарә аша уза. Үзидарәнең, хокукый дәүләтнең һәм гражданлык җәмгыятенең үзара бәйләнешен ачып бирегез.

***3.** Ни өчен җирле үзидарә бүгенге Россиядә конституцион строй нигезләре элементы әһәмиятенә ия? Җирле үзидарә — халык хакимиятенең беренчел дәрәҗәсе ул дип әйтеп буламы? Җавабыгызны дәлилләгез.

**4.** Җирле үзидарәнең дәүләт идарәсеннән аермасы нәрсәдә? Төп билгеләрне аерып күрсәтегез һәм аларның мәгънәсен билгеләгез.

**5.** Россиядә җирле үзидарә органнары үсешен күзәтегез.

**6.** Җәмгыятьтә җирле үзидарәнең төп вазыйфалары нинди?

**7.** Җирле үзидарәнең җәмгыять өчен файдасы нәрсәдә?

**? Проблема.** Бүгенге Россиядә җирле үзидарә органнары гражданнар тормышында нәрсәне дә булса чынлап торып үзгәртә алалармы?

**Практикум.** А. И. Солженицын «Безгә Россияне ничек итеп үзгәртеп корырга. Көчтән килгән уйланулар» дигән мәкаләсендә кече киңлекләр: зур булмаган шәһәр, поселок, станица, волость (авыллар төркеме) һәм өяз (район) чикләрендә демократия турында сөйли.

Әлеге әйткәннәрнең мәгънәсен билгеләгез. Кече киңлекләр демократиясенең үзидарәгә ни катнашы бар? Әллә бәлки А. Солженицын башка берәр нәрсәне күз алдында тоткандыр?

Җавап бирергә кыенсынсагыз, аңлатулар өчен түбәндәге материалга мөрәҗәгать итегез.

«Кече киңлекләр демократиясе гасырлар дәвамында Россиядә дә була. Ул гасырлар буенча рус авылы дөнья-

сы, ә кайчакларда шәһәр вечелары, казак үзидарәсе булган. Узган гасыр ахырыннан аның тагын бер формасы — кызганычка каршы, бары тик өяз һәм губернаныкы, волость земствосының тамыры булмаган һәм бөтенроссия белән тәмамланмаган земство үсте һәм шактый юл үтте.

Октябрь перевороты теләсә нинди земствоны көчләп ватты, аны баштан ук компартия белән изеп сытылган советлар белән алыштырды. 1918 елдан алып бөтен тарихы белән әлеге советлар яманатлы булды: алар беркайчан да нинди дә булса дәрәҗәдә чын үзидарә булмадылар. Хәзер кертелә торган кыюсыз сайлау үзгәрешләре дә коткара алмый бу форманы: ул астан өскә бөтен структура аша йогынты ясап, җирле мәнфәгатьләрне тәэмин итми. Мин уйлыйм, «депутатлар советлары»н, адымлап, түбәннән югарыга, земство системасы белән алыштырырга кирәк»[3].

[3] *Солженицын А.* Как нам обустроить Россию. Л., 1990. 47–49 битләр.

# 6 бүлек.
# Җәмгыятьнең сәяси тормышы

## § 19. Сәяси тормыш шартлары

**Җәмгыятьнең сәяси тормышы** — ***кешеләрнең (индивидлар, төркемнәр, партияләрнең), җәмгыятьнең сәяси тормышында актив яки пассив катнашуы сәбәпле көндәлек үзара тәэсир итеше һәм үзара мөнәсәбәтләре җыелмасы ул.*** Кемнәрдер партияләргә берләшә, блоклар оештыра, трибунадан яки ММЧ аша агитацияли, кемдер үзен депутатлыкка яки президентлыкка тәкъдим итә, кемдер, сайлау участокларына сирәк кенә барып (яки бөтенләй бармыйча), вакыйгаларны телевизордан пассив кына күзәтә. Шуңа да карамастан, хакимият өчен актив көрәш бара, аны тотып тору механизмнары эшләнә. Безнең тавышлардан кемдер файдаланырга, безнең катнашмавыбыз кемгәдер файда гына булырга мөмкин. Хакимияткә кемдер башка кеше килде, бөтенләй дә без теләгәнне эшләмәде. Ризасызлык белдереп, без инициативаны бөтенләй башка кешегә биреп, йә пассив дәшмибез, йә байлар хакимиятенә каршы баш күтәрәбез, ә бит алар югарыга безнең аркада менгән, чөнки без йә алай сайламаганбыз, йә ул вакытта дәшмәгәнбез. Шулай итеп, сәяси тормыш барыбызга да кагыла.

Гражданнар өчен җәмгыятьнең сәяси тормышында актив катнашу мөмкинлеге күп шартларга бәйле. Ил белән идарә итү формасы — шуларның берсе генә. *Сәяси режим* мөһим роль уйный.

**СӘЯСИ РЕЖИМ** — дәүләт хакимиятен тормышка ашыру алымнары системасы, шәхеснең демократик хокукларын һәм ирекләрен гамәлгә ашыру дәрәҗәсе, хакимиятнең үз эшчәнлегенең хокукый нигезләренә мөнәсәбәте, рәсми конституцион һәм хокукый формаларның чын сәяси тормыш белән нисбәте.

***Сәяси режимнарның ике төп тибы яши — демократик һәм демократик булмаган, аларның һәрберсе үз эчендә берничә төргә бүленә. Демократик режимнарга*** идарә итүнең төп рольне *парламент* — коллектив законнар чыгару органы уйнаган формалары керә. Шунлыктан демократик режимнар өчен икенче исем булып парламент режимы атамасы хезмәт итә. Республика — моңа ачык мисал.

***Демократик булмаган*** режимнарга идарә итүнең чикләнмәгән хакимият бер кешегә бирелгән формалары керә. Бу — идарә итүнең *авторитар* (бер кешеле) формалары.

Авторитар режимнарның барысына да сәяси оппозиция һәм ирекнең юклыгын, дәүләтнең эчке проблемаларын хәл итү өчен файдаланыла торган тармакланган полиция аппараты һәм көчле армия хас. Газета, радио һәм телевидение — идарәче партия идеяләрен пропагандалау каналлары, ә мәктәпләр һәм университетлар рәсми идеология рухындагы сәяси социальләшү чарасы булып хезмәт итәләр. Сәнгать әсәрләре һәм фән катгый сәяси цензура аша үтә, дин идарәче партия диктаты астында кала, әлеге партия икътисадны да тулысынча контрольдә тота.

Авторитар идарә итү формаларының берсе — *тоталитаризм* (соңгы лат. totalis — бөтен, тулы). Идарә итүнең тоталитар формалары беренче тапкыр 1914–1919 еллардагы беренче бөтендөнья сугышыннан соң барлыкка килә. Тоталитар дәүләттә җәмгыять тормышының барлык өлкәләре тулы контроль астында була. Анда шәхес һәм гражданлык ирекләре бастырыла, кешенең сәяси караш-гадәтләре сакланмый, закон идарәче сыйныф яки идарәчегә яраклаштырып чыгарыла. Барча гражданнарның закон алдындагы тигезлеге сакланмый.

Сәяси тормышта катнашу мөмкинлеген, хокукларны һәм ирекләрне гражданнарга *демократик режимнар* бирә. Андый режим вакытында җәмгыятьтә барлык сәяси,



социаль һәм икътисади тормыш парламенттан башлана, аның аша законлы көч ала һәм аның тарафыннан контрольдә тотыла. Парламент халык тарафыннан конституция билгеләгән система буенча сайлана һәм законнар чыгару вазыйфасын башкара. Хакимиятләр кабул иткән һәр принципиаль карар халыкның *мәҗбүри тавыш бирүен* үткән җәмгыять кенә чын демократик булып исәпләнә. Кагыйдә буларак, тавыш бирү системасы бик тә катлаулы. Андый җәмгыятьләрнең күпчелегендә «вәкаләтле демократия» дигән система сакланган. Халык фикерен үз сайлау округларында җиңгән кешеләр чагылдыра. ***Демократик җәмгыятьтә гражданнар сәяси эшчәнлектә актив катнашу мөмкинлеге бирә торган күп кенә сәяси хокукларга һәм ирекләргә: сайлау һәм сайлану хокукына, сүз, матбугат, җыелышлар һәм митинглар, берләкләр ирегенә, хакимият органнарына шәхси һәм күмәк мөрәҗәгатьләр (петицияләр) җибәрү хокукына ия.***

Сәяси тормышта катнашу хокукына бары тик шул ил гражданнары гына ия. Борынгы заманнардан бирле шулай булган һәм берничә мең еллар дәвамында ярлылар, коллар, плебейлар һәм хатын-кызлар гражданлык хокуклары һәм ирекләре алу өчен көрәшкән. Игълан ителмәгән әлеге сугыш дистәләрчә мең тормышны алып киткән, шулай да бүгенге демократияләрдә, кагыйдә буларак, җенескә, раса, профессия, дин тотуга, милләткә карап кимсетү юк. Ләкин бер кимсетү кала — *гражданлык* булу-булмау, ә аны алу барлык илләрдә дә бик үк җиңел түгел. Бөтен дөньядан миллионлаган кешеләр күчеп килгән АКШта ул болайрак эшләнә.

***Әлеге дәүләт территориясендә яшәү кешене автомат рәвештә аның гражданины итми.*** АКШка һәр ел саен миллионнан артык иммигрант килә. Аларга башта яшәү мөмкинлеге бирәләр, алар Америка гражданнары файдаланган барлык хокуклардан диярлек: медицина иминияте, эшсезлек буенча пособие, төрле социаль дотацияләрдән файдаланалар, лицензияләр алалар һәм эшкә урнашырга мөмкиннәр һ.б. Ләкин алар сайлау хокукыннан һәм дәүләт постларына сайлану хокукыннан мәхрүм. Аларны *резидентлар* дип кенә атыйлар.

АКШта иммигрантка яшәү хокукы алганнан соң тавыш бирү хокукы алу өчен тагын берничә ел яшәргә кирәк. Шуннан соң гына ул АКШ гражданины булып санала. ***Андый хокуклар алу процессы натуральләштерү — кешене аның үтенече буенча нинди дә булса илнең гражданлыгына яки гражданлыгында булуга (мәсәлән, озак яшәү очрагында) кабул итү дип атала.*** Моңа кадәр кеше илнең гражданины булып саналмый. Гражданлык алганнан соң кеше барлык гражданлык хокукларыннан файдалана башлый. Балалар һәм үсмерләрнең тулы гражданлык статусы булмый, чөнки аларның сайлау хокуклары һәм өлкәннәр генә ия булган кайбер башка хокуклары юк. Аларны ил конституциясе гарантияләгән хокуклар яклый. Хөкем ителгәннәр күп илләрдә гадәттә гражданлык хокукларын югалталар. Алар сайлый һәм дәүләт органнарына сайлана алмый.

Кешеләр гражданлыкны кабул итәләр, гражданлыктан үзләре теләп баш тарталар. Аны аның теләгеннән башка мәхрүм итә алалар. 30 елларда Сталин лагерьларына эләккән совет сәяси тоткыннары белән соңрак башкача фикер йөртүчеләрне (А. И. Солженицын) илдән көчләп куып чыгарганда шулай эшләделәр. Гражданлыгы булмаган кешеләр — *апатридлар* (гр. apatris һәм apolis — ватаныннан, иленнән мәхрүм ителгән), ә ике яки берничә гражданлыгы булганнар *бипатридлар* (лат. bi — ике һәм гр. patris, иялек килеш patridos — ватан, ил) дип атала. Гражданлыктан мәхрүм ителгән, илдән куылган *экспатрид* дип исәпләнә.

АКШ, Канада һәм Австралия XX гасыр дәвамында иммигрантларга гражданлык хокукларын бик теләп бирделәр, шуның белән эшче көчләрне арттырдылар, җитеш-

теру һәм хезмәт күрсәтү өлкәләрен киңәйттеләр, икътисади куәтләрен үстерделәр. Йөзьеллык ахырында алар виза бирүне чикләделәр, чәчәк ата торган илдә яшәргә теләүче агымны туктаттылар. Илчелекләрдә таләпләр катгыйланды. СССР яшәгән чорда америкалылар, демократик илнең вөҗдан тоткыннарына сәяси сыену урыны бирергә тиешлекләрен истә тотып, барлык сәяси иммигрантларны кабул итсәләр, ул ил таркалган һәм демократик принципларның өстенлеген таныган Россия Федерациясе оешу чорында сәяси критерийлар яшәүдән туктады. Әмма квалификацион-профессиональ критерийлар яшәп калды. Бу, әлеге илләр үзләренә югары квалификацияле белгечләрне, шул исәптән галимнәрне, даһи рәссамнар, артистларны кабул итә, тик аз квалификацияле хезмәт кешеләрен түгел, дигәнне аңлата. Нәтиҗәдә, Россия аларны укытуга күп акча түккән дистәләрчә мең белгеч бушлай гына башка илнеке булды (галимнәрнең күпләп китүен «миләрнең китүе» дип атадылар). Әлеге ил аларга яшәү, үзләренең иҗат мөмкинлекләрен үстерү, үз көчләрен кирәкле урында куллану мөмкинлеге тудырды.

Алга киткән Европа илләре — Англия, Франция, Германия — Икенче Бөтендөнья сугышыннан соң үз илләренә иммиграцияне хуплый һәм Италия, Греция, Испания, Төньяк Африка һәм Якын Көнчыгыштан чыккан кешеләргә бик теләп гражданлык бирәләр. Ләкин 70 еллар башында икътисади кризис башланып, миллионнарча кеше эшсез кала. Төп халык аларның эш урыннарын алган чит ил кешеләрен кертүне яклаган хөкүмәткә ачуларын белдерә башлый. Моңа җавап итеп, әлеге илләрнең хөкүмәтләре эмигрантларны кире җибәрергә күп мәртәбәләр тырышса да, бу тырышлыклар уңышсыз тәмамлана.

Гражданлык хокукы бирү турындагы законнар һәркайда төрлечә. Моның өчен барыннан да элек бу илдә берничә ел дәвамында яшәү, монда даими яшәү нияте, билгеле бер яшьтән өлкәнрәк булмау, үзеңне-үзең тәэмин итү хәлендә булу, әлеге ил телен белү, сәламәт һәм ачык йөзле булу, элеккеге гражданлык сезне инде кызыксындырмавын эштә исбатлау таләп ителә. Читтә яшәүче ата-анадан туган балалар, әгәр ата-анасының берсе генә дә Америка гражданы булса, АКШ гражданины булып санала.

| Ничек итеп АКШ гражданины булырга | АКШ гражданлыгын ничек югалтырга |
|---|---|
| бу илдә туарга;<br>ата-ана буларак, гражданлык алырга; | башка илдә натуральләшү;<br>башка илгә тугрылыкка ант итү; |
| бу ил гражданына өйләнергә яки кияүгә чыгарга; | хакимият ризалыгыннан башка чит ил армиясендә хезмәт итү; |
| натуральләшергә. | чит ил хөкүмәтендә эшләү; |
| | чит илдә тавыш бирү һәм сайлану; |
| | язма рәвештә һәм кабул ителгәнчә Америка гражданлыгыннан баш тарту; |
| | дәүләткә хыянәт итү; |
| | АКШ хөкүмәтен бәреп төшерергә омтылу; |
| | ике гражданлыкта булып, АКШтан читтә өч ел яшәү. |

Политологиядә һәм юридик фәндә гражданлык әле зат белән дәүләтнең үзара хокукларында һәм бурычларында чагыла торган даими сәяси-хокукый элемтәсен дә аңлата. 1948 елгы Бөтенгомум кеше хокуклары декларациясе, кеше хокуклары турында халыкара пактлар нигезендә беркем дә гражданлыгыннан яки аны алыштыру хокукыннан мәхрүм ителә алмый. Кайда гына булмасын, һәр гражданинга дәүләт хокукый яклау гарантияли. Гражданлыктан мәхрүм ителгән кешеләрне конституция инде яклямый. Санап үтелгән нигезләмәләр Россия Федерациясенең 1991 елгы Кеше хокуклары һәм ирекләре декларациясендә бар. Россиядә гражданлык турындагы закон 1991 елда кабул ителде.

Монархиячел идарә итү формалы дәүләтләрдә кешенең бу илнеке икәнен белдерү өчен «гражданлык» атамасы урынына «подданство» сүзе кулланыла.

Гражданлыкның асылы әлеге илнең конституциясен тануда гына түгел, ә аның башлыгын һәм идарә итүнең

югары сәяси органнарын сайлауда катнашу мөмкинлегендә дә тора. Сайлау кампаниясендә катнашуга формаль хокуктан тыш, «гражданлык» төшенчәсенәниндидер эчтәлекле билгеләр, әйтик, кешеләрнең сәяси активлыгын да кертергә кирәктер. Алар белән эш бик җиңел генә тормый. Кайбер илләрдә гражданнарның сәяси активлыгы югары, алар хакимиятнең һәртөрле органнары, учреждение, фонд, хәрәкәтләре һ.б. актив катнашалар, ә икенчеләрендә ул бик тә түбән. Мондый очракларда, хакимият белән халык арасында читләшү барлыкка килгән диләр. Халык үз дәүләтенә ышанмый, чөнки тегесе аны моңарчы күп тапкырлар алдаган. Беренче очракта кешеләр үзләрен чын гражданнар һәм патриотлар итеп хис итәләр, икенчесендә күпләр ватаннарын ташлап китәргә әзер, тик төрле сәбәпләр аркасында моны эшли алмыйлар. Беренче очракта бу илгә башка илләрдән кешеләр күчеп килә, икенчесендә аннан башка илләргә китәләр.

Шулай итеп, гражданнарның гражданлык пассивлыгында беренче чиратта алар өчен берни эшләми торган дәүләт гаепле. Гражданнарның үзендә дә гаеп аз түгел, чөнки үзләренә болай мөрәҗәгать итәргә алар үзләре юл куйган, ягъни гражданнарның үзләрен тотышлары һәм дәүләтнең алар белән эш итүе — үзара бәйләнгән нәрсәләр. Аларның һәрберсе икенчесенең сәбәбе һәм нәтиҗәсе булып тора. Тоталитар дәүләттә гражданнарны хокукый яклау юк, яисә ул бик түбән, ә гражданнар сәяси пассивлык белән җавап бирәләр. Әлбәттә, алар сайлау урналары янына килергә, шимбә өмәләренә һәм бәйрәм демонстрацияләренә чыгарга, күпләгән җәмгыять эшләре эшләргә мөмкиннәр, ләкин болар ирексездән, теләмичә, баш тартсаң, үзеңә зыян килереннән куркудан эшләнә. Мондый активлыкны тышкы активлык дип атарга кирәк. Бу аңлашыла да, чөнки дәүләт аларга бөтенләй бәйле түгел диярлек. Алар идарә итүдән читләштерелгән, димәк, идарә итү карарлары кабул итүдә актив катнашуны таләп итеп тә булмый.

---

**Төшенчәләр**: *сәяси режим, авторитар режим, тоталитар режим, демократик режим, гражданлык, натуральләштерү.*

---

**Сораулар һәм биремнәр**

*1. Хокукый дәүләт белән гражданлык җәмгыятен чагыштырыгыз. Нинди нәтиҗәләр ясый аласыз? Сез хокукый дәүләтнең нинди билгеләрен беләсез?

*2. Ике төрле фикер бирелгән:
— кеше хокукларын саклау — илнең эчке эше;
— кеше хокукларын саклау — гомумкешелек проблемасы.
Әйтегез, аларның кайсысы
— тоталитар җәмгыятьне;
— хокукый дәүләтне характерлый.

3. Тоталитар дәүләткә нәрсә хас:
— басым ясау аппараты;
— башкача уйлаучыларны эзәрлекләү;
— катгый цензура һәм сүз ирекен бетерү;
— бер сәяси партия диктатурасы;
— дәүләт милке монополиясе;
— үз халкына каршы геноцид;
— шәхесне баету, дәүләттән аеру.

4. Нәрсә ул хакимиятнең бер кешеле режимнары? Аларга монархия, диктатура, президентлык республикасы, тирания, демократияне кертеп буламы?

5. Нәрсә ул гражданлык һәм ул практикада нәрсәдә чагыла? Сезнең гражданлыгыгыз бармы?

6. Нәрсә ул натуральләштерү? Ул ничек формалаштырыла?

**? Проблема.** «Гражданин булу» нәрсәне аңлата?

**Практикум 1.** Түбәндәге раслауларны кире кагыгыз яки аларның дөреслеген исбатлагыз:
— «дәүләт» төшенчәсе «җәмгыять» төшенчәсеннән киңрәк;
— «дәүләт» һәм «җәмгыять» төшенчәләре күләмнәре белән туры киләләр, ләкин эчтәлекләре буенча аерылалар;
— монархия, республика, демократия хокукый дәүләт типларын тасвирлыйлар;
— җәмгыятькә — сыйныфлар, ә дәүләткә идарә итү типлары керә;
— Борынгы Грециядә, демократиянең ныклы фундаменты өстендә гражданлык җәмгыяте һәм дәүләт якын ук килгәннәр;

— Борынгы Мисырда, киресенчә, дәүләт җәмгыятьне изгән. Алар капма-каршы торганнар;

— Көнчыгыш деспотлыгы — тоталитар дәүләтнең бер төре.

**Практикум 2.** Үз реформалары белән XIX гасырны алдан әзерләп куйган Екатерина IIдән башлап, алга таба маятник сыман либераль дәверне реакцион дәвер алыштырган һәм киресенчә. Монархлар саны белән исәпләгәндә, рус тарихында беренче сәнәгать революциясенең беренче 100 елындагы 6 чоры болай күренә: өч тапкыр алга, өч тапкыр артка.

Әлеге закончалыкны анализлагыз.

## § 20. Сәяси тормышны идарә итү формалары һәм гражданнарның катнашу механизмнары

Гражданнарның һәм аларның берләшмәләренең катнашу механизмнарына илнең югары законнар чыгару, суд һәм башкарма органнарында аларның мәнфәгатьләрен күрсәтүне һәм яклауны тәэмин итә торган сәяси институтларны һәм учреждениеләрне кертергә кирәк. Мисал итеп сайлау хокукын һәм тавыш бирүне, кандидатлар күрсәтүне һәм сайлауны, сәяси партияләр һәм ассоциацияләр оештыруны, вәкаләтлек институтын (борынгы халык трибуналары һәм бүгенгеге халык депутатлары), гражданлык институтын, ММЧ эшчәнлеген һ.б. кертергә була.

*Сайлау хокукы дигәндә ике күренеш аңлана:* 1) дәүләт башлыгын, вәкаләтле органнарны һ.б. сайлау тәртибен урнаштыра торган хокук нормалары җыелмасы; 2) гражданның сайлауларга катнашуы, сайлау (актив сайлау хокукы) һәм сайлану (пассив сайлау хокукы) хокукы.

***Сайлау хокукы, гадәттә, конституция һәм сайлаулар турындагы махсус законнар белән регламентлана.*** Кандидатлар күрсәтү тәртибе, вәкаләтлек формалары, тавыш бирү нәтиҗәләрен билгеләү тәртибе һ.б. билгеләнә. *Сайлау хокукы кешеләргә сәяси карарлар кабул итүгә йогынты ясауның бик тә куәтле каналларын бирә.*

***Гражданнарның илнең сәяси тормышында катнашуының төрле формалары бар: сәяси һәм иҗтима-***

***гый хэрэкэтлэрдэ катнашу, тәкъдимнәр һәм проектлар белән парламентка һәм хакимиятнең җирле законнар чыгару органнарына мөрәҗәгать итү, җыелышларда һәм митингларда катнашу, теге яки бу партия өчен агитацияләү, партия функционеры булып эшләү, сәяси клубта яки оешмада әгъза булып тору, партия файдасына акча бирү.***

**ТАВЫШ БИРҮ** — гражданнарның илнең сәяси тормышында катнашу формаларының берсе.

Тавыш бирү тәртибе барлык илләрдә дә якынча бер үк: 1) яшәгән урын буенча сайлаучылар исемлегендә теркәлү; 2) махсус кабинада яшерен сайлау; 3) барлык сайлау округлары өчен дә бер үк булган кандидатлар исемлеген куллану; 4) сайлауларда тавыш бирү тәртибенең дөреслегенә контрольлек итүче бәйсез күзәтүчеләр булу; 5) махсус оештырылган комиссиянең бюллетеньнәрне санавы; 6) тавыш бирү нәтиҗәләрен рәсми бастырып чыгару.

**Сайлаулар** гражданнарга тавыш бирү вакытында берничә бәйсез кандидат тәкъдим ителүен, аның алар арасыннан үз теләге белән берсен сайлавын күздә тота. Күпчелек илләрдә сайлаучылар альтернатив нигездә үтә, ягъни сайлаучыларга күп кандидатуралар арасыннан берсен сайлау мөмкинлеге бирелә. Сайлаулар бер яки ике турда үтәргә мөмкин. Әгәр беренче турда берничә кандидат арасыннан берсе дә тавышларның яртысыннан күбрәген ала алмаса, икенче тур үткәрелә.

Җәмгыятьтә дәүләтнең төзелешен һәм сәяси тормышын халыкның аеруча мөһим мәсьәләләр буенча үз ихтыярын белдерү ысулы яхшырак билгеле. Референдум институты — шул ысулларның берсе булып тора.

**РЕФЕРЕНДУМ** — гомуми тавыш бирү юлы белән законнарны яки дәүләт тормышының бик тә мөһим мәсьәләләрен хәл итү формасы.

Ул җәмгыять өчен бик тә мөһим мәсьәләләрне бөтенхалык тавыш бирүе белән хәл итүне күздә тота; әлеге тавыш бирү нәтиҗәләре югары хокукый статуска ия һәм барлык дәүләт органнарының үтәве өчен мәҗбүри булып тора. Референдум дөньяның күпчелек демократик дәүләтләре



тарафыннан законнар чыгару механизмы сыйфатында кулланыла.

Теләсә кайсы дәүләттә сәясәтне күпчелек халыкның яклавын тапкан һәм үз функционерлары аша теге яки бу төркем, катлау, сыйныфлар мәнфәгатьләрен чагылдыра торган партияләр билгеле. Алар сайлаучыларның тавышлары өчен көрәшәләр һәм күпчелек очракта хакимияткә тыныч юл белән киләләр.

> **СӘЯСИ ПАРТИЯ** — гомуми сәяси программаны уртаклаша торган һәм законлы юл белән хакимияткә килергә, үз президентын куярга һәм үз хөкүмәтен формалаштырырга омтылучы кешеләрнең оешкан төркеме.

Парламентка депутатларны халык сайласа, партия җитәкчеләрен партия җыелышларында яки съездларында сайлыйлар. Барлык партия әгъзалары акчалата взнос түли, аңа партия аппараты тотыла, партия чаралары үткәрелә, партия әдәбияты нәшер ителә һ.б. ***Парламент, президент яки муниципаль сайлауларда нинди дә булса сәяси партия өчен тавыш бирүче сайлаучылар даирәсе электорат дип атала.*** Партияләр башта үз электоратларын булдыру, аннары аны киңәйтү һәм тоту өчен көрәшәләр, электоратлар өчен үзара ярышалар. Аларның һәрберсенең үз үзенчәлеге була.

Партияләр үз сайлаучылары белән хөкүмәт арасында арадашчылар кебек эш итәләр, шул ук вакытта үз лидерларын хакимияткә үткәрү механизмнары булып торалар.

***Сәяси партия түбәндәге вазыйфаларны башкара:***

— **сәяси** — дәүләт хакимиятенә ия булу;

— **вәкаләтле** — халыкның билгеле бер төркеме һәм катлавы мәнфәгатьләрен чагылдыру;

— ***рекрутор*** — төрле сәяси институтлар өчен кадрлар әзерләү һәм тәкъдим итү;

— **электораль** — сайлау кампанияләрен оештыру һәм аларда катнашу;

— **социальләштерү** — тугрылыклы әгъзалар әзерләү һәм гражданнарның сәяси культурасын формалаштыру.

Партия вазыйфаларының берсе — парламент һәм хөкүмәт өчен сәяси укымышлы лидерлар *сайлап алу һәм тәкъдим итү*. Профессиональ сәясәтчеләр артыннан партиядән хакимияткә алар даирәсендәге аппарат: партия экспертлары, аналитиклар, белгечләр килә.

***Һәр сәяси партия нәрсәләргә ия:***

— **партиянең максатлары** һәм стратегиясе формалаштырылган сәяси программа;

— партиянең эчке тормышының мөһим нормаларын эченә алган **партия уставы;**

— **җитәкче органнары** (үзәк комитет) һәм партия функционерлары аппараты (ешрак башка эштән азат кешеләр);

— ирекле активистлардан торучы тармакланган **башлангыч җирле оешмалар** челтәре;

— дәүләттә **югары хакимият өчен көрәштә** актив **катнашу;**

— **партия әгъзалары исемлеге.**

> **СӘЯСИ ПРОГРАММА** — җәмгыятьнең киләчәген сурәтләгән, хакимият башында торган хөкүмәтне тәнкыйтьләүне, халык алдында торган четерекле социаль һәм икътисади проблемаларны хәл итү чараларын һәм механизмнарын гәүдәләндерә торган нигезләмәләр җыелмасы.

Сәяси программаның төше — ***сәяси философия*** — үзенең тамырлары белән теге яки бу дөньякүләм сәяси системага — ***коммунизмга***, коммунизмның түбән баскычы буларак *социализмга, либерализм, консерватизм, фашизмга* барып тоташучы ***җәмгыятьне дөрес төзүгә төгәл карашлар системасы.*** Нәкъ менә сәяси философия үзенчәлекле

гыйлем үзәге булып тора, ә конкретрак фикерләр белән тутырылган программа үзе аның практик кулланмасы вазыйфасын үти.

Сәяси философиянең төп типларына **коммунизм, либерализм, консерватизм** һәм **фашизмны** кертәләр.

**Коммунизм** (лат. communis — гомуми) — нигезендә хосусый милекне инкарь итү яткан төрле концепцияләрнең (борынгы заман коммунизмы, утопик коммунизм һ.б.) гомуми исеме.

Тарихи процессның марксистик концепциясендә иҗтимагый-икътисади формация үз үсешендә ике баскыч (фаза) үтә: түбәндәгесе — социализм һәм югарыгысы — коммунизм. *Социализмны* күпләгән тәгълиматлар яктырта, аларда максат һәм идеал сыйфатында социаль гаделлек, ирек һәм тигезлек принципларын, шулай ук әлеге принципларны гәүдәләндерә торган иҗтимагый стройны тормышка ашыру алга куела. Гәрчә социаль гаделлек строе турындагы күзаллаулар «алтын гасыр» турындагы борынгы идеяләргә барып тоташса да, «социализм» атамасы XIX гасырның икенче яртысында барлыкка килә. Бүгенге социализм сәяси философия буларак утопик социализм идеяләрендә төзелгән, аның иң югары формасы булып К. Маркс һәм Ф. Энгельс эшләгән фәнни социализм теориясе хезмәт итә. Алар пролетар революция һәм пролетариат диктатурасы урнаштыру нәтиҗәсендә капитализмга алмашка килгән социализмны коммунизмның түбәнге фазасы (баскычы) дип карыйлар.

*Утопик социализм* — бердәм милеккә, мәҗбүри хезмәткә, гадел бүлүгә нигезләнгән идеаль җәмгыять турындагы тәгълимат. Үз максаты итеп фәнни социализм идеяләрен практикада гәүдәләндерүне игълан иткән 1917 елгы Октябрь революциясеннән соң ул халыкара социалистик хәрәкәт бүленгән ике юнәлештә: коммунистик һәм социал-демократик юнәлешләрдә үсә. *Социал-демократик агымда* капитализмны реформалаштыруга юнәлеш тоту раслана. Шактый эволюция кичереп, бердәнбер идея нигезе буларак марксизмнан баш тартып, социал-демократия демократик социализмның бүгенге концепциясен эшли; аның буенча социализм — капитализм реформалашуның, сәяси, икътисади һәм социаль демократияне, шулай ук ирек, гаделлек, бердәмлек һәм тигезлек кыйммәтләрен

раслауның озак процессында гамәлгә ашырыла ала. Социал-демократиянең сәясәте хакимият һәм милек мөнәсәбәтләрен демократлаштыруга, ялланган хезмәткәрләрнең тормыш дәрәҗәсенә һәм сыйфатына йогынты ясый һәм башка факторлар белән бергә капиталистик җәмгыятьне шактый үзгәртүгә китерә.

*Коммунистик агымда*, социализм вакытында дәүләт милке монополиясе, директив үзәкләштерелгән планлаштыру, башбаштаклык, законсызлык, башкача фикер йөртүгә түзә алмаучанлык белән тулы көчләү һәм массакүләм репрессияләргә таянган партия-дәүләт аппаратының югары катлавының диктатурасы яши. Тоталитар режимның хакимлек итүе икътисади, сәяси һәм рухи кризиска, дөньяның алга киткән илләреннән шактый артта калуга, дөньякүләм мәдәнияттән аерылуга китерә. Узган гасырның 80 еллар ахыры — 90 еллар башында СССРда, Россиядә һәм башка илләрдә башланган үзгәртеп корулар базар икътисадына һәм демократиягә күчүгә юнәлдерелгәннәр.

**Либерализм** (лат. liberalis — ирекле) — Европа илләрендә XVII–XVIII гасырларда барлыкка килгән һәм гражданлык, сәяси, икътисади ирекләр игълан иткән идея һәм иҗтимагый-сәясәт агымы. Либерализм чыганаклары Дж. Локк, А. Смит, Ш. Монтескьё һәм башка философлар һәм икътисадчыларның абсолютизмга һәм федераль тәртипләргә каршы юнәлдерелгән концепцияләрендә чагыла. Либерализм идеяләре беренче тапкыр АКШ Конституциясендә (1787) һәм Франциянең Кеше һәм гражданин хокуклары декларациясендә (1789) гәүдәләнеш таба. XIX гасыр — XX гасыр башында либерализмның төп нигезләмәләре формалаша: гражданлык җәмгыяте, шәхеснең хокуклары һәм ирекләре, хокукый дәүләт, демократик сәяси институтлар, шәхси эшмәкәрлек һәм сәүдә иреге. Бүгенге яңа либерализм (неолиберализм), ирекле базар механизмы нәтиҗәле икътисади эшчәнлек, социаль һәм икътисади процессларны җайга салу өчен тагын да уңайлырак алшартлар тудыра, шуның белән бергә дәүләтнең даими тыкшынуы базарның, көндәшлекнең эшләве өчен нормаль шартлар булдыру өчен кирәк дигәннән чыгып эш итә. XX гасыр ахырында либерализм, консерватизм һәм социал-демократия идеяләре якыная.

**Консерватизм** (фр. conservatism, лат. conservo — саклыйм) — социаль һәм мәдәни тормышта традицияләр һәм дәвамчанлык идеясенә таяна торган идея-сәяси һәм мәдәни агымнар җыелмасы. Аңа яки урнашкан социаль системаларга һәм нормаларга тугрылыклы булу, революцияләрне һәм радикаль реформаларны кабул итмәү, эволюцион үсешне яклау хас. Консерватизм дәүләтнең икътисадка һәм гражданнарның шәхси тормышына катнашуына каршы, социаль тигезсезлекне бетерү, дәүләтнең ярлыларга ярдәм итүе яклы. Социаль үзгәреш шартларында консерватизм иске тәртипләрне яңарту, югалган позицияләрне торгызу, үткәннәрне идеаллаштыру таләпләрендә чагыла. «Консерватизм» атамасын беренче тапкыр француз язучысы һәм сәяси эшлеклесе Ф. Шатобриан XVIII гасыр ахыры Франция революциясе чоры аристократиясенең идеологиясен чагылдыручы концепция буларак куллана.

**Фашизм** (итал. fascismo, fascio дан — бәйләм, учма, берләшмә) төп милләтнең раса өстенлеге идеясенә корылган, ягъни ул милләтнең «иң яхшы» өлеше (элитасы) җәмгыятьнең сәяси һәм социаль тормышы белән идарә итәргә тиеш. Фашизм җәмгыятьне каты тәртип, бердәнбер лидерга ышану коткарачак дигән инануга корылган идеологияне алга сөрә. Ул демократиягә тоталитар режимны каршы куя, бердәнбер массакүләм сәяси партиягә һәм «юлбашчы»ның, «фюрер»ның кагылгысыз абруена таяна. Массакүләм террорны ул «милләт дошманнары»на — идея дошманнарына карата куллана, ә шовинизм идеологиясе ярдәмендә фашизм «түбән» раса вәкилләрен һәм «тулы булмаган» халыкларны эзәрлекләүне аклый. Фашизм тибындагы хәрәкәтләр демагогияне, популизмны, социализм, империя державачылыгы, сугышны мактау лозунгларын киң куллана. Фашизм күпчелек гомуммилли кризислар һәм үзгәртүләр катаклизмнары шартларында социаль җәберләнгән төркемнәрдә таяныч таба. Җәмгыятьне сәяси туплау, террорчылык хакимлеге һәм пропагандасы ысуллары белән фашизмга сталинизм, маоизм, «кызыл кхмерлар» һ.б. ның тоталитар режимнары якын тора.

Партияләр үзләренең сәяси программалары, идеологияләре, җәмгыятьтәге урыннары һәм рольләре, алар яклыларның саны белән генә түгел, эчке оешулары белән дә

аерылалар. Кайбер партияләрнең каты дисциплинасы һәм иерархиясе булмый, күбрәк клубны хәтерләтәләр. Башкалары каты тәртип, иерархия, үзәкләштерелгән структура белән аерылып тора. Партия уставын нык бозган өчен партия әгъзасын, барлык өстенлекләрдән мәхрүм итеп, партиядән чыгарырга, вак бозулар өчен (мәсәлән, взнос түләмәгәнгә) каты шелтә белдерергә мөмкиннәр. Монда партия бурычларын төгәл вакытында, сыйфатлы итеп, тәртипле үтиләр.

Ләкин сәяси партия ничек кенә катгый яки йомшак булмасын, зур булып үскәч, ул шундук күпләгән төбәк вәкиллекләре, ячейкалары, башлангыч бюро, секция, бүлек һәм бүлекчәләре булган бик тә зур пирамидага әверелә. Аның түбәнге дәрәҗәсен партия өчен үз тавышларын биргән гади гражданнар тәшкил итә. Аннан соңгы катны партия функционерлары белән бергә партиянең җирле идарә органнары били.

Өченче баскычта төбәк хезмәтләре барлыкка килә, ә өстәрәк гомумдәүләтнекеләр тора. Сәнәгать корпорациясендәге кебек үк команда өстән аска килә, урыннардагы үтәлеш контрольдә тотыла, ә шикаятьләр һәм петицияләр астан өскә йөри. Прокламация, брошюра, плакатларны һ.б. исәпләгәндә, бик тә зур партия машинасы бернинди дә продукция чыгармый, куллану хезмәтләре күрсәтми. Ул чираттагы сайлауларга әзерләнеп, 4 яки 5 елга бер тапкыр туплана. Ул чакта бу машинада барысы да әйләнә, чаба, агитацияли, чыгыш ясый, кул куя, җыя, анализлый һәм өнди. Партия оешмасының башлангыч ячейкасы булып сайлау округы тора, анда төрле партия вәкилләре туктаусыз агитация алып бара, сайлауларны оештыруда катнаша, ә аннары, җирле дәрәҗәдә җиңүгә ирешкән очракта, край администрациясе органнарына керә. Дөресен әйткәндә, аларның күпчелеге шуңа омтыла да, чөнки һәр партия төп максат итеп хакимият өчен көрәшне куя.

Күләме буенча бик зур булмаган партия үзәге, кешеләр массасын үзенең активлыгы һәм максатка омтылучанлыгы белән рухландырып, бик тә зур нәтиҗәләргә ирешә. Сайлауларда җиңүгә ирешкән яки законнар чыгару органнарына үз вәкилләрен үткәрүгә ирешкән партияләр җитәкче элитаны формалаштыруда, идарә итүче кадрларны сай-

лап алуда һәм куюда катнашу, ә алар аша принципиаль карарлар кабул итүгә йогынты ясау мөмкинлеге алалар. Сайлаудан соңгы стадия партияләр арасында килешүләр төзү, җиңгән партияләрнең коалицияләрен, берлекләрен һәм блокларын оештыру белән характерлана.

***Илдә булган һәм эш иткән барлык партияләр бары-сы бергә партия системасы дип атала. Алар: а) бер партияле, б) ике партияле һәм в) күп партияле булыр-га мөмкиннәр.*** Кытайда һәм Кубада — бер партияле, АКШ, Англия һәм Канадада — ике партияле, Европа державаларының күпчелегендә, аерым алганда, Германия, Италия, Бельгиядә күп партияле система. Авторитар режимнарда хакимияттә бер партия була. Калганнары йә тыелган, йә ярым яшерен хәлдә. 1991 елда СССР конституциясенең 6 маддәсе юкка чыгарылгач, дөньяда территориясе буенча иң зур илдә бер партияле система яшәүдән туктады. Россия Федерациясе Конституциясендә сәяси күп төрлелек һәм күп партиялелек танылa (13 маддә). Барлык иҗтимагый берләшмәләр тигез хокуклы. Хәзерге вакытта безнең илдә дистәләрчә сәяси партия бар, ләкин аларның күбесенең чын социаль базасы, башлангыч оешмаларының тармаклы челтәре юк, әгъза саны бик аз.

2001 елда сәяси партияләр турында закон кабул ителде. Хәзер партия үз сафларында 50000 әгъзаны берләштерергә, төбәкләрнең яртысында бүлекчәләрен булдырырга (500 кеше) тиеш һ.б. Димәк, илнең сәяси тормышында иң күп санлылар һәм чын социаль базасы булганнар катнаша ала. Шулай итеп, гамәлдәге партияләр саны кыскара.

---

**Төшенчәләр:** *сайлау хокукы, референдум, сәяси партия, сәяси программа, коммунизм, либерализм, консерватизм, фашизм.*

---

**Сораулар һәм биремнәр**

**1.** Гражданнарның җәмгыятьнең сәяси тормышында катнашу механизмы буларак нәрсә ул тавыш бирү һәм сайлаулар?

***2.** Бүген безнең илдә массакүләм сорап белешү нигезендә гражданнарның сәяси симпатияләрен һәм кемгә өстенлек бирүләрен ачыклап торган сәяси рейтинглар

зур популярлык казана. Конкрет рейтинг яшәү урынына бәйле икән. Мәсәлән, 1999 елның 16 апрелендә үткәрелгән бөтенроссия җәмәгатьчелек фикерен сорап белешү күрсәткәнчә, Г. А. Зюгановны шәһәрләрдә 10%, кече шәһәрләрдә 20%, авылларда 30% респондент яклый икән, ә Ю. М. Лужковның киресенчә, 40% эре шәһәрләрдә, 20% кечеләрдә, 12% авылда. Үзегез өстенлек бирә торган һәр сәяси лидерның электоратын һәм рейтингын билгеләгез.

**3.** Сәяси партияне җәмгыять институты буларак характерлагыз, аның бүгенге дөньядагы ролен ачып бирегез. Нәрсә ул электорат һәм ул үзенең нәрсәгә сәяси өстенлек бирүе буенча ничек бүленә?

**4.** Нәрсә ул күп партиялелек һәм ул бүгенге Россиядә ничек чагыла?

***5.** Ни өчен яшь демократияле илләрдә сәяси партияләр саны нык үскән демократияле илләрдәгегә караганда күбрәк?

***6.** Уйлап карагыз, бүгенге Россиядә гражданнарның хөкүмәткә йогынты ясавының кайсы юлы нәтиҗәлерәк — сайлауларда тавыш бирүме, әллә оешкан иҗтимагый төркемнәр төзүме?

**7.** Сәяси программа һәм сәяси философия нәрсә белән аерылалар? Сәяси философиянең төп дүрт тибын тасвирлагыз.

**8.** Сәяси партиянең эчке структурасы нинди?

**? Проблема.** Илдә партияләрнең популярлыгы нигезендә нинди факторлар ята?

**Практикум.** А. И. Кравченконың «Җәмгыять белеме» дәреслегенең тиешле бүлекләре һәм параграфларыннан файдаланып, түбәндә китерелгән җөмләләрне тәмамларга тырышыгыз:

Сайлау хокукы дигәндә...

Тавыш бирү — ... формаларының берсе.

Коммунизм — төрле концепцияләрнең гомуми исеме, аларның нигезендә...

Капитализмны алыштыра торган иҗтимагый-икътисади формация үз үсешендә ике баскыч уза: ...

Утопик социализм — ... дигән тәгълимат.

Социал-демократик агымда ... юнәлеш расланды.

## § 21. Сәяси тормыш субъектлары

Гади граждкаinнардан тыш сәяси төркемнәр ил тормышының мөһим сәяси субъектлары булып торалар. Түбәндә дүрт төп төркем аерып күрсәтеләчәк: ***басым төркемнәре, мәнфәгатьләр төркемнәре, лобби һәм элита.***

Демократик дәүләттә гади гражданнар хөкүмәткә ике юл белән йогынты ясыйлар:

— сайлауларда тавыш биреп;

— оешкан иҗтимагый төркемнәр төзеп.

Андый төркемнәрдә катнашучы гражданнар үз эшләре өчен хезмәт хакы алмаганлыктан, иҗтимагый төркемнәр дип аталалар һәм гадәти оешма, әйтик, институт яки сәүдә фирмасы кебек теркәлмиләр. Ирекле ярдәмчеләр еш кына түләүсез эшли.

Оешкан иҗтимагый төркемнәрнең ике төре була:

— үз мәнфәгатьләрен яклый торган төркемнәр (профсоюзлар, эшмәкәр берлекләре);

— законнарны үзгәртү буенча яңа инициатива белән чыккан төркемнәр (феминистлык хәрәкәте).

Беренче төр — **басым ясау төркемнәре**, икенчесе **мәнфәгатьләр төркемнәре** дип атала.

Төркемнәрнең исеме шактый шартлы. Мәсәлән, мәдәният һәйкәлләрен саклау җәмгыятен яки мохитне саклау җәмгыятен кая кертергә? Формаль күзлектән чыгып карaганда, беренче төркемгә, чөнки аларның исемнәрендә «саклау» сүзе очрый. Ләкин чынлыкта исә алар үзләренең төркем мәнфәгатьләре сагында түгел, бөтен җәмгыять мәнфәгатьләре сагында тора. Шул ук вакытта профсоюзлар, үз мәнфәгатьләрен яклап, даими рәвештә законнар кабул итү инициативасы белән чыгалар һәм җәмгыятькә теге яки бу үзгәрешләр кертүне таләп итәләр. Дөресрәге, төркемнәрнең ике төрен дә аларның кем мәнфәгатьләрен — үзләренекенме, әллә башка кешеләрнекенме икәненә карап аерырга һәм шунлыктан берләрен басым төркемнәре, икенчеләрен мәнфәгатьләр төркемнәре дип атарга кирәк. Аңлашыла ки, ветераннар советы — беренче, ә Кызыл Хач һәм Коткару армиясе икенче төркемгә керә.

*Мәнфәгатьләр төркемнәрен сәяси партияләрдән аерырга кирәк.* Бу ике критерий буенча эшләнә. Беренчедән,

мәнфәгатьләр төркемнәре беркайчан да илдә сәяси хакимиятне алырга тырышмый, икенчедән, аларның игътибары партияләрнең программасын тәшкил итә торган декларатив раслаулар җыелмасына түгел, ә бер практик мәсьәләгә юнәлдерелгән, алар шуны хәл итү белән мәшгуль. Мәнфәгатьләр төркемнәре гражданнарның эмоцияләрен, өмет, идея, мәнфәгать, карашларын чагылдыра, аларга икеләтә көч бирәләр һәм кумәк эш итү нәтиҗәсендә, аларны җәмәгатьчелек казанышы итәләр. 70 елларда безнең илдә *экология хәрәкәтен* беркем дә белмәде диярлек. Аның турында 80 елларда да бик аз ишетелде. Ләкин эшкәртүдән соң чыккан газлар, терекөмеш парлары, радиоактив явымнар, сәнәгать калдыклары күбәйгәч һәм бу күп шәһәрләрдә яшәүчеләргә кагылгач, энтузиастлар төркеме барлыкка килде һәм ул бу проблемага планлы төстә, түземлелек белән һәм эзлекле төстә җәмәгатьчелек игътибарын җәлеп итте. Нәтиҗәдә, 90 елларда мохитне саклау проблемасы парламентның законнар чыгару эшчәнлегендә иң мөһимнәрнең берсенә әверелде, мәктәптә махсус укыту предметы кертелде.

Нинди дә булса проблема кискен яисә түзеп тора алмаслык була башладымы, ул шундук күпләгән кешеләрнең игътибарын җәлеп итә һәм алар арасыннан булачак хәрәкәтне оештыручы килеп чыга. Актив эшләүче мәнфәгатьләр төркемнәре хөкүмәт һәм парламент игътибарын үзләренә җәлеп иткәч, алар күпләгән проблемаларны яхшырак аңлый башлый һәм шундук иң әһәмиятлесен аерып ала.

Шулай итеп, мәнфәгатьләр төркемнәре лакмус кәгазе ролен үти: алар иң хәлиткеч проблемаларны аерып күрсәтәләр. Мәсәлән, озак вакыт армиядә «бабайлык» чәчәк атты һәм тыныч вакытта меңләгән яшь солдат һәлак булды. Бары тик 90 елларда гына илдә көчле *солдат аналары хәрәкәте* оешты һәм дөньяда иң консерватив хакимият органы — армия җитәкчелегенең игътибарын үзенә җәлеп итте.

Шундый хәрәкәтләр аша гади гражданнар актив сәясәткә җәлеп ителә һәм аңа эре түрәләрдән ким булмаган йогынты ясый.

Бер проблема белән озак шөгыльләнеп, мәнфәгатьләр төркемнәре квалификацияле кадрлар, әлеге проблеманың белгечләрен әзерли. Әгәр сезнең «бабайлык» һәм армиядәге

үлем турында беләсегез килсә, солдат аналары советына мөрәҗәгать итәргә кирәк. Әгәр мохит турында тулы мәгълүмат кирәк булса, әлеге җәмгыять белгечләреннән дә яхшыракны таба алмассыз һ.б. Министрлыклар һәм парламент комитетлары, конкрет карарлар әзерләп, еш кына шундый белгечләргә эксперт бәяләмәсе сорап мөрәҗәгать итәләр.

Мәнфәгатьләр төркемнәренең кайберләре иҗтимагый хәрәкәтләр булып үсә, ә иҗтимагый хәрәкәтләрдән сәяси партияләргә әверелә.

МӘНФӘГАТЬЛӘР ТӨРКЕМНӘРЕ ЭВОЛЮЦИЯСЕ

Мәнфәгатьләр төркеме

↓

Иҗтимагый хәрәкәт

↓

Сәяси партия

Басым төркемнәренең вазыйфаларын башкару характеры һәрвакыт аларның эшләү ысулы законлымы, түгелме икәнлеккә бәйле.

Мәнфәгатьләр һәм басым ясау төркемнәре, дәүләт белән халык арасында арадашчы буларак, үз вазыйфаларын түбәндәгечә башкара:

— депутатлыкка кандидатлар, башкарма һәм вәкаләтле органнар әгъзалары белән үзара эш итәләр (киңәшләр, тәкъдимнәр, ышандырулар рәвешендә);

— закон проектларын, экспертизаларны, хөкүмәт органнары бәяләмәләрен финанслауда катнашалар;

— кабул ителгән карарларның (законнарның) үтәлүен контроль итәләр;

— хөкүмәтнең идарә итүенең кайбер тармакларындагы эшчәнлеген, финанс средстволарын тотуны күзәтәләр һ.б.

Үзара эш итүнең законлы (яки легитим) формалары шундый. Алардан тыш, әлеге төркемнәр эшчәнлегенең законлы булмаган формалары да бар. Аларга, аерым алганда, ришвәтләр һәм түрәләрне сатып алу, легаль булмаган берләшмәләргә финанс белән ярдәм итү, компромат җыю



максатында сәясәтчеләрнең шәхси тормышын контрольдә тоту һ.б. кирә.

**Лобби.** Гади гражданнар оештырган мәнфәгатьләр төркемнәреннән ***бюрократик структуралар базасында формалашкан басым ясау төркемнәрен аерырга кирәк. Мәнфәгатьләр төркемнәреннән аермалы буларак, лобби хакимияткә басым ясауның турыдан-туры формаларын үстерә.*** Лоббиларга якын даирәдә булган һәм кирәкле карарны тыныч юл белән, мәсәлән, парламентта күпчелекне тәшкил итеп, депутатларны сатып алып, югары дәрәҗәдәге кешенең туганнары һәм якыннары ышанычына кереп, хөкүмәткә яки парламентка ялган куркыту белән янап кабул иттерергә сәләтле кешеләрне кертәләр.

Соңгы вариант 90 елларда хакимият коридорларында еш уйналды. Аграрийлар төркеме парламентны — авыл хуҗалыгының бөлгенлеккә төшүе, хәрбиләр — армиянең ризасызлыгы һәм дәүләт банкыннан тиешле сумма бирелмәгән очракта аның хөкүмәтне бәреп төшерергә әзер торуы белән куркыталар. Акча бирелгәч, ул еш кына гади аграрийларга яки хәрбиләргә барып җитми, казна караклары кесәсендә кала. Аграрийлар һәм хәрбиләр, вәгъдә ителгән средстволарны ала алмагач, ризасызлык белдерәләр. Аларның парламенттагы һәм хөкүмәттәге лоббилары яңадан атмосфераны кыздыралар һәм тагын акча таләп итәләр.

Әле аталган типтагы куәтле лобби төркемнәре хакимият тирәсендә була. Мәнфәгатьләр төркемнәре, солдат аналары яисә экология тибындагы хәрәкәтләр, киресенчә, аннан

ераклаштырылганнар. Аларга үзләренә игътибарны җәлеп иттерү шактый читен. Аларның рупоры — массалар өчен демократик трибуна дип саналырлык газеталар, радио, телевидение.

Лобби әле шуның өчен дә көчле, чөнки ул ниндидер стратегик ресурсларны контрольдә тота. Хәрбиләр — оборонаны, аграрийлар — ашамлыкларны, банклар акчаны контрольдә тота. Элек куәтле лоббистлар фракциясен рус дворяннары тәшкил иткән. Алар төп ресурсны — җиргә милекне контрольдә тоткан. Алар белән шулай ук яшәү өчен мөһим ресурсларны контрольдә тоткан сәнәгать лоббие ярышкан. Ул бүген дә саклана. Мәнфәгатьләр төркемнәре бер нәрсәне дә контрольдә тотмый, шунлыктан аларның сүзенә иң ахырдан колак салалар.

Әгәр лоббига һәрвакыт юл куйсаң, алар дәүләттәге барлык хакимиятне басып алачак һәм аны үз проблемаларын гына хәл итәргә мәҗбүр итәчәкләр. Моны АКШта XX гасыр уртасында ук аңлап алалар, шунлыктан 1946 елда лобби эшчәнлеге турында федераль закон кабул ителә. Закон лобби әгъзаларының теркәлүен, акча ресурсларын һәм аларны сәяси көрәштә тоту турында хәбәр итүләрен таләп итә. Шуннан соң, лоббиның эшчәнлеге киң даирәгә ишеттерелә башлаган саен, законны урап үтү теләге сүнә башлаган.

*Лоббичылык тактикасы* — хакимият структуралары аша кирәкле карарларны көч белән үткәрү тактикасы элементларыннан лоббистлар үзләре генә түгел, башка төркемнәр һәм иҗтимагый оешмалар да файдалана. 1998 елда Россия нефть компанияләре, үзләре белдергәнчә, лобби түгел иделәр. Алар үзләрен нефтьне читкә сатудан дәүләткә ныклы керем бирүче (ә аны барлык башка институтлар һәм структуралар әрәм-шәрәм итте) савым сыеры итеп күрсәтте. Авыр кризиска элэгеп, хөкүмәт нефть корольләренә салымны күтәрергә карар кылды. Шунда ук массакүләм мәгълүмат чаралары эшкә җигелде, алар нефть компанияләренә ил өчен үз эшчәнлекләренең мөһимлеге һәм алар очраша торган искитмәле кыенлыклар турында сөйләү мөмкинлеге бирделәр. Җәмәгатьчелек фикере бик оста һәм сизелмәслек диярлек эшкәртелде. Дәүләт Думасында нефть компанияләре отчетын тыңлау әзерләнгән фонда үтте һәм

котелгән нәтиҗә бирде. Нефтьчеләрнең парламентта лоббилары булгандырмы, әллә юкмы, анысы билгесез булып кала, әмма матбугат аша депутатларга, президентка, хөкүмәткә һәм гади гражданнарга басым бик каты ясалды.

Илнең сәяси тормышына йогынты ясый торган иң көчле төркем — җәмгыятьнең элитасы. «Элита» атамасын XIX гасыр ахырында итальян социологлары Г. Моска белән В. Парето кертә. Безнең илдә һәм Европада җәмгыятьнең югары өстен хокуклы катлауларын билгеләү өчен «элита» сүзе, ә АКШта тагын «истеблишмент» (өстенлек итүче югары катлау, хакимлек итүче даирәләр) сүзе дә кулланыла. Американың «истеблишмент» дигәндә АКШта җәмгыять тормышының төп өлкәләренең — бизнес, сәясәт, фән һәм техника, реклама һәм мәгълүмат, мәдәният һәм «массакүләм мәдәният»нең иерархия пирамидалары түбәсендә торучы кешеләрне күздә тоталар. «Истеблишмент»ны әлеге кешеләр арасындагы формаль булмаган элемтәләр яшәтә. Алар зәвыкта һәм үзеңне тотуда «тон бирәләр», алардан юнәлеш, үрнәк алалар.

***Элита — яхшы әхлакый, профессиональ һәм иҗади сыйфатларга гына түгел, ә җәмгыятьтә иң зур хакимияткә ия булган кешеләрнең зур булмаган төркеме ул.*** Җәмгыять элитасы — зур хакимияткә һәм күп акчага ия булган, социаль пирамиданың түбәсендә торган сайланган кешеләрнең тар даирәсе. Элитага, гадәттә, эшлекле һәм финанс даирәсе вәкилләрен, тышкы сәясәт һәм оборона өлкәсендәге белгечләрне, хөкүмәт башында торучыларны һәм сәяси лидерларны, зур галимнәрне, телевидение челтәре һәм танылган басмалар хуҗаларын, шулай ук популяр мәдәният эшлеклеләрен кертәләр. АКШта халыкның 0,5% тәшкил иткән элита милли байлыкның 35%ына хуҗа. Россия турында да шуны ук әйтергә була.

*Җәмгыятьтә хакимиятнең ничә төре бар, элита төрләре дә шул кадәрле дип санала.* Бу аңлашыла да, зур хакимият — элитага керүнең билгесе. Икътисади элита, сәяси элита һәм бюрократ-түрәләр элитасы бар. Башкача әйткәндә, элитага төп сәясәтчеләр, эре бизнесменнар һәм югары дәрәҗәдәге дәүләт хезмәткәрләре керә. Алардан тыш элитага армия җитәкчелеген, махсус хезмәтләр җитәкчеләрен кертергә була.

«Дүртенче хакимият» дигән төшенчә — ММЧ та бар, шунлыктан элитага газеталарда эшләүче күренекле журналистлар һәм журналист-телекомментаторлар керә. Мода һәм зәвык хуҗалары, популяр җырчылар һәм музыкантлар да киң публика өстеннән билгеле бер хакимияткә ия. Шул ук вакытта, хакимиятне формаль һәм формаль булмаганга бүлү белән бергә, галимнәр сәяси башлыклардан торган рәсми элитаны һәм «данлыклылар хакимияте» — рәсми булмаган элитаны аерып күрсәтәләр.

Кагыйдә буларак, *элита хакимияттәге партиянең төшен тәшкил итә.* Күләме белән зур булмаса да, ул бик тә зур нәтиҗәгә ирешә. Куәтле капитал аркасында алар сайлаучылар тавышын сатып алырга, сәяси реклама мәкаләләре язучы журналистларны ялларга яисә нинди дә булса газетаны сатып алырга ярдәм итәләр. Россия социализмнан базар мөнәсәбәтләренә күчкәч, илнең ММЧ дәүләт дотациясеннән мәхрүм калды. Шәхси капитал зарурлыгы туды. Аны илнең бай кешеләре — олигархлар бирде дә. Матбугатка финанс ярдәмен алар юкка гына күрсәтмәде, кайбер газета, журнал һәм телевидение каналлары аларның рупорына әверелде. Олигархлар хакимият структураларына бик зур йогынты ясады, шуның нәтиҗәсендә үзләренә кирәкле кешеләрне югары дәүләт постларына билгеләтүгә ирештеләр. 2000 елда эре бизнес вәкилләре белән киңәшмә вакытында президент В. В. Путин, моннан соң барлык олигархлар хакимияттән «тигез дәрәҗәдә читләштереләчәкләр», диде.

---

**Төшенчәләр:** *басым ясау төркеме, мәнфәгатьләр төркеме, лобби, элита.*

---

**Сораулар һәм биремнәр**

1. Басым ясау төркемнәре, мәнфәгатьләр төркемнәре, лобби һәм элитаның үзенчәлекләрен һәм аерымлыкларын чагыштыру өчен таблица төзегез.

*2. Сәяси көрәштә ММЧ ничек файдаланыла? Үз җавабыгызны хәзерге Россия тормышыннан мисаллар белән күрсәтегез.

*3. Дәүләт Думасы депутатларын һәм Федераль Җыен сенаторларын Россия элитасына кертеп буламы? Бәлки,

аларны лобби дип атау дөресрәктер? Җавабыгызны дәлилләгез.

***4.** Уйлагыз, түбәндәге төшенчәләр үзара ничек бәйләнгән: *бюрократия, басым ясау төркеме, лобби, номенклатура, криминалитет, парламент, элита, аристократия, олигархия.*

**5.** Солдат аналары хәрәкәте нинди төркемгә керә?

**6.** Үз максатларына ирешү өчен лобби нинди тактика куллана? Тарихтан мисаллар китерегез.

**? Проблема.** Совет элитасы белән бүгенге Россия җәмгыяте элитасы арасында дәвамчанлык бармы? Ни өчен шулай уйлыйсыз?

**Практикум.** Уйлагыз һәм җавап бирегез: түбәндәге оешмалар һәм хәрәкәтләр сәяси төркемнәрнең кайсы типларына керә?

1. Басым ясау төркемнәре.
2. Мәнфәгатьләр төркемнәре:

а) профсоюзлар,
б) Эшмәкәрләр берлеге,
в) феминистлык хәрәкәте,
г) экология хәрәкәте,
д) Кызыл Хач,
е) ветераннар советы,
ж) Офицерлар берлеге,
з) казаклар берләшмәләре,
и) солдат аналары хәрәкәте.

## Сүзлек

**Абруй** — авторитет, йогынты; җәмәгатьчелек фикерендә урнашкан статусны хөрмәт итү.

**Абсолют ярлылык** — индивид үз кеременә хәтта азыкка, торак, кием-салым, җылылыкка булган иң кирәкле ихтыяҗларны да канәгатьләндерә алмый, яисә биологик тереклекне тәэмин итүче иң кечкенә ихтыяҗларны гына канәгатьләндерүгә сәләтле.

**Абстракт** (лат. abstractio — читкә юнәлдерү) — читкә юнәлдерелгән, тормыштан аерылган, теоретик.

**Автономия** — тышкы шартлардан бәйсезлек.

**Авторитар** (лат. auctoritas — хакимият) — шәхси хакимияткә, шәхси диктатурага нигезләнгән.

**Авторитет** (абруй) (лат. auctoritas — хакимият, йогынты) — белемнәргә, әхлакый өстенлекләргә, тәҗрибәгә нигезләнгән йогынты.

**Аграр** (лат. agrarius) — җиргә, җир биләүгә, җирдән файдалануга кагылышлы.

**«Ак якалар»** — автоматлаштырылган производствода, фәнни һәм гамәли эшләрдә, шулай ук мәгълүмат өлкәсендә мәшгуль хезмәткәрләр.

**Акциз** (фр. accise) — читләтелгән салым төре, сатучыдан ул товарларның кайбер төрләрен сатып алганда алына һәм гадәттә әлеге товар бәясенә карата процентларда билгеләнә.

**Акча** — алмашу мөнәсәбәтләрен гамәлгә ашыру средствосы, гомуми эквивалент.

**Альтернатива** (лат. alter — икенең берсе) — мөмкин булган ике чишелешнең яки кирәкле вариантның (яки берничәсенең) берсен сайлау зарурлыгы.

**Альтруизм** (франц. altruisme, лат. alter — башка) — башка кешеләрнең әйбәт яшәве турында эчкерсез кайгырту, эгоистлыкның капма-каршысы.

**Андерсыйныф** — җәмгыятьнең сыйныфтан мәхрүм ителгән элементлары (эчкечеләр, наркоманнар һ.б.) тәшкил иткән катлавы, җәмгыятьнең «социаль төбе».

**Антропоген йогынты** (гр. anthropos —кеше, genes — туучы) — кеше эшчәнлегенең табигатькә йогынтысының төрле формалары, мәсәлән, аны пычратуы.

**Артефакт** (лат. artefactum — ясалма эшләнгән) — кеше ясаган, эшләгән әйбер.

**Аскетлык** (грек. asketes — нәрсәгә булса да күнегүче) — хисси теләкләрне чикләү яки басу, физик авыртуны, ялгызлыкны һ.б. үз теләгең белән кичерү; ул фәлсәфи мәктәпләр (мәсәлән, кинիկларга) һәм аеруча төрле диннәр (монахлык һ.б.) практикасына хас.

**Ассимиляция** — этник йотылу, бер халыкның (кайчак берничә халыкның) икенчесе тарафыннан тулысынча йотылып юкка чыгуы.

**Атеистлык** (фр. athéisme, грек. átheos — алласыз) — Алланы, шуның белән бәйле рәвештә динне инкарь итү.

**Атрибутлар** (лат. attribuo — бирәм, бүләм) — кирәкле, әһәмиятле үзенчәлек.

**Ачык җәмгыять** — бер дәрәҗәдән икенчесенә күчү рәсми чикләнмәгән җәмгыять.

**Әхлаксызлык** — әдәпсезлек, тәрбиясезлек.

**Базар** (market) — сатып алучыларны һәм сатучыларны (товар тәкъдим итүчеләрне) бергә җыя торган теләсә нинди институт яки механизм.

**Бакчачылык** — әзер ашамлыклар (кыргый үләннәр) җыюдан бөртекле культуралар үстерүгә системалы күчү формасы.

**Башкаручы** (җитештерүче яки әзерләүче) — эшмәкәр статусы булган оешма яки гражданин.

**Бәя** — товар яки хезмәт күрсәтү берәмлеге өчен түләнә һәм алына торган акча (яки башка төр товар яки хезмәт) күләме.

**Без-төркем** — әгъзалары теләктәш булган кече төркем.

**Бүләкләү** — хезмәт өчен әхлакый яки матди бүләкләү, түләү.

**Бизнес** (ингл. business) — эшмәкәрлек эшчәнлегенең табыш алуга юнәлдерелгән төре.

**Бурыч** — башка затлар, оешма һәм учреждениеләр белән билгеле бер мөнәсәбәтләргә керүче зат кабул итә торган тиешле булу формасы.

**Бурычлы булу** — кемгәдер йөкләнгән һәм мәҗбүри үтәлергә тиешле эшләр яки йөкләмәләр даирәсе.

**Бюрократия** — оештыру структурасына кертелгән, төгәл иерархия, «вертикаль» мәгълүмат агымнары, карарлар кабул итүнең формаль ысуллары һәм җәмгыятьтә аерым статус тенденциясе белән характерланучы профессиональ идарәчеләрнең социаль катлавы.

**Вакыт буенча түләү** — җитештерелгән продукциягә түгел, ә эшләгән сәгатьләр санына карап түләү.

**Вестернизация** (ингл. western — көнбатыш) — Көнбатыш мәдәнияте кыйммәтләрен Көнбатыш булмаган җәмгыятьләргә тарату.

**Виза** (лат. visus — күрелгән, каралган) — башка илгә керергә, анда йөрергә яки аннан чыгарга рөхсәт бирү турындагы документ.

**Вөҗдан** — кешенең үз гамәлләренә тәнкыйть белән карый алу, үз кимчелекләрен тану һәм үкенә белү сәләте.

**Гадәт** — үзеңне тотуның традицион урнашкан тәртибе.

**Гадәти хокук** — үзеңне тотуның дәүләт рөхсәт иткән, әмма язылмаган кагыйдәләре җыелмасы.

**Гадәтләр** — билгеле бер хәлләрдә үзеңне тотуның урнашкан схемасы (стереотибы).

**Гаилә** — көнкүреш бергәлеге, үзара ярдәм, әхлакый һәм хокукый җаваплылык белән бәйле никах яки кан кардәшлегенә нигезләнгән кече төркем.

**Гаилә бюджеты** — аерым гаиләнең вакыт берәмлегенә карата (ай, ел) керемнәре һәм чыгымнарының тулаем суммасы.

**Гаиләнең тормыш циклы** — гаиләнең яшәвендә әһәмиятле, этаплы вакыйгаларның эзлеклелеге — никахлашудан башлана һәм ул өзелгәч, ягъни аерылышкач тәмамлана.

**Генотип** (гр. genos — ыруг, килеп чыгу, tyros — эз, форма, үрнәк) — организмның генетик (нәселдән килгән) конституциясе, барлык геннары, тотрыклы сыйфатлары җыелмасы; аларны буыннан-буынга тапшыру нәтиҗәсендә халык яки этнос үзенең биологик асылын саклый.

**Глобальләштерү** (фр. global — гомуми, лат. globus — шар) — милләтләрне һәм халыкларны якынайта, акрынлап традицион чикләрне бетерә һәм кешелек дөньясын бердәм системага әверелдерә торган тарихи процесс.

**Гражданлык** — кешенең һәм дәүләтнең хокук һәм бурычларында чагыла торган даими сәяси-хокукый бәйләнеш.

**Гражданлык буйсынмавы** — хакимияткә буйсынмауның күмәк протесты формасы.

**Гражданлык никахы** — закон белән теркәлмәгән, ирекле килешүгә нигезләнгән никах.

**Гражданлык җәмгыяте** — сәяси булмаган мөнәсәбәтләр җыелмасы; киң гражданлык һәм сәяси хокуклар бирелгән, дәүләт белән идарә итүдә актив катнашучы ирекле, суверен шәхесләр берлеген гәүдәләндерүче идеал.

**Дәүләт** — әлеге илнең хакимият режимының билгеле бер тибын (монархия, республика), идарә итү органнарын һәм структурасын (хөкүмәт, парламент) үз эченә алган сәяси оешма.

**Дәүләт бурычы** — дәүләтнең кайтарылмаган займнар һәм аларның түләнмәгән процентлары буенча бурычларының гомуми суммасы.

**Дәүләт бюджеты** — дәүләтнең керемнәрен һәм чыгымнарын бер елга билгеләп кую.

**Девиация** (соң лат. deviatio — тайпылу) — кешенең үзен тотышында кабул ителгән нормалардан тайпылуы.

**Деесәләтлелек** — мөстәкыйль рәвештә бернинди чикләүләрсез хокукларны тормышка ашыру һәм бурычларны үтәү сәләте.

**Делинквентность** (лат. delinquens — гаеп эш эшләүче) — социологиядә һәм юриспруденциядә җәза бирелергә тиешле җинаять эшләр аталышы.

**Дефицит** (лат. deficit —җитмәү) — средстволар яки ресурсларның элек билгеләнгән, планлаштырылган яки кирәкле дәрәҗә белән чагыштырганда, җитмәве; чыгымнарның керемнәрдән артып китүе.

**Диаспора** (гр. diaspora — сибелү) — халыкның шактый өлешенең үзе килеп чыккан илдән читтә яшәве.

**Дөньякүләм икътисади система** — икътисади элемтәләр белән берләшкән территорияләр яки илләр күплеге.

**Дотация** (урта гасырлар лат. dotatio — бүләк) — предприятиеләрнең, фирмаларның зыянын каплау өчен дәүләт бюджетыннан бирелә торган акча, хәрби сәнәгатьне, инфраструктура тармакларын һ.б. финанс белән яклау.

**Җаваплылык** — гаепленең үзе кылган гамәлләренең күңелсез нәтиҗәләре өчен газаплануы.

**Җәмгыять** — нинди дә булса илнең нигезендә социаль структура яткан социаль оешма.

**Җәмгыятьне полярлаштыру** — ала торган керемнәре күзлегеннән караганда, ике социаль полюсны тәшкил итүче, ярлылар һәм байлар арасындагы араның кинәт, шактый ерагаюы.

**Җитештерү** — икътисади продуктларның барлык төрләрен булдыру процессы.

**Җитештерү хезмәте** — продуктлар яки әйберләр (товар) булдыра торган хезмәт.

**Җитештерми торган хезмәт** — хезмәт күрсәтүләр.

**Законлылык** — законнарда ныгытылган хокук.

**Идарә итү** — карарлар кабул итү, производствоны оештыру, кешеләрнең эшчәнлегенә контрольлек итү процессы.

**Идарә итү формалары** — хакимиятне оештыру, үзенең формаль чыганагы белән характерлана. Монархиядә ул — король, патша, фиргавен һ.б. Республикада закон буенча хакимият чыганагы — күпчелек.

**Идентификация** (соңгы лат. identifico — тәңгәлләштерү) — тәңгәллекне тану.

**Идол** (гр. eidolon — образ) — а) кеше яки хайван формасы бирелгән матди әйбер, б) дини табыну булып хезмәт итүче алла яки рух сурәте.

**Иерархия** (гр. hieros — изге һәм arche —хакимият) — бөтен өлешләренең яки элементларының югарыдан түбәнгә таба урнашуы.

**Иерархия принцибы** — А. Маслоу теориясе буенча һәр яңа баскычның ихтыяҗлары аннан алдагысының таләпләре канәгатьләндерелгәннән соң гына актуаль (кирәкле) була, үзләре турында белдерә.

**Ике карьералы гаилә** — ир белән хатын икесе дә эшләүче гаилә.

**Икътисад** — үзара җитештерү, куллану, бүлү, товар һәм хезмәтләр алмашу мөнәсәбәтләренә кергән зур төркем кешеләрнең нәтиҗәле оештырылган эшчәнлеге.

**Ил** — билгеле бер чикләре булган һәм дәүләт суверенлыгы белән файдалана торган дөнья кисәге яки территория.

**Имидж** — кеше үзенең статусы нигезендә үзен ничек тотарга тиешлеге, әлеге статуста хокуклар һәм бурычлар нинди нисбәттә булырга тиешлеге турында иҗтимагый фикердә урнашкан күзаллаулар җыелмасы.

**Импичмент** (ингл. impeachment) — югары вазыйфаи затларның җинаятьләре турындагы эшләрне судта карауның һәм җаваплылыкка тартуның аерым тәртибе.

**Инвестицияләр** (нем. investition, лат. investio — киендерәм) — ил эчендә һәм чит илдә икътисад тармакларына озак срокка капитал салулар.

**Индивидуализм** (лат. individuum — индивидуум, зат) — индивид мәнфәгатенең төркем яки иҗтимагый мәнфәгатьләрдән өстенлеген тануны аңлата торган төшенчә; шулай ук алар аркасында кешенең әйбәт яшәве, иреге һәм шәхес буларак үсеше — югары максат, ә социаль институтларның һәм төркемнәрнең эшләве әлеге максатка ирешү өчен нигез һәм чара булып торган идеяләр һәм практик принциплар җыелмасы. Гадәти сөйләмдә индивидуализм дигәндә еш кына эгоизмны аңлыйлар.

**Индивидуальлек** — кешенең үз асылын, башка кешеләрдән аерымлыгын тәшкил итә торган психологик үзенчәлекләре кушылмасы.

**Индивидуум** — (индивид) (лат. individuum — бүленмәс; зат) — аерым кеше.

**Индустриальләштерү** — сәнәгать технологиясендә фәнни белемнәр куллану, энергиянең элек кешеләр яки йөк хайваннары башкарган эшне машиналар башкару мөмкинлеге тудырган яңа чыганакларын ачу.

**Индустрия** (лат. industria — тырышлык) — сәнәгать кебек үк.

**Инноватика, инновация** — яңалык, ачыш; яңа технологияләр, теорияләр, идеяләр булдыру һәм гамәлгә кертү.

**Инноватор** — нинди дә булса ихтыяҗны канәгатьләндерүче һәм табыш китерүче яңа эш уйлап тапкан кеше.

**Интернет** — Җирнең төрле өлешендә яшәүче кешеләргә аралашу мөмкинлеге бирә торган глобаль компьютер челтәре.

**Интерпол** — җинаятьчеләрне эзләү буенча халыкара оешма. Мәскәүдә бүлекчәсе бар.

**Ирекле эшсезлек** — тәкъдим ителгән хезмәт хакына эшләргә теләмәү белән бәйле рәвештә вакытлыча эшләмәү.

**Ирексездән эшсезлек** — хезмәткәргә бәйләнмәгән сәбәпләр аркасында килеп чыккан вакытлыча эшсез булу.

**Ихтыяҗ** — кешенең яшәү шартларын тәшкил итүче факторларга бәйлелеген чагылдыручы халәте.

**Казна караклыгы** — дәүләт милкен талау.

**Капитал** (лат. capitalis — төп, баш) — кеше тарафыннан булдырылып, товарлар җитештерү һәм хезмәт күрсәтү өчен файдаланыла, табыш китерә торган ресурслар.

**Капитализм** — хокукый милеккә һәм ирекле (дәүләтнең катнашуыннан башка) базар мөнәсәбәтләренә корылган җәмгыять.

**Каста** — кешенең анда әгъза булуы фәкать тумышы белән генә билгеләнә торган социаль төркем (страта).

**Катлау** — үзенә беркетелгән гореф-гадәтләргә һәм юридик законга, нәсел буенча тапшырыла торган хокукларга һәм бурычларга ия булган социаль төркем.

**Керем** — хезмәт хакы, пенсия, рента, пособие, алимент, гонорар һ.б. рәвешендә алынган акчаның теләсә нинди суммасы.

**Керем салымы** — физик затлар кеременнән (хезмәт хакы, өстәп түләүләр, премияләр, дивидентлар, процентлар, күчемсез милектән керемнәр һ.б.) һәм юридик затлар кеременнән (табышка салым) алына торган турыдан-туры салымнарның төп төре.

**Кешесез производство** — барлык эшне машиналар башкара торган, роботлаштырылган цехлар һәм предприятиеләр.

**Килешү** — кешеләрнең гражданлык хокукларын һәм бурычларын урнаштыруга, үзгәртүгә яки туктатуга юнәлдерелгән гамәлләр.

**Клан** (галл. clann — нәсел, токым) — фараздагы борынгы баба исемен йөртүче кан кардәшләр төркеме (клан җиргә уртак милекне, кан үчен, яклауга алуны һ.б. саклаган); бүгенге, нигездә чит ил әдәбиятында клан «ыруг» атамасына тиң атала.

**Коллык** — кешеләрне тулы хокуксызлык һәм иң нык дәрәҗәдәге тигезсезлек белән чикләнә торган кабалага төшерүнең икътисади, социаль һәм юридик формасы.

**Конституция** (лат. constitutio — корылыш, төзелеш) — дәүләтнең иҗтимагый һәм дәүләт төзелешен, хаки-

миятнең вәкаләтле органнарын булдыру тәртибе һәм принципларын, сайлау системасын, гражданнарның төп хокукларын һәм бурычларын билгели торган төп законы.

**Конфликт** (лат. conflictus — бәрелеш) — һәр як тарафыннан югары бәяләнә торган нәрсәне үзенеке итү өчен ике кеше, социаль төркемнәр, дәүләтләр бәхәсе, бәрелеше.

**Конфронтация** (фр. confrontation) — төркемнәр, сыйныфларның, шулай ук аларның мәнфәгатьләре һәм инануларының каршы торуы, бәрелеше.

**Коррупция** (лат. corruptio — сатып алу) — вазыйфаи затның хезмәт урынын шәхси баю өчен турыдан-туры файдалануы.

**Көндәшлек** — билгеле бер иҗтимагый өлкәдә охшаш максатларга, яхшы нәтиҗәләргә ирешүдә кешеләр, төркемнәр яки оешмаларның ачыктан-ачык ярышуы.

**Көч** — башка кешеләргә аларның теләкләреннән тыш, үз ихтыярыңны тагу максатында физик йогынты — көч куллану.

**Кулланучы** — товарлар, хезмәт күрсәтүләр алучы һәм аларны шәхси көнкүреш ихтыяҗларында файдаланучы кеше.

**Күп буынлы гаилә** — балалар, ата-аналар һәм әби-бабайлар булган гаилә.

**Күп партиялелек** — илдә ачыктан-ачык яши торган икедән артык сәяси партия булган партия системасы.

**Кыска вакытлы казна векселе** — дәүләтнең 1 елга кадәр срок белән чыгарыла торган кыйммәтле кәгазе, гадәттә дәүләт соңыннан аны кире сатып алгандагы номиналь бәя белән чагыштырганда ташлама белән сатыла.

**Легаль** (лат. legalis — законлы) — законлы, танылган, закон рөхсәт иткән.

**Легитим** — законлы.

**Лидер** (ингл. leader — алып баручы, җитәкче) — 1) сәяси партия яки иҗтимагый оешма башлыгы; 2) кече төркемнең иң абруйлы әгъзасы; 3) спорт ярышларында катнашып, алда баручы.

**Мавыгу** — кыска вакытлы тәэсирле омтылыш.

**Манералар** — кешенең үзен тотышының тирә-юньдәгеләрнең уңай яки тискәре бәясен алган тышкы формалары; аерымлык сыйфатлары.

**Маргинал** (фр. marginal — кырәксез, кырыйлардагы) — бер мәдәниятне, ил, катлау, сыйныф, төркемне ташлап киткән һәм башкаларның кыйммәтләренә, яшәү рәвешенә ярашмаган кеше.

**Маркетинг** (ингл. marketing, market — базар) — предприятиеләрнең җитештерү-сату эшчәнлеге белән идарә итүнең базарны комплекслы өйрәнүгә нигезләнгән бүгенге системасы.

**Мәгълүмати җәмгыять** — җитештерү көчләренең нигезе белемнәр һәм мәгълүмат булган постиндустриаль җәмгыять.

**Мәдәният (культура)** (лат. cultura — эшкәртү, тәрбияләү, белем, үсү, хөрмәтләү) — хәзер яшәүчеләрнең тәртипләрен җайга сала һәм иртәгә яшәүчеләргә тапшырыла торган традицияләр, гореф-гадәт, социаль нормалар, кагыйдәләр җыелмасы.

**Менеджер** (инг. берлек сан. manager — идарә итүче) — предприятие, бүлек, фирма, оешмада идарә итү буенча белгеч.

**Миграция** (лат. migratio, migro — күчәм, күченәм) — кешеләрнең бер урыннан икенчесенә күчүе. Тышкыга — илдән илгә (эмиграция, иммиграция), эчкегә — авылдан шәһәргә, бер районнан икенче районга, вакытлы, сезонлы һ.б. күчүгә аерыла.

**Милек** — мөлкәткә хокукый ия булу.

**Милек мөнәсәбәтләре** — нинди дә булса милек яки әйберләр мәсьәләсендә хокукый мөнәсәбәтләр.

**Милләт** — әгъзалары уртак кыйммәтләр һәм институтлар буенча яшәгән, территориаль кысалар белән чикләнмәгән автоном сәяси төркем.

**Милли азчылык** — халыкның төп өлеше яшәгән урыннан яки шул исемдәге дәүләттән читтә яшәүче аерым өлеше.

**Мин-концепция** — үзең, тулаем дөнья һәм мохиттә үз ролең турында күзаллаулар системасы.

**Монополия** (гр. monos — бер, берданбер һәм poleo — сатам, сату итәм) — эшчәнлекнең нинди дә булса өлкәсендә дәүләтнең (мәсәлән, тышкы сәүдә монополиясе) оешма, фирма h.б. ның кагылгысыз хокукы; тар мәгънәдә — базардагы тәкъдимнәрнең гомуми күләменә һәм товар яки хезмәт күрсәтүләрнең бәясенә йогынты ясарга сәләтле аз санлы (сирәк кенә — берданбер) сатучыларның булуын характерлый торган хәл.

**Мотив** (фр. motif, лат. moveo — хәрәкәтләндерәм) үзеңне тотуның акыллы аңлатыла торган сәбәбе.

**Натуральләштерү** — кешенең үтенече нигезендә нинди дә булса дәүләтнең гражданлыгына яки подданлыгына кабул итү (мәсәлән, озак яшәгән очракта).

**Нәсел** — күп сандагы ыругларны һәм кланнарны колачлаучы этник бергәлек һәм социаль оешма тибы.

**Неолит революциясе** (неолит — яңа таш гасыр) — аучылыктан һәм әзерне җыюдан игенчелеккә күчү.

**Норма** (лат. norma — җитәкче башлангыч, кагыйдә, үрнәк) — социологиядә төркемдә яки җәмгыятьтә формаль яки формаль булмаган кагыйдәләр җыелмасы.

**Нуклеар гаилә** (лат. nucieus — төш) — ата-анадан һәм балалардан, ягъни социаль һәм биологик төштән (нәсел үрчетү һәм иҗтимагый элемтәләр өчен җитәрлек) торган гаилә.

**Община** — берничә йөз кешенең үзара кан кардәшлеге, никахлар, хезмәт кооперациясе, үзара ярдәмләшү, территорияне бергәләп саклау белән берләшкән берлеге.

**Олигополия** (гр. oligos — аз санлы һәм poleo — сатам, сату итәм) — базарда ярыша торган берничә эре фирманың тармак продукциясенең төп массасын җитештерүгә һәм сатуга монополия урнаштыруы.

**Оферта** (лат. offero — тәкъдим итәм) — гражданлык-хокукый килешү төзергә тәкъдим итү.

**Оят** — а) эчке контроль механизмы; б) кешенең кабул ителгән нормаларга яки әйләнә-тирәдәгеләрнең өметләренә туры килмәвен, димәк, хатасын (гаебен) тануы.

**Өстенлек** (льгота) — нинди дә булса өстенлекле шартлар бирү, билгеләнгән кагыйдәләрне, бурычларны үтәүдән өлешчә азат итү яки аларны үтәүне җиңеләйтү, мәсәлән, салым ташламалары.

**Өстенлекле мәдәният** — җәмгыятьнең күпчелек әгъзасы кабул итеп алган кыйммәтләр, дини ышанулар, традицияләр һәм гореф-гадәтләр җыелмасы.

**Парламент** (ингл. parlament, фр. parler — сөйләү) — тулаем яки өлешчә сайлау башлангычларында төзелгән, законнар чыгара торган югары вәкаләтле хакимият органы.

**Патриархаль гаилә** — башында ир кеше торган, берничә буынны берләштергән зур гаилә.

**Постиндустриаль җәмгыять** — төп җитештерүче көче фән һәм яңа интеллектуаль технологияләр булган җәмгыять. Күпчелек хезмәткәрләре хезмәт күрсәтүдә: сәүдә, финанс, транспорт, сәламәтлек саклау, ял, фән, мәгариф, хөкүмәттә мәшгуль.

**Предприятие** — закон билгеләгән тәртиптә төзелгән мөстәкыйль хуҗалык субъекты.

**Прогресс** — җәмгыятьнең уңай үзгәрешләре (алга барулар) тискәреләреннән өстен булган үсеше.

**Прогрессив салым** — салым салына торган керемнең артуына бәйле рәвештә салым ставкаларын арттыру принцибына корылган салым.

**Процент** — чит кешеләрнең акчасын яки капиталын файдаланган өчен түләү.

**Раса изүе** — гражданнарның, этник төркемнең хокукларын милләтенә яки расасына карап системалы төстә кысу.

**Рациональ** (лат. rationalis — акыллы, ratio — акыл) — акылга, логик исбатлауларга, максатка ярашлылыкка корылган.

**Регресс** (лат. regressus — кире кайту, начарлану, түбәнрәк дәрәҗәгә төшү, үсешнең югарырак формадан аска тө-

шүе, артка чигенү; җәмгыятьнең тискәре үзгәрешләре уңай үзгәрешләрдән өстен булган үсеше; прогрессның киресе.

**Республика** (лат. respublica, сүзгә-сүз — җәмәгать эше) — дәүләт башлыгы (мәсәлән, президент) халык яки махсус сайлау коллегиясе тарафыннан сайланып идарә итү формасы; законнар чыгару хакимияте сайлана торган вәкаләтле органда (парламентта) була.

**Ресурслар** (фр. ressource — ярдәмче средство) — акча средстволары, кыйммәтләр, запаслар, мөмкинлекләр, средство, керем чыганаклары (мәсәлән, табигый ресурслар, икътисади ресурслар).

**Ресурсларның сирәклеге** — аерым төр ресурсларның чикләнгәнлеге, алар күләменең производство таләпләрен канәгатьләндерү өчен җитмәве.

**Референдум** (лат. referendum —хәбәр ителергә тиешле нәрсә) — гомуми тавыш бирү юлы белән законнар кабул итү яки дәүләт тормышының мөһимрәк мәсьәләләрен хәл итү формасы.

**Рецидивист** (лат. recidivus — кире кайта торган) кабаттан җинаять кылган һәм элек хөкем ителгән зат.

**Рэкет** — көчләү юлы белән (шантаж, куркыту, физик җәзалау) табышны тартып алуның криминаль формасы.

**Сайлау хокукы** — дәүләт башлыгын, вәкаләтле органнарны һ.б. сайлау тәртибен билгели торган хокукый нормалар җыелмасы.

**Салымнар** — дәүләт (хакимиятнең үзәк һәм җирле органнары) тарафыннан физик һәм юридик затлардан дәүләт һәм җирле бюджетларга алына торган мәҗбүри түләүләр.

**Сальдо** (итал. saldo — исәп-хисап, калдык) — бухгалтерия балансында дебет һәм кредит суммалары арасындагы аерма.

**Санкция** — (лат. sanctio — катгый карар) — уңай яки тискәре йогынты чарасы.

**Сәясәт** — асылы социаль агентларның (индивидлар, оешма, социаль төркемнәрнең) хакимлек итү һәм

буйсындыру максатында үзара йогынтысы яткан иҗтимагый тормыш өлкәсе; шуның нәтиҗәсендә җәмгыятьтә билгеле бер социаль-сәяси тәртип формалаша, үз чиратында, әлеге үзара йогынтылар җайга салына.

**Сәяси партия** — социаль төркемнәр мәнфәгатьләрен чагылдыра, аларның активрак вәкилләрен берләштерә торган сәяси оешма.

**Сәяси программа** — җәмгыятьнең киләчәк төзелешен тасвирлай торган, хакимият башында торган хөкүмәтне тәнкыйтьләүне, халыкны борчыган көндәлек социаль һәм икътисади проблемаларны чишү чараларын һәм механизмнарын чагылдыра торган нигезләмәләр җыелмасы.

**Сәяси режим** — дәүләт хакимиятен тормышка ашыру алымнары системасы, шәхеснең демократик хокукларын һәм ирекләрен гамәлгә ашыру дәрәҗәсе, хакимлекнең үз эшчәнлеге хокукый нигезләренә мөнәсәбәте, рәсми конституцион һәм хокукый формаларның реаль сәяси тормыш белән нисбәте.

**Сәяси философия** — җәмгыятьнең идеаль төзелешенә карашлар системасы, үзенең тамырлары белән теге яки бу дөньякүләм сәяси системага — коммунизм, социализм, либерализм, консерватизм, фашизмга барып тоташа.

**Сепаратизм** (лат. separatus — аерылган) — аерылуга, ялгыз калуга омтылыш.

**Символ** (гр. symbolon — билге, тану тамгасы) — матди әйберне алыштыра торган идеаль билге.

**Сорау** — сатып алучыларның әлеге товарны алу ниятен акча мөмкинлекләр белән ныгыту.

**Социализм** — иҗтимагый милеккә һәм икътисадны планлы җайга салуга нигезләнгән җәмгыять.

**Социаль** — күп кешеләрнең үзара эш итүе нәтиҗәсендә барлыкка килгән иҗтимагый кыйммәт.

**Социаль бүленү** — халык арасында катлаулар барлыкка килү процессы (һәм аның нәтиҗәсе).

**Социаль институт** (лат. institutum — урнаштыру, оештыру) — җәмгыятьнең аның мөһим ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен җайлаштыру корылышы; социаль нормалар җыелмасы белән җайга салына.

**Социаль институтлар** — уртак эшчәнлекне оештыруның нормалар, традицияләр, гадәтләр белән җайга салына торган, җәмгыятьнең фундаменталь ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә юнәлдерелгән һәм тарихи урнашкан тотрыклы формалары.

**Социаль инфраструктура** (лат. infra — түбәнрәк, аскы һәм structura — төзелеш, урнашу) — социаль өлкәнең (мәктәпләр, сырхауханә, театр, стадионнар һ.б.) эшләве өчен кирәкле корылмалар, бина, система һәм хезмәтләр җыелмасы.

**Социаль программалар** — халыкның матди яшәү мөмкинлекләре абсолют ярлылык чигендә яки аннан түбән, ягъни яшәү минимумы дәрәҗәсендә яки аннан да түбәнрәк булган аз керемле, картайган, эшсез, гарип һәм башка төркемнәрен яклау буенча дәүләт бюджетыннан финанслана торган чаралар.

**Социаль төркем** — кешеләрнең социаль әһәмиятле критерийлар (җенес, яшь, милләт, раса, профессия, яшәү урыны, керем, хакимият, белем һ.б.) буенча аерылып алынган теләсә нинди җыелмасы.

**Социальләштерү** — мәдәни нормаларны һәм социаль рольләрне үзләштерүнең гомер буе дәвам итә торган процессы.

**Социальләштерү агентлары** — мәдәни нормаларга һәм социаль рольләрне үзләштерүгә өйрәтү өчен җаваплы кешеләр һәм учреждениеләр.

**Статус** — индивидның төркемдәге яки җәмгыятьтәге социаль позициясе (хәле).

**Стратификация** (лат. stratum — катлау һәм ...фикация) — социаль катлауларның (төркемнәрнең) өстән аска таба керемдә, белем дәрәҗәсендә, хакимлек итү күләмендә, профессиональ абруйда тигезсезлек билгесе буенча урнашуы.

**Структура** — катгый ныгытылган һәм үзара бәйләнгән элементлар җыелмасы.

**Субмәдәният** — гомуми мәдәниятнең бер өлеше, зур социаль төркемгә хас кыйммәтләр, традицияләр, гадәтләр системасы.

**Суверенлык** (дәүләтнеке) — аңа тулаем бөтен җәмгыять исеменнән эш йөртү, җәмгыятьнең барлык әгъзалары мәҗбүри үтәргә тиешле норматив актлар һәм законнар чыгару, суд эшләре алып бару хокуклары бирелүдә чагыла.

**Сыйныф** — кешеләрнең җитештерү средстволары булган яки булмаган, иҗтимагый хезмәт бүленеше системасында билгеле бер урын тоткан һәм керем алуның үзенчәлекле ысулы белән характерлана торган зур социаль төркеме.

**Табыш** — товар сатудан аны җитештерүгә һәм сатуга тотылган чыгымнарга караганда артыграк файда күрү.

**Тармак** — бер үк продукт җитештерә, охшаш технологияләр яки бер үк чимал куллана торган фирмалар төркеме.

**Тәкъдим** — җитештерүченең (сатучының) үз товарларын натураль мөмкинлекләр белән ныгытылган тәкъдим итү нияте.

**Тәкъдим күләме** — әлеге урында һәм әлеге вакытта сатучылар төрле бәя белән сатуга тәкъдим итә торган товарлар һәм хезмәтләр күләме.

**Теләктәшлек** — нинди дә булса фикерләрне яки эш-гамәлләрне уртаклаша белү.

**Тигезсез никах** — ир белән хатынның нинди дә булса әһәмиятле билге — җәмгыятьтә тоткан урыны, яше, кереме буенча аерымлыгы.

**Тигезсезлек** — җәмгыятьнең дефицит ресурсларын — акча, хакимият, белем һәм абруйны халыкның төрле дәрәҗәләре һәм катлаулары арасында тигез бүлмәү.

**Тинэйджер** — 13 яшьтән 19 яшькә кадәр малай яки яшүсмер.

**Товар** — хезмәт куеп, алмашу (сату) өчен җитештерелгән продукт.

**Тормыш планы** — алдагы тормышның идеаллаштырылган күренеше, аның нигезе булып социаль карьераның фаразланган траекториясе һәм ихтималый мөмкинлекләрнең суммасы тәшкил итә.

**Тоталитарлык** (урта гасыр лат. totalis — бөтенләй, тулаем) — дәүләтнең, җәмгыятьнең барлык өлкәләренә тулы (тоталь) контрольлек итү, конституцион хокукларны һәм ирекләрне тулысынча бетерү, оппозициягә яки башкача фикер йөртүчеләргә карата репрессияләр куллану формаларының берсе.

**Төп статус** — әлеге индивидка бик тә хас булган, тирәяктагылар аны шуның буенча аера торган (яки тәңгәлләштергән) статус.

**Традиция** — элекке буыннардан мирас булып калган бар нәрсә.

**Трансмилли** — милләтара.

**Тулы булмаган гаилә** — ата-ананың берсе генә булган гаилә, ата белән ана аерылган яки берсе үлгән вакытта барлыкка килә.

**Турыдан-туры салым** — һәр гражданнан яки хуҗалык оешмасыннан аларның керемнәре күләме яки милекләре бәясенә бәйле рәвештә дәүләт файдасына алына торган җыем.

**Университет** (лат. universitas —җыелма) — фундаменталь һәм күпләгән гамәли фәннәр, халык хуҗалыгының һәм мәдәниятнең төрле тармаклары буенча белгечләр әзерли торган югары уку һәм фәнни учреждение.

**Үз-үзеңне тоту дәрәҗәсе** — ата-аналарның бала алдында үзләрен мәдәни нормага туры китереп яки туры китермичә тотулары.

**Үз-үзен яллаган** — бер үк затта ялланган хезмәткәр һәм хуҗа.

**Фактор** (лат. factor — эшләүче, җитештерүче) — нинди дә булса процессның, күренешнең характерын яки аерым

сыйфатларын билгели торган сәбәп, хәрәкәтләндерә торган көч.

**Феминизм** — хатын-кызларның ирләр белән тигез хокуклар өчен көрәш-хәрәкәте.

**Фераль кешеләр** — кешеләрдән аерылган һәм хайваннар арасында тәрбияләнгән затлар.

**Фетишизм** (фр. fetiche — португ. feitico — амулет; тылсым) — гайре табигый сихри көчкә ия дип уйланылган җансыз әйберләргә дини табыну.

**Фирма** (лат. firma) — юридик зат булып хуҗалык эше алып бара торган оешма.

**Формаль** — язылган кагыйдәләргә һәм законнарга нигезләнгән.

**Хакимият** — закон яки традицияләр нигезендә йогынты ясау, ягъни закон яки гореф-гадәт кысаларында башка кешеләргә физик булмаган тәэсир итү; башка кешеләргә үз ихтыярыңны яки карарларыңны аларның теләкләренә бәйсез рәвештә көчләп тагу мөмкинлеге.

**Халыкның социаль составы** — зур социаль төркемнәр җыелмасы.

**Хәерчеләр** — бары тик физик ихтыяҗларын гына канәгатьләндерергә сәләтле, биологик тереклек итүләрен генә тәэмин итүче, хәергә яшәүче кешеләр.

**Хәерчелек** — иң чик ярлылык.

**Хезмәт** — товар һәм төрле хезмәтләр җитештерү һәм бүлү өчен кешенең вакытын, энергиясен һәм сәләтләрен файдалану.

**Хезмәт хакы** — эшләгән эшнең вакыт берәмлеге (атна, ай) белән үлчәнә торган бәясе; эшләгән вакыт күләмен билгеле бер ставкага тапкырлап исәпләнә.

**Хезмәткә урнашу** — эш эзләү һәм эшкә урнашу.

**Хезмәткә хокук** — эш вакытында эшче (хезмәткәр) белән эш бирүче арасындагы мөнәсәбәтләрне җайга сала торган нормалар җыелмасы.

**Хокук** — үзеңне тотуның дәүләт тарафыннан билгеләнгән

яки рөхсәт ителгән гомуммәҗбүри кагыйдәләр (нормалары) җыелмасы.

**Хокук нормасы** — кешеләрнең үзләрен тотышларында нинди дә булса хокукый хәлдә мәҗбүри башкарылырга тиешле аерым кагыйдә.

**Хокукка сәләт** — хокуклар һәм бурычлар булу.

**Хокукый дәүләт** —җәмгыятьтә законның өстенлеге, кеше хокукы һәм ирекләрен саклау, халыкның әйбәт яшәве турында кайгырту, халыкның аз керемле катлауларына актив ярдәм итү.

**Хокукый статус** — кешенең хокуклары һәм бурычлары җыелмасы.

**Хосусый милек** — гражданин яки юридик затның конкрет мөлкәткә ия булуы формаларының берсе.

**Цивилизация** — 1) «варварлыкка» алмашка килгән тарихи чор; 2) кешелек дөньясы үсешенең югары этабы; 3) мәдәни-географик берәмлек, мәсәлән, Көнчыгыш, Көнбатыш, Кытай цивилизацияләре; 4) планетаны колачлаган глобаль цивилизация.

**Цивильлек** (цивиль) — тәрбия аша мәдәни нормалар алу, мәдәният белән аралашу.

**Циклды эшсезлек** — барлык тармакларда, өлкәләрдә, төбәкләрдә эшче көчләргә сорауның гомуми кимүе белән бәйле вакытлыча эшсез калу.

**Чагыштырмача ярлылык** — яхшы яшәү дәрәҗәсен яки әлеге җәмгыятьтә кабул ителгән кайбер яшәү стандартын тоту мөмкинлеге булмау.

**Чимал** — элек хезмәт куелган һәм алга таба эшкәртелергә тиешле материаллар (мәсәлән, чыгарылган руда).

**Читләтелгән салым** — гражданнардан яки хуҗалык оешмаларыннан алар билгеле бер эш кылганда, мәсәлән кайбер төр товар сатып алганда гына дәүләт файдасына алына торган салым.

**Шактый яхшы яшәү дәрәҗәсе** — кешегә шактый уңайлы яшәү рәвеше алып бару, үзен кимсетелгән итеп сизмәү, барча уйланылган ихтыяҗларны канәгать-

ләндерү мөмкинлеге бирә торган матди байлыклар күләме.

**Шартнамә** — кешеләр, оешмалар, дәүләтләр арасындагы килешү.

**Шәһәрләшү** — кешеләрнең шәһәрләргә күчеп килүе һәм шәһәр тормышы кыйммәтләренең халыкның барлык катлауларына таралуы.

**Шәхеснең хокукый мәдәнияте** — хокукның мәгънәсе һәм аны аңлау, шулай ук алар нигезендә эш итү.

**Шәхси статус** — кешенең кече яки башлангыч төркемдә үзенең шәхси сыйфатлары буенча бәяләнүенә карап торткан роле.

**Эмиграция** (лат. emigro — күчәм) — сәяси, икътисади яки башка сәбәпләр аркасында гражданнарның үз иленнән башка илгә даими (яки озак вакытка) яшәргә китүе.

**Эмиссия** (лат. emissio — чыгару) — банк яки казначейство билетларын, кәгазь акчаларны һәм кыйммәтле кәгазьләрне әйләнешкә чыгару.

**Этник кушылу** — күп буыннар дәвамында төрле этник төркемнәрнең милләтара никахлар аша стихияле төстә кушылуы һәм бер милләт барлыкка килү.

**Этнос** (гр. ethnos — кабилә, халык) — кабилә, халык яки милләт барлыкка китерүче кан кардәш кешеләр төркеменең гомумиләштерелгән исеме.

**Этноцентризм** — үз мәдәниятеңнең дөреслеген тану, башка мәдәният стандартларын ялгыш дип карау.

**Эш** — билгеле бер түләү өчен башкарыла торган эшчәнлекнең теләсә нинди төре.

**Эш буенча түләү** — җитештерелгән продукция күләменә карап түләү.

**Эшмәкәр** — предприятие хуҗасы, табыш алу нияте белән шәхси яки бурычка алып торган акчалары ярдәмендә яңа эшкә нигез салучы.

**Эшмәкәрлек** — товарлар җитештерү һәм хезмәтләр күрсәтү өчен шәхси яки бурычка алып торылган акча

исәбенә хуҗалык оешмалары (фирмалар) булдыру һәм шул нигездә керем алу.

**Эшсез** — хезмәт хакы алмаучы, эшсезлек буенча пособие дигән махсус пособиегә яшәүче кеше.

**Эшсезлек** — хезмәткә яраклы һәм эш яшендәге кешеләрнең иҗтимагый җитештерүдә катнашмавы.

**Эшсезлек дәрәҗәсе** — эшсезләр санының хуҗалыкта мәшгуль кешеләрнең гомуми санына нисбәте.

**Ябык җәмгыять** — түбән дәрәҗәдән югарысына социаль күчү тулысынча тыелган яки шактый чикләнгән җәмгыять.

**Ялланган хезмәт** — үз милке булмаган предприятиедә килешү буенча эшләүче хезмәткәрнең хезмәте.

**Яңарту** — заман таләпләренә туры китереп үзгәртү, камилләштерү (мәсәлән, җиһазларны яңарту).

**«Яңа руслар»** — бездә базар мөнәсәбәтләре елларында барлыкка килгән эре, урта һәм вак буржуазия.

**Яраклашу** — физик яки социаль мохиткә күнегү.

**Ярлылык** — минималь акча, белем, хакимият һәм абруйга ия кешеләрнең икътисади һәм социаль хәле. Ләкин ярлылык мәдәни күренеш тә әле ул.

**Ярлылык чиге** — иң аз керем сыйфатында рәсми төстә расланган акча суммасы (мәсәлән, доллар яки сумнар белән исәпләнә), шуңа ялгыз кеше яки гаилә азыктөлек, кием-салым, торак ала. Аны шулай ук «ярлылык дәрәҗәсе» дип тә атыйлар. Россиядә ул яшәү минимумы дигән өстәмә исем дә алды.

**Яшәү минимумы** — фәнни күзлектән караганда, кешегә минималь кирәкле ихтыяҗларны канәгатьләндерү өчен җитәрлек товарлар һәм хезмәтләр (реаль сатып алу бәяләрендә) җыелмасы.

## Әдәбият

*Алексеев В.П.* Становление человечества. М., 1984.

*Андреев И.Л.* Происхождение человека и общества. М., 1988.

*Андреева Г.М.* Социальная психология. М., 1994.

*Арутюнов С.А.* Народы и культуры: Развитие и взаимодействие. М., 1989.

*Байбурин А.К., Топорков А.Л.* У истоков этикета. Этнографические очерки. Л., 1990.

*Белозерова В.Г., Ващенко А.В.* История цивилизаций мира: Уч. пособие для 10–11 классов. М., 1988.

*Берн Э.* Игры, в которые играют люди. Люди, которые играют в игры. М., 1988.

*Бергер П.Л.* Приглашение в социологию: Гуманистическая перспектива / Пер. с англ. М., 1996.

*Бодалев А.А.* Личность и общение: Избранные психологические труды. 2-е изд., перераб. М., 1995.

*Введение в обществознание.* Актуальные проблемы: Пособие. М., 1991.

*Введение в обществознание:* Учебн. пособие для 8–9 классов общеобразовательных учреждений / А.И.Матвеева, Л.Ф.Иванова, Л.Н.Боголюбов и др.; Под ред. Л.Н.Боголюбова. 2-е изд. М., 1997.

*Гофман А.Б.* Мода и люди: Новая теория моды и модного поведения. М.,1994.

*Гуревич А.Я.* Проблемы средневековой народной культуры. М., 1981.

*Гусейнов А.А., Апресян Р.Г.* Этика: Учебник для вузов. М., 1998.

*Здравомыслов А.Г.* Социология конфликта. М., 1995.

*Клибанов А.И.* Духовная культура средневековой Руси. М., 1994.

*Клименко А.В., Румынина В.В.* Обществознание в вопросах и ответах: Учеб. пособие для старшекл. и поступающих в вузы. М., 1998.

*Кон И.О.* Открытие «Я». М., 1978.

*Кравченко А.И.* Обществознание: Учебник для 8–9 классов. М., 2004.

*Липсиц И.В.* Экономика без тайн. М.,1993.

*Лихачев Д.С.* Прошлое — будущему: Статьи и очерки. Л., 1985.

*Пономарева Г.М. Немировская Л.З., Тюляева Т.И.* Основа культурологии: Учебное пособие для 10–11 классов. М., 1998.

*Поршнев Б.Ф.* Социальная психология и история. М., 1979.

*Прикладная экономика.* М., 1993.

*Пугачев В.П., Соловьев А.И.* Введение в политологию. М., 1995.

*Россия в окружающем мире*: 1998 (Аналитический ежегодник). М., 1998.

*Руднев В.А.* Древо жизни: Об истоках народных и религиозных обрядов. М.; Л., 1989.

*Русская нация:* Историческое прошлое и проблема возрождения. М., 1995.

*Самуэльсон П.* Экономика. М., 1964.

*Семья на пороге третьего тысячелетия.* М., 1995.

*Семенникова Л.И.* Цивилизации в истории человечества: Учебное пособие. Брянск: Курсив, 1998.

*Соколов Э.В.* Культурология. Очерки теорий культуры: Пособие для старшеклассников. М., 1994.

*Сорокин П.* Человек, цивилизация, общество. М., 1992.

*Социальные реформы в России:* История, соврем. состояние и перспективы. СПб., 1995.

*Февр Л.* Бои за историю. М., 1991.

*Фрейд З.* Будущее одной иллюзии. М., 1990.

*Фромм Э.* Иметь или быть. М., 1990.

*Юнг Г.* Современность и будущее. Минск, 1992.

*Юнг Г.* Программа души современного человека // Это человек: Антология / Сост. П.С. Гуревич. М., 1995.

Учебное издание

*Кравченко Альберт Иванович*

ОБЩЕСТВОЗНАНИЕ

Учебник для 10 класса
общеобразовательных учреждений

*(перевод с русского на татарский язык)*

Редакторы *Р. С. Вафина*
Корректоры *Ә. Ф. Әхмәдуллина*
Компьютерда биткә салучы *В. М. Садыйкова*

Татарстан Республикасы «Хәтер» нәшрияты.
420111, Казан, Тельман ур., 5.
Хатлар өчен: 420014, Казан, Кремль, а/я 54.
Тел. (факс): (8432) 264-67-96

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 22.11.2009. Форматы 60×90 1/16.
Офсет кәгазе. «Школьная» гарнитурасы. Офсет басма. Басма табагы 12.
Тиражы 6450 д., Заказ В-1603.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ.
420066, Казан, Декабристлар ур., 2.

«РУССКОЕ СЛОВО»
«ХӘТЕР»